Безнен Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

08

август 2019

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ИРИНА КОЛМОГОРЦЕВА «КЫР ЧӘЧӘКЛӘРЕ ЯҢГЫРДАН СОҢ»

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

БИШЬЕЛЛЫК ЭШКӘ ХИСАП

11 июльдә Казанда Бишенче чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының соңгы – кырык тугызынчы утырышы булып узды. Утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров катнашты. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Республика парламентының бишьеллык эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап ясады.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
08 (308)
август 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

73

34 **ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛЛАР СӘЛАМЕ...**
Рүзәл Мөхәммәтшин



62 **ХАТИРӘТ**
Сәгыйть Сүнчәләй

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Газинур Морат**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*
9 **Төрки халыкларның гомуми тарихы.** *Х.Габәши*
14 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
21 **Большевизм уты астына.** *К.Нәҗми*
28 **Агымсуларны эшкә җигәсе бар.** *Ф.Хатипов*
34 **Егерменче еллар сәламе...** *Р.Мөхәммәтшин*

ТАТАР ГАМЕ

36 **«Бәйгеләрдә бәйге тоткан кавем...»** *Ф.Леронова*
42 **Безнең заман һәм замандашлар.** *Р.Хәбибуллина*

ДИНИ МИРАС

50 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*
56 **Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?** *Г.Буби*

ӘДӘБИ МИРАС

62 **Хатирәт.** *С.Сүнчәләй*
68 **«Хөсәен мирза» трагедиясе турында.** *А.Әхмәдуллин*
69 **Хөсәен Мирза.** *Ф.Бурнаш*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

73 **Гомәр Бәширов көндәлегеннән**

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

77 **Изге антка тугрылык.** *Ш.Мостафин*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

83 **Мөхтәрәм Мөдәмил ядкяре.** *Р.Зарипов*

95 **Мәктәпләр һәм сабакташлар.** *Л.Лерон*
98 **Кайсысы дөрес: «Фатих»мы, әллә «Фатиһ»мы?** *Ф.Кутлу*
100 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

102 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

106 **Ил тотмыйча, тел тотып кара…** *Б.Рәхимова*

ХӘТЕР САГЫНДА

110 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Август*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Лотфулла Шәфигуллин
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №О-1890. Тираж – 2250 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 23.07.2019.
Чыгу көне: 29.07.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Кыр чәчәкләре яңгырдан соң».** 1995.
Ирина Колмогорцева рәсеме



Газинур Морат

Китап сүзе

Хөкем итмә – хөкем ителмәссең, –
Күктән иңгән тәүге хәбәрдер.
Әлмисактан килгән Китап сүзен
Хәкарәтләү – язык, хәрәмдер.

Угры түгел – тугры булу кирәк, –
Шулай кушкан Китап яшәргә.
Кассаплыкны кәсеп иткән өчен
Купкандыр бу Җирдә мәхшәр дә.

Кан коючы, җан кыючы булып,
Барымтага барма күршеңә.
Хәрәм белән түгел, хәләл белән
Яшәү индерелгән кешегә.

Яманлыкны ялган белән ямау –
Илгә килгән иң зур казадыр.
Илдә һаман канун ишәйгәндә,
Азгынлык та шулай азадыр.

Китап сүзе иңгәчтен дә, дөнья
Карыш юл да гүя үтмәгән.
Илдә һаман канун ишәйгәндә,
Илнең башы чыкмас фетнәдән.

Бер кануны меңгә әйләнгәндә,
Меңгә төрләнгәндә үзебез.
Сират күперен дә кичәрбез күк,
Тота алсак Китап сүзен без. ■

Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шагыйрь Газинур Морат (Газинур Васик улы Моратов) 1959 елның 18 августында Татарстанның Кукмара районындагы Зур Сәрдек авылында туган.

Редакциядән: Бу айда мөхтәрәм каләмдәшебезгә 60 яшь тула. Танылган әдипне юбилее белән ихластан котлыйбыз һәм аңа саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез!

Безнең мирас №8 август 2019

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән.

Сөембикәнең маҗаралары бу өзектә дә дәвам итә. Ат өстеннән очып төшкәч, ул кар тоткынлыгына һәм үзенә кайчандыр таныш булган колларга килеп эләгә. Әсәр авторының хыялында гына тугандыр, дисәк тә, бу күренешләр, кешеләр һәм аларның сөйләшү рәвешләре ышандырырлык итеп сурәтләнгән. Укып карагыз әле, мөгаен, сез дә моны күрерсез, Сөембикә язмышының кискен борылышлары сезне дә дулкынландырмый калмас.

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

Ак киез белән төрелгән тирмәсеннән чыккач, бәк күккә күз салып алды да нөкәрен чакырды. Кысык күзле елдам сугышчы иярләнгән атны җәһәт кенә алып килде. Этләр әле һаман өрүдән туктамаган иде. Кызлар шул тирәгә барып җиткәннәр инде, кашлыктагы кар белән капланган кечкенә түмгәк өстенә иелгәннәр, аларның куркып кычкырганын нөкәр белән бәк тә ишетте. Алар, борчылып, шул тарафка карадылар, ә кызлар, чинашып, алар янына йөгерде:

– Әй, әфәндебез! Безне Аллаһ ярдәменнән ташламасын, ләкин анда... Анда кеше!

Кыю Туйчы гына шул сәер калкулык янында калды, ул карны казып як-якка таратты, этләрне куып җибәрде. Инде мехларга төренгән кеше билгеләре беленә башлады.

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

Нөкәр хуҗасыннан алда йөгереп килде, туңган кешене чалкан әйләндерде, йөзенә сыланган карны сыпырып алды. Ул арада килеп җиткән Әхтәм бәкнең аягы астында җир убылгандай булды. Әле бер мизгел генә кукраеп, кабаланмыйча гына чыгып барган ир ашыгып тезләнде, кайнар бармаклары белән салкын, бозланган битне капшарга кереште:

– Сөембикә!

Хатын ыңгырашып куйды, ябышкан керфекләрен авырлык белән генә ачты һәм өстенә иелгән ирләргә карады. Тоныкланган аң пәрдәсе аша аларның берсе таныш кебек тоелды. Морзабәк аны кулларына күтәрде, шул көе тирмәсенә йөгерде, үзе акылыннан шашкан кебек пышылдады:

– Аһ! Ходай сине – бәһасез хәзинәмне миңа кайтарды!

Тирмә янында ул һушына килде, кулындагы кадерле йөкне җиргә төшерде, учлап-учлап йомшак кар алып, аның кулларын, йөзен уарга кереште. Хатын, авыртуга түзә алмый, кычкырырга тотынды, ә ул, барыбер тыңламыйча, уды да уды. Тирмәдән өлкән хатыны Калдыбикә атылып чыкты, куркып, иренә һәм ул алып кайткан ханымга карады:

– Хуҗам, бу кем?

Әхтәм бәк бикәгә бер күз салды да:

– Урын-җир, сарык мае һәм кайнар үлән чәе әзерлә! – диде.

Берсүзсез буйсынырга гадәтләнгән хатын шунда ук эчкә кереп югалды. Нөкәр хуҗасы тирәсендә бөтерелде, ярдәм итәргә теләвен әйтте, әмма бәк, аның кулын читкә тибәреп, яссы каракучкыл чыраена төксе генә карап алды:

– Бу хатынның исемен беркем дә белергә тиеш түгел. Мин әйткәннәрнең барысын да оныт. Артыгын сөйләнсәң, иртәгә мәетеңне этләр кимерер!

Нөкәр берни дә аңламаган күзләрен тасрайтты, куркып, башын чайкады:

– Ничек кушасыз, әфәндем. Мин инде барысын да оныттым.

Ир бәһасез йөкне яңадан кулларына күтәрде, аерыла алмыйча, Сөембикәнең күзләренә текәлде. Казан ханбикәсе үзен бөтен дөньядан аерылган хәлдә – болытлар артында, бик еракта итеп тойды, ул берни дә аңламады, әмма күтәргән ирне таныды. Кан белән укмашкан иреннәре көчкә генә кыймылдап куйды:

– Әхтәм бәк...

Калдыбикә тирмәдәге кечкенә казанда кайный башлаган шифалы чәйне болгатып тора. Үлән чәе хуш исле дулкын булып тарала һәм учак төтене белән бергә өскә – түшәмдәге төнлеккә менеп китә. Туйчы, кашларын җыерып, бер почмакта утыра. Ул бикәгә дә, гомумән, тирә-юньдә барган хәлләргә дә бернинди катнашы юк сыман кыяфәт ясый. Кызый ягымлы һәм игътибарлы булган хатынга үпкәли, Калдыбикәнең беркайчан да аның белән бүгенге кебек коры-кырыс сөйләшкәне, орышканы һәм битәрләгәне булмады бит. Барысы да чокыр буенда табылган хатын аркасында килеп чыкты. Әлеге таныш түгел табылдык Туйчының тынычлыгын алды, кызыксынуын көчәйткәннән-көчәйтә барды, әмма аның бөтен сораштырулары җавапсыз калды. Кыз чаршау артына – торлак хуҗасы әлеге «табыш»ны алып кереп яшергән якка үтеп кермәкче иде, бикә шунда ук аңа очып кунды, чәч толымнарыннан тартып туктатты, тынңны да чыгармыйча шул почмакта гына утыр, дип кисәтте. Калдыбикә әле һаман аңа ачулы, Туйчы моны хатынның туткыл маңгаендагы җыерылган сырлардан һәм кырысланып кысылган иреннәреннән күреп тора. Әмма асрамага алынган кыз чамалап алды: бикә аңа түгел, ә теге, чаршау артында исенә килә алмый яткан хатын янынннан әлегә кадәр

чыкмый торган иренә ачулана булса кирәк. «Кем икән ул?» – дип бик беләсе килде Туйчының. Хуҗа әйткән исемне ул бик ачык ишетеп калды – «Сөембикә». Дала карлары эченнән пәйда булган хатынның коры холыклы Әхтәм бәккә нинди кагылышы бар? Үзенең почмагында утырган көе, Туйчы ант итте: бу серне белмәсә, ул – ул булмаячак. Учак янындагы бикә үлән чәен чынаякка салмакчы иде, ләкин, саксызлык күрсәтеп, кулын пешерде бугай: чынаякны идәнгә төшереп җибәрде. Туйчы аңа ярдәм итәргә ташланды, хезмәт күрсәтергә тырышуында арттырып та да җибәреп, бикәнең яшь белән мөлдерәмә тулы күзләренә карады:

– Мин Сезгә булышам.

Хатынның яклау һәм иркәләүгә мохтаҗ йомшак күңеле эреде дә китте. Калдыбикә, асрамага алган кызының аркасыннан сөйде дә:

– Булыш, акыллым, миңа үпкәләмә инде. Авыр миңа, әй, бик авыр, – диде.

Бикә, күлмәгенең киң җиңен сызганып, пешкән кулын караштырды.

– Кайдан килеп чыкты ул? – дип ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады хатын. – Минем бичара иремнән аңа ни кирәк?

Калдыбикәнең пышылдавы игътибарсыз калмады, Туйчының күзләре түгәрәкләнде, хәтта авызы ачылып калды. Асрамага алган әнисеннән ул хатынның кемлеген дә сорашмакчы иде, әмма, күптән түгел генә каты шелтә алуы исенә төшеп, телен тешләде. Юк инде, ул акыллы гына дәшми дә кала ала. Кыз үлән чәе белән чынаякны тотырып, бик юаш кына:

– Кертеп биримме, бикә, – диде.

– Уйлама да! – Хатынның тавышы янә кырысланды. – Үзем бирәм.

Бикә чаршауны ачып эчкә керде, ә аның артыннан, күләгәсе кебек тагылып, Туйчы барып өлгерде. Кыз, моның өчен тагын чәченнән сөйрисеннәрен белсә дә, чаршау ярыгына бер күзе белән генә сыланып, бүлмә эченә карады: ул кызыксынуыннан чынчынлап яна иде. Әнә, дәһшәтле дала бәге ятак каршында тезләнеп тора, ә теге, чит хатын тиреләр өстенә яткан да йөзен киез диварга борган. Әхтәм бәк, бу битарафлыкны бөтенләй күрмәгәндәй, дәртләнеп, аның учларына битен куя, кулларын сыйпый һәм үбә.

– Пәрием[1] минем. Сөйгәнем, – дип пышылдый иде бәк. – Мин синең өчен генә яшим, җанымны синең аяк очыңа салырга әзермен. Куш кына, бер тапкыр булса да илтифат итеп карачы. Телисең икән, кылычың, атар угың, колың булам!

– Ирем, – Калдыбикәнең тавышы калтыранып чыкты. – Сез сораганча, үлән чәе алып кергән идем.

Бәк аягына сикереп торып басты, кашын җыерып, өлкән хатынына карап алды:

– Бир чынаякны, мин аны үзем эчерәм.

– Аны карап-тәрбияләп торырга рөхсәт итегез, – дип, ялварулы күзләре белән иренең кырыс йөзенә карап сорады Калдыбикә. – Хатын-кызга ир-ат хезмәт күрсәтүе – күз күрмәгән, колак ишетмәгән хәл бит. Аңа хатын-кыз кулы һәм кайгыртуы кирәк.

– Кит әле моннан! – Әхтәм бәк хатынының кулыннан чынаякны тартып алды.

Башкалардан көнләшеп саклаган хәзинәсенә таба борылып, ул кабат тезләнде. Хәзер аның хәрәкәтләре тагын да ягымлырак һәм саграк була башлады. Авыруның башын үзенә таба борып, ярылган ирененә чынаякның ирнәвен тидерде:

– Эчегез, ханым, бу үләннәрдә даланың бөтен көче тупланган. Күрерсез дә торырсыз, алар Сезнең хәлегезне җиңеләйтер.

Хатынның иреннәреннән газаплы ыңгырашу саркылып чыкты, әмма ул барыбер кайнар чәйне йотты, аннары тагын бер йотым эчеп куйды. Бикә, кайгырып, башын

[1] Пәрием – чибәрем, гүзәлем *(тәрҗ. иск.)*.

чайкады һәм чаршауны ныгытып ябып чыгып китте. Тиктормас Туйчыга шикләнеп күз ташлады, тегесе исә, берни булмагандай, үлән чәен болгата иде.

– Казанны тынычлыкта калдыр, – дип мыгырдап алды бикә. – Суга барып килүең хәерлерәк булыр, аның кирәге чыгуы бар.

Әхтәм бәк өлкән хатыны Калдыбикә тирмәсеннән чыкмады. Чырае төксе, үзе уйчан иде, янындагы инде суынган ширбәт белән тулы бизәкле касәгә кагылмады да. Бикә караңгы почмактан, борчылып, ирен күзәтте, бу мәлдә ул күңеле төшенкелеккә бирелгән улының сагышлану сәбәбен йөзеннән аңларга тырышкан кайгыртучан ананы хәтерләтте. Калдыбикә әле карт түгел, бу тирмәнең бусагасыннан атлап керүенә унбиш кенә ел узды. Аны кәләш итеп алганда кайчандыр атаклы һәм бай мангыт нәселеннән булган ир-егет кызның атасына калымны көч-хәл белән генә түли алды. Әхтәм бәккә мирас булып тишек-тошык берничә тирмә һәм тагын йолкыш киемле көтүче коллар гына калган иде. Ни гомер бәргәләнде ул, башына төшкән хәерчелекне җиңәргә азапланды. Соңгы елларда бәк Хаҗитарханда көн күрде, анда дала ханының иң яхшы сәргаскәре булып танылды. Хаҗитарханда аны «Барыс» дип йөрттеләр һәм Әхтәм бәк үзенә тагылган бу исем-кушаматны аклады. Бикә ире белән горурлана ала иде: курку белмәс «Барыс» исәпсез-сансыз баскынчылык итүләрдә байлык туплады, үлеп барган олыска җан кертте. Нугай далаларына ул күптән түгел генә әйләнеп кайтты һәм туган җирендә күчмәннәр арасында тормышын җайга салырга кереште. Бәккә варис кирәк иде, тик аларның бердәнбер улы чирле булып туды, бер мәртәбә дә аягына басып карый алмады. Бикә иренең яңа хатын, аннары тагын берне алуын гаепкә санамады. Иренең Йосыф кызына – Сөембикәгә өметсез мәхәббәте турында барысыннан да күбрәк белә иде ул. Аның аркасында бәк кайчандыр Хаҗитарханга качып китте, бәкләр бәгенең коточкыч ачуы чыгуыннан башына боз явуын көтеп яшәде. Ләкин давыл купмады, чөнки Әхтәмнең ул чакта Сөембикәне шулкадәр тупас рәвештә урларга маташуын Йосыф бөтенләй белми калды. Ә үзенең мәхәббәте белән саташкан бәк һаман язмыш белән уйнавын дәвам итте. Ул, күңелен алгысыткан хатынның чалымнарын эзләгән кебек, Йосыф нәселеннән кызлар алды. Әмма чибәр һәм яшь хатыннары хуҗаның нәселен озайтмау гына түгел, аны шашкын мәхәббәт бизгәгеннән дә дәвалый алмадылар. Сөембикә турында теләсә кемнең искә төшерүе генә дә Әхтәм бәкне ярсыта иде. Аларның аиленә, кар эченә Казан ханбикәсен китереп ташлаганда Ходай ни уйлагандыр, анысы Калдыбикәгә нәмәгълүм, әмма ирен акылга китерү, аңа күңел тынычлыгын кайтару өчен, ул көн саен догалар укыды.

Хатын әледән-әле, борчылып, артында Сөембикә яткан чаршауга карап куя. «Кайдан гына килеп чыктың соң син, Йосыф кызы? – дип, әвә-түнә йөреп уйланды Калдыбикә. – Нишләп аның йөрәген тагын да газапларга пәйда булдың? Аңа – бөтен тормышымны багышлаган иргә – мин ничек кенә булышыйм?» Уйлары көтмәгәндә өзелеп китте, хатын хәтта сикереп куйды һәм кулындагы инә-җебен, чигешен төшереп җибәрде. Ул инде, иренең игътибарын үзенә тартмыйча, тирмәдән ничек чыгып китәргә икән дип баш вата башлады, бер почмакта нәрсәдер эшләгән кебек йөрде-йөрде дә, бәк ягына борылып карамыйча гына, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

– Бу тиктормас Туйчы кая китеп югалды соң? Су алып кайтырга кушармын, дигән идем...

Ире һаман дәшми-тынмый, урыныннан кузгалмый утыруын белде, шуңа бикәгә тирмәдән бер тоткарлыксыз чыгу юлы ачылды. Инде күптән караңгы тoрактан башка дөнья йөзен күрмәгән хатынның ап-ак кардан күзләре чагылды. Ул дулкынланудан ярсып типкән йөрәген ике куллап кыскан хәлдә беркавым басып торды. Чокыр буенда

сыенышып торган ярлы тирмәләрнең берсендә аның ерак туган тиешле кешесе Сарман яши иде. Шуның ишеген шакыгач, торлак хуҗабикәсе аны бик аптырап-гаҗәпләнеп каршы алды, бертуктамый аны мактый-мактый түргә уздырды. Сарманның хатыны да әрле-бирле йөгергәләде, тиз генә утка кизәк[2] ташлады.

– Тиздән көлчәләр әзер булачак, бикә, – диде бичә. – Әлегә әйрән алып килә торыйм. Сарман күптән түгел генә көтүдән бия сөте алып кайткан иде, менә дигән әйрән килеп чыкты.

Ләкин кунакчыллык кануннарын һәрвакыт хөрмәт иткән бикә бу юлы туган тиешле кешесенең хатынына борылып та карамады. Ул, дулкынлануын көчкә тыеп, Сарманга эндәште:

– Миңа Баһадур кирәк иде, кайда ул?

Ат көтүчесе белән хатыны, пошаманга төшеп, бер-берсенә караштылар. Бикәнең асрамага алган кызы Туйчы белән улларын кавыштырырга теләвен икесе дә беләләр иде. Тик нишләп әле бикә үзен бик сәер тота? Баһадур берәр ярамаган гамәл кылып ташламадымы икән? Сарман хатынына ым какты:

– Карале, мөгаен, улыбыз бәкнең айгыры янында кайнашадыр, аны ашату белән мәшгульдер. Сез беләсез бит инде, мөхтәрәм бикә, Әхтәм бәк үзенең атын Баһадурга гына ышанып тапшыра.

– Әйе, шулай шул. – Калдыбикә башын кагып алды, әмма барыбер сүзнең ни турында барганын аңламаган кебек иде әле. Ул үзен көйдергеч ут ялмап алганын тойды, күз алдында һәммә нәрсә биешә башлады: Сарманның ничек тә ярарга тырышкан йөзен һәм бөрешеп беткән кечкенә буйлы бичәсенең җилкәсенә ашык-пошык бишмәтен салырга тотынуын, ә аннары, томан эчендәге кебек, каршысына килеп баскан Баһадурны күрде. Бикә җилкәләрен куллары белән кочаклап алды, түзеп булмаслык калтыравын басарга тырышты.

– Безнең икебезне генә калдырып торыгыз әле, – дип сорады ул Сарман белән аның хатыныннан.

Алар тирмәдән чыгу белән, хатын егеткә эндәште:

– Ат аласың да, Баһадур, әлбәттә, иң яхшы атны, шунда ук Сарайчыкка җилдерәсең. Бөек бәкләр бәгенә аның кызы табылганын, безнең аилдә икәнлеген хәбәр итәсең. Тик артыгын берни дә әйтәсе түгел, Баһадур улым.

Бикә ат сайлашырга үзе дә барды һәм егетне сәфәргә озатып калды. Баһадурның яшь чаптары кар белән өртелгән дала буйлап очып киткәнен күзен дә алмыйча карап калды ул.

– Мин кушканны башкарып чык, улым, – дип үзалдына пышылдады хатын, – тик Сарайчыкка барып җитә генә күр. Шул чакта минем ирем дә бу казадан котылыр.

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

---

[2] Кизәк – тирес кирпеч (ягулык).

Безнең мирас №8 август 2019

Төрки халыкларның гомуми тарихы

Хәсәнгата Габәши*

Фин кавеме

Туран кавеменең бик зур өлешеннән вә саф төрек кавеменең иң якыныннан бере – фин кавемедер. Болар «угыр-алтай», «урал-алтай» вә «төрки-фин» кавемнәре аталмышлардыр. Сәбәбе дә боларның әүвәлге урыннары Алтай таулары[1] булып, кавеменең күбрәге искедән угыр аталмыш төрек илә финнән катыш бер халык булганлыктан, «угыр-алтай» кавеме аталмышлардыр. Күбрәге Урал таулары тирәсендә җирләштекләреннән вә башка тарафка китмешләре дә әүвәл озак вакыт Урал тирәсендә күченеп, соңрак башка тарафларга сачылдыкларыннан, «урал-алтай» кавеме аталмышлардыр. Бу кавемнәрдән немецләргә әүвәл мәгълүм булганнары сазлыкларда тереклек итүчеләре булганыннан, немецләр сазлыкта тереклек итүче мәгънәсендә булган фин исеме илә атамышлардыр. Бу кавем бик искедә төрек ыругларыннан бер кисәк булып, шул заманнардан соңгы заманнарга кадәр саф төрек

Чирмеш-марилар. (Народы России. Черемисы (марийцы) Симбирской губернии, 1880-е года.)

*Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 2 нче санында. Текст хәзерге әдәби телгә берникадәр якынайтылып бирелә.

[1] Алтай сүзе, кайберәүләр фикеренчә, «алтын тау»дан барлыкка килгән. Әмма соңгылар «алтын тау» түгел, бәлки, ул тирә төрекләре теленчә, олуг урман мәгънәсендә булган «ал тайга» мәгънәсендә дип уйлыйлар.

кавеме илә һәрвакыт күршелектә вә алар илә бик катышу вә аралашуда булдылар. Хәтта шулкадәр аралашмышлар ки, араларыннан кавемнәр тугмыш. Ул кавемнәрне фин кавеменә дә вә төрек кавеменә дә нисбәт итәргә мөмкин. Моның өчен фин халкы «төрек-фин» кавеме дип тә аталмыштыр[2].

Юнанилар финнәрне славяннар илә бер, дип, күп вакыт боларның хаким кавемнәре булган төрки кавем исеме – скит дип атадыклары кеби, шул ук канун илә гарәпләр дә финнарны сакляб (ягъни, славян) атамышлар иде. Славяннар исә финнәрне, гомумән, чуд дип атадылар. Әмма финнәр үзләрен «сумалайн», «суоми», «манса» «мари» кеби төрле исемнәр илә атамышлар иде. Бу заманыбызда географ вә тарихчылар аларны «фин» исеме илә генә йөртәләр.

Фин кавеменең тармаклары

Фин кавеме бик иске заманнардан Алтайдан чыгып, төньяк тарафларга сачелделәр. Төркестан сахралары төньягына, Сибириягә, Иртыш вә Обь, Йәнәси сулары түбән тарафларына, Урал таулары тирәсенә вә аның төньяк тарафларына, Ауропа төньяк-көнчыгышына вә төньягына, Балтыйк төньягындагы Швеция, Норвегия, Дания вә Төньяк Боз океанына кадәр, Балтыйк көньягындагы Двина елгасы тирәләренә, Волга башларына, Москва, Ука сулары, Зөя, Волга[3], Кама, Вятка, Уфа елгалары тирәсенә сачелмешләрдер.

Тарихларда исеме күрелгән вә бу вакытка кадәр сәламәт тереклек итмәктә булган фин кавемнәре ошбулардыр: камасин, тува, кет, арин, асан вә гайреләр – Алтай төньягында. Самоедлар – Турхан, Йәнәси, Обь сулары түбәнендә[4] вә Төньяк Боз океаны буйларында. Остяк, истәк, вогуллар да Йәнәси, Иртыш вә Обь (самоедлардан көньяктарак) вә Урал таулары тирәләрендә вә аның бераз көнбатыш тарафында яши. Березовский остяклары югра дип тә аталыналар.

Печора – Урал таулары төньяк-көнбатышында Печора елгасы буенда; зырян – Урал таулары көнбатышында, Кама башларында; биарми – Урал таулары илә Кама башлары арасында; лаплан (саамнар) – Ауропа төньягында, Төньяк Боз океаны буйларында; емь – Финляндиядә; лив – Ливониядә; чуд – Ладога күле көнчыгышында; эстлар – Эстониядә; нарвалар – Норвегиядә, вепслар – Белое озерода; мерлар – Растов[5] һәм Москва елгасы көнчыгышында; вотяк (ар)[6], бисермән – Вятка Иделе тирәсендә; чирмешләр – мер халкының көньяк-көнбатышында, Уфа, Вятка, Волга сулары тирәсендә; муром – Ука елгасының түбән тирәләрендә[7]; мишчарлар – Ука

---

[2] Ибне Халдун финнәрне төрек кавеменнән диядер. Финнәр арасында төрек телендә дастаннар барлыкны хикәя кылалар.

[3] Волга елгасы иң иске тарихларда – «Ра», ислам тарихларында «Ител» аталмыштыр. Кама – «Чулман», Вятка – «Нократ», Уфа – «Ак Ител» дип атала.

[4] Самоедларның болгарларга охшаш икәне ачыкланган.

[5] Волга югарысында булган Растов шәһәре фин-меряларныкы иде. IX гасыр урталарына кадәр фин кавеме илә славян кавемнәре арасында чик Мәскәү елгасы иде. Мәскәү губернасында Мирска аталмыш су, шиксез, ошбу мерялар җиреннән агадыр иде. Великий рус кавеме славян илә ошбу славянлашмыш финнәрнең бергә җыелуыннан хасил булды (Соловьев).

[6] Арлар (вотяк) болгарлар илә бик якын аралашмышлар иде. Хәтта иске болгарларның бер калгасе «ар» кәлимәсенең төрекчә әйтелеше булган Арча исеме илә аталмыш иде. Вә моның өстенә Вятка губернасында булган арлардан бер фирка бисермәннәр (мөселманнар) үзләрен иске болгар кавеменең дәвамчылары дип хисап итәләр.

[7] Бу кавемнәр исеме рус тарихларында «мишчар» вә «мажар» сурәтендә язылмышлардыр. «Ш», «ч» хәрефе фин вә төрек телләрендә булмаганлыктан, әүвәлдә бу сүзләр, әлбәттә, «шин» илә мишәр вә «ч» илә мичар әйтелмешләрдер. Ука тирәләрендә вә көньягында, Волганың көнбатыш вә көнчыгышында, төс-кыяфәт вә мәгыйшәтләрендә бераз финлек әсәре күрелмеш төрек кавемнәр мишәр аталмышлардыр. Мачар вә мажар исеменәре хәзер дә фин вә төрекләр арасында ишетеләдер. Аңлашылганча, болар мажар вә мазар сурәтләренә дүндерелмешләрдер. Казан тирәсендә ошбу мажар вә мазар исеме илә аталмыш мөселман авыллары әле дә бардыр.

елгасы буйларында (хәзерге Касыйм – Ханкирмән шәһәре ошбу кавемгә нисбәт илә әүвәлдә мишчар шәһәре аталмыш иде). Чуаш, мукшы, мордва – Сура, Зөя, Волга сулары тирәсендә. Гарәпләр бу халыкларны бортаслар дип тә атыйлар.

Ауропага арилар кавеме килгәнче анда тереклек иткән ибер вә басик кеби турани кавемнәр дә ошбу фин ыругларыннан булулары гөман ителенәдер[8]. Бу халыклардан бәгъзеләре: вепс, меря, муром, кайбал, кут вә гайреләр, кавемиятләрен саклый алмый славянлашып, руслар эчендә югалмышлардыр. Кайберләре бу көнгә кадәр сәламәт булсалар да, ләкин барчасын славянлаштырмак өчен бик олуг чаралар күрелмештер.

Фин кавеменең тел вә кыяфәтләре

Барча фин ыругы халкының телләре вә кыяфәтләре бере-беренә бик якындыр. Төрки телгә дә якын вә мөнәсәбәтле идекне тел галимнәре тикшерделәр. Вә кыяфәт гыйлеме (антропология) галимнәре «төрек-монгол» кыяфәте таныйлар. Һава вә климат соңрак гәрчә кыяфәтләрен күп үзгәртсә дә, ләкин асыл сималары һаман да сәламәт калмыштыр. Араларында кайберләре, мисал, вагуллар кыяфәт җәһәтеннән монгол кавеменә, самоедлар да болгар төрекләренә бик охшаулы табылдыгы кеби, чуашлар да тел җәһәтеннән аларга бик якын күрелмештер[9].

Фин кавемнәренең тереклек рәвеше

Фин ыругыннан тереклек баскычларының һәр каюсында кавемнәр бардыр: вәхшәт хәлендә, ау ауламак, балык тотмак илә тереклек итүчеләре бар – самоед, лаплан кебиләр. Хайван асрамак илә күчмә мәгыйшәть итүчеләре бар – остяклар, камасиннар кебиләр. Искедән авылларда иген игү илә тереклек итүчеләре бар – чирмеш вә чуаш кебиләр. Мәдәният, гыйлем вә мәгариф юлына кермешләре дә бар – эстлар кебиләр.

Мәдәният, гыйлем вә мәгарифтә, һөнәр вә сәнәгатьтә күп тәрәккый итеп, бу көндә руслардан да югары дәрәҗәдә хисап ителмешләре дә бар – Финляндиядәге финнәр кеби. Болар бик искедән һөнәр белмешләрдер. Скандинавия тарихларында финнәр тимерчелек сәнәгате илә мәшһүр. Швеция, Норвегиядә бик иске заманнан бирле фин кылычы мактаулы булмыш. Финляндия финнәре заманнарын вә әйләнәләрен чолгап алган хәлләрен бик вакытлы булмаса да, шулай да булса бик соңга да калмый, танымышлардыр. Куәтле ят кавемнәр арасында зәгыйфь вә заманасына күрә зарур гыйлемнәрдән мәхрүм калган кавемнәрнең азаклары ни булачагына төшенделәр. Форсат качырмый кавемнәрен һәләклектән коткаручы әсбапларга нык ябышмышлардыр. Эчләреннән, фин вә төрек кавемнәре әхвәлен якын тикшереп, күп хакыйкатьләр ачып, үзен бөтен дөньяга тынытмыш Кострин кеби галимнәр дә чыкмыштыр[10].

Фин халкының гореф-гадәт вә холыклары

Фин халкы үз көче вә хезмәте илә тереклек итүне ихтыяр итмештер. Тереклек өчен аз нәрсәгә канәгать итеп, зарур вә хаҗәттән башка һич нәрсәгә күңел куймамышлардыр. Зиннәт, ясалмалылык, олуглану, исраф, әрәм-шәрәм итү кеби эшләр анларның хәтеренә дә килмәмеш. Башкаларның җанын алу кая, йөз суына, малына вә хакына кагылмак та аларда һич булмамыштыр. Угрылык, хыянәт, ялган, золым кеби

---

[8] Фин кавеме хәзерге Русия төньягындагы бик күп җирнең һәм дә Швеция, Норвегия, Даниянең тарихка мәгълүм булган иң иске халыкларыдыр.

[9] Чуаш теле аз гына финләшмеш, йәисә финлеге аз калмыш төрки телдер. Иске рус тарихларында чуашлар татар хисап ителенеп, башка татарлардан аеру өчен, «чуаш-татар» аталмышлардыр. Әмма чуашлар татарларны да чуаш дип атыйлар.

[10] Кострин 1847 елларда Сибириядә фин вә төрек кавемнәре арасында сәяхәт итеп, аларның әхвәлләрен бик якын тикшереп, ул заманга кадәр мәгълүм булмаган күп яңа хакыйкатьләр язды.

Кияүгә чыккан бисермән гүзәле. 1900-1905 еллар

әхлаксызлыкларның ни идекен дә белмәмешләрдер. Бу холык әлеге кавемнәрнең күбесендә, аеруча башка кавемнәр илә катышмаганнарында, хәзерге көннәрдә дә бардыр. Фин халкы үзеннән гайре һичкемгә хуҗа вә боеручы вә башкаларны үзенә хезмәт иттерергә вә буйсындырырга һәвәсле булмамышлардыр. Бу сәбәптән алар эченнән һичвакыт куәтле хакимнәр, үзенә бик күп халыкны буйсындыргучы ханнар чыкмамыштыр. Эчке эшләрендә аңа ихтыяҗлары да булмамыштыр. Бәлки һәр авыл үз картлары илә яхшы киңәшеп башкарылмыштыр. Башкаларның малына вә җирләренә күзләре төшмәмеш вә күңелләре кызыкмамыштыр. Моның өчен алар һичбер кавемгә сугыш ачмамышлар вә һичкемнең өстенә йөрмәмешләрдер. Бәлки үзләре[11] һәр тарафтан кысылмышлардыр: Швеция, Норвегия вә Даниядә яшәүче халыклар, гот, норман, варяглар; Балтыйк көньягынннан славяннар, руслар, немецләр аларның җирләрен алып, араларына кереп урнашканнардыр. Көньяк тарафыннан ыругдашлары төрекләр дә боларга аралашып берләшкәннәрдер. Ләкин болар фин кавеменең кавемиятләрен бөтенләй югалтмый, бәлки алар илә катышып фин кавеменә дә, төрек кавеменә дә нисбәт ителенергә яраклы кавемнәр тугдырмышлардыр.

Фин кавеменең диннәре

Фин ыруглары әүвәлдә һинд дин кадимәләренә охшаш мәҗүси диндә булмышлардыр. Барлык хәердән гыйбарәт бер көч Йаму барлыкны игътикад илә аннан һәр төрле максатларын сорашмышлардыр. Бар яманлыктан гыйбарәт кирәмәт исемендә янә бер көч барлыкны игътикад итеп, аның яманлыгыннан ялварып вә аннан саклануны кирәк күрмешләрдер. Бабаларыбыз булган кама болгарлары күршеләрендә булган мәҗүси кавемнәрне ислам диненә күндерергә тырышсалар да, Аурупа кавеменең (варяг, рус вә славяннарга) бәгъзе гореф вә гадәтләренә вә йә максатларына хилаф булдыгыннан, кабул иттерә алмамышлардыр. Әмма Азия (турани) кавемнәренең табигыятьләренә, гореф вә гадәтләренә ислам дине кадәр уңай дин булмаганлыктан, финнар исламиятне бик җиңел кабул итмәктә иделәр[12]. Ләкин бабаларыбыз болгарилар башына бере артыннан бере – варяг, татар, рус тарафыннан килә торган тормыш афәтләре сәбәбеннән, бу эшләрне ахырына кадәр бардыра алмамышлардыр. Шул сәбәпле финнәр, исламиятне тиешенчә кабул итә алмый, әүвәл аз-азлап мәҗүсиятләренә кайтып, соңрак, руслар яулап алганнан соң, алар христианлыкка дәгъвәт ителенмешләрдер. Һәм алардан күбесе рәсми христиан хисап ителмәктәләрдер. Соңгы заманнарда аларны христианлаштырмак сылтавы илә руслаштырмак максаты өчен, бик олуг иҗтиһад вә чаралар кылынмыш иде[13]. Ләкин, көтелгән кадәр файда ителмәдегеннән, бу чараларны туктатырга карар бирелде. ■

---

[11] Бу язылмышлар фин кавеменә шагыйранә бер мактау түгелдер. Бәлки тарих вә этнография галимнәренең тикшерүеннән вә кайберләре үз тикшерүебездән хасил булган бер хакыйкатьтер.

[12] Болгар әтрафындагы финнарда гарәби «Алла» сүзен әйтмәк, «Бисмилла» димәк, җомга көннәрне бәйрәм итмәк, хәмердән сакланмак, балаларын мөселман исемнәре илә атамак – исламияттән калмак эшләрдер. Төрекчә вә чуашча телләр катыштырып язылмыш кабер ташлары да күптер. Вятка губернасында фин-ар кавеменнән бер таифә «бисермән» исемен бу көндә дә сакламактадыр. Алар үзләрен борынгы болгар халкының калдыгы хисап итәләр.

[13] Бу тәдбирләр күбрәге укыту илә булдыгыннан, әүвәлдә максатларына бик муафыйк нәтиҗәләр тудырыр, ягъни финнәр славянлашырлар иде. Ләкин соңгы заманнарда барча укымакта булганнары арасында миллият, кавемият фикере бик куәтле уйгандыктан, руслаштыру өчен төзелмеш тәдбирләр хилаф нәтиҗә бирмәгә, ягъни руслаштырмак урынына, финнәргә кавемият фикере бирмәгә башламыштыр. Болардан бәгъзеләре, хиссият миллияләрен каумият, миллияттән хәбәрсез булган җенестәшләре илә уртаклашу өчен, үз телләренчә рисаләләр (китап-җыентыклар), хәтта җәридәләр (журналлар) нәшеренә башламышлардыр. Ошбу көннәрдә генә руслаштыру өчен ачылган семинариядән укып чыкмыш бер фин илә әңгәмәбез булып, милли хиснең куәтлелегенә гаҗәп иттем.

Безнең мирас №8 август 2019

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

ЭТРУСКЛАРНЫҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ

Бу халыкның килеп чыгышы турында фәндә төрле фикерләр яши. Шуларның берсен «тарих атасы» исемен алган борынгы грек тарихчысы Геродот язып калдырган. Аның сүзләренчә, этрусклар әүвәл Кече Азиядәге Лидия патшалыгында яшәгәннәр. Ул чакта алар «лидлар» дип аталганнар, чөнки лидларның беренче бабасы Лид атлы булган. Моннан тыш, Лидның Кар һәм Мис исемле туганнары да телгә алына. Кече Азиянең көньяк-көнбатышында борынгы заманнарда Кария һәм Мисия дип аталган дәүләтләр булуын искә төшерсәк (хәзерге Төркия территориясе), бу дәүләтләргә нигез салучылар Кар белән Мис булмадымы икән, дигән сорау да туа. Әмма әлегә Кар белән Мис легендар исемнәр булып кала. Тарихчы Геродот лидлар, карлар һәм мислар бу җирләргә диңгез утрауларыннан күченгәннәр, дип яза.

Италиядә яшәгән борынгы кавемнәр (б.э.к. IV гасыр)

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 7 нче санында.
*Фәнни-популяр тарихи бәян.

Лидларның (ул вакытта алар әле этрусклар дип аталмый) Кече Азиядән күчеп китүләрен Геродот болай аңлата: «Лидиядә Манәй улы Атис патшалык иткәндә унсигез елга сузылган ачлык була, халык ашарга икмәк җитмәүдән бик нык интегә. Баштарак лидлар бу хәлгә түзеп яшиләр, тик ачлык дәвам итә. Ачлыкны онытып тору өчен, алар төрле уеннар уйлап табалар (шахмат уеныннан башка). Тик ачлыктан котылу чарасы һич табылмый. Бу хәлне күреп, Атис патша, халыкны ике өлешкә бүлә дә, жирәбә салганнан соң, аның бер өлешен үз янында калдырырга карар кыла, ә икенче өлеше күчеп китәргә тиеш була. Туган җирдән китәчәк халыкның патшасы итеп улы Тирренны билгели.

Күчеп китүчеләр үзләренә кораблар төзиләр, аңа кирәк-яракны төйиләр дә, яңа җир эзләп, ачык диңгезгә чыгып китәләр. Күп халыклар яшәгән җирләрне узып, алар берзаман Италиягә, умбрлар дип аталган халык яшәгән җиргә килеп чыгалар. Анда алар тора-бара калалар төзиләр һәм бүгенге көнгә хәтле шунда яшиләр. Инде алар элекке кебек лидлар дип аталмыйлар, үзләренә аларны яңа җиргә алып килгән патша улы Тиррен исемен алалар һәм тирреннар булып китәләр».

Тирреннар исемен кабул иткән бу халык Италиянең урта бер җирендәге зур өлкәгә килеп урнаша. Моңарчы анда умбр кабиләләре яши. Күчеп килүчеләр белән җирле умбрлар арасында бәрелешләр булу-булмавы хакында хәбәрләр юк. Шулай да җирле умбрлар килмешәк тирреннарны колач җәеп каршы алмагандыр. Ни генә булмасын, тирреннар анда урнашып кала. Күрәсең, умбрларга Апеннин тауларына таба бераз чигенергә туры килгәндер. Тирреннар килеп урнашкан өлкә хәзерге көндә Тоскана өлкәсе дип атала.

Геродот язганнарга әйләнеп кайтсак, Лидиядә халыкның унсигез ел буе ачлыктан интегеп яшәве, әлбәттә, шик уята. 1921 елдагы корылыкны һәм коточкыч ачлыкны гына искә төшерик. Димәк, ачлык булгач, Лидиядә күп елларга сузылган корылык хөкем сөргән, игеннәр, үләннәр үсмәгән, терлек-туар да ач булган, үрчи алмаган. Геродот бу вакыйганы б.э.к. V гасырда язып алган, ә тирреннар туган җирләреннән б.э.к. X гасырда ук күчеп киткәннәр. Мәшһүр тарихчы бу вакыйганы язып алганчы дүрт-биш гасыр вакыт узган. Шуңа күрә, тирреннарның Кече Азиядән күчеп китеп Италиягә килеп урнашуын кабул иткән хәлдә, без бу хикәяттәге унсигез елга сузылган ачлыкны да, аны онытып тору өчен төрле уеннар оештырылуын да чын дөреслек дип кабул итә алмыйбыз. Өстәп шуны да әйтик: Геродот үзе без югарыда телгә алган Кече Азиядәге Кария дәүләтенең башкаласы Галикарнас шәһәрендә туа. Соңрак ул сәяхәтләре вакытында Италиядә дә була. Б.э.к. VIII гасырда тирреннардан этрускларга әверелгән бу халык чәчәк аткан Этрурия дәүләтендә яши, аның абруе, даны еракларга тарала. Этрускларның Лидиядән күчеп килүе турындагы хикәятне Геродот йә Кече Азиядәге сәяхәтләре вакытында, йә Италиядә яшәгәндә ишеткән булса кирәк.

Галимнәр фикеренчә, этрускларның мәетләр урнаштыра торган курган сыман эче буш түгәрәк таш төрбәләре Кече Азиядәге Лидия белән аның күршесендәге Фригиядә табылган төрбәләргә бик охшаш икән. Этрускларның күп төсләр белән бизәлгән төрбә эчендәге сурәтләре Көнчыгыш илләре сәнгатенә бик якын, аларның храмнарны биек ясалма платформа өстенә төзү гадәте дә шул хакта сөйли (А.М.Кондратов, 5. Интернет).

Әмма Геродот язганнар белән килешмәүчеләр дә бар. Әйтик, шулай ук б.э.к. V гасырда яшәгән, Эгей диңгезенең Лесбос утравында туган грек тарихчысы Гелланик этрускларның килеп чыгышы турында капма-каршы фикердә торган. Аның фикеренчә, Борынгы Эллада (Греция) җирләрендә кайчандыр бик борынгы халык – пеласклар яшәгән. Греклар басып кергәннән соң, пеласклар Элладаны ташлап китәргә мәҗбүр булганнар. Башта алар Фессалиягә күчеп киләләр (борынгы Грециянең төньяк-



Этрускларның Вульчи шәһәрендәге Франсуа исемен йөрткән гаилә төрбәсенең эчке күренеше

көнчыгышындагы өлкә), соңрак греклар аларны аннан да кысрыклап чыгаралар һәм тегеләр, диңгезгә чыгып китеп, Крит һәм башка утрауларга таралалар. Пеласк атлы патшалары җитәкчелегендә, алар Италиягә үк барып чыгалар һәм яңа урында үзләренә яңа исем алалар. Алар шулай үз илләрен Тирсения яисә Тиррения дип атый башлаганнар, имеш. Геродот та хезмәтләренең бер урынында: «Эллада элекке заманда Пеласгия исемен йөрткән», – дип язган.

Гелланик Лесбослы пеласкларның ничек тирреннарга әверелеп китүен «Фавонида» дип аталган хезмәтендә тагын да ачыграк язган: «Тирреннар әүвәл пеласклар дип аталганнар. Пеласк патша белән Пеней кызы Мениппадан уллары Фрастор туган, аннан – Аминтор, Аминтордан – Тевтамид, Тевтамидтан – Нан». Соңгысы хакимлек иткән заманда эллиннар (греклар) тарафыннан торган җирләреннән куып җибәрелгән пеласклар, корабларын җилләр Италиягә китереп җиткергәч, ил эченә тирән үтеп кереп, анда Кортона каласына нигез салалар һәм ул җирләр хәзер Тиррения дип атала (Немировский, 22).

Гелланик Лесбослы, әйткәнебезчә, б.э.к. V гасырда яшәгән һәм аның язганнары пеласклар-тирреннар турында соңрак гасырларда язган грек авторлары мәгълүматларына караганда ышанычлырак дип уйларга кирәк. Шулай итеп, Гелланик Лесбослы пеласклар белән тирреннарны бер үк кавем дип исәпли. Бәлки алар тугандаш халыклар булгандыр, шуңа Италиягә күчеп килеп, тора-бара үзара кушылып киткәннәрдер. Галимнәр пеласкларның теле һинд-аурупа телләре төркеменә кермәве турында да язалар. Димәк, һинд-аурупа телле халык саналган греклар өчен алар бу җирләрдә борын-борыннан яшәп килгән пеласклар бөтенләй ят халык булган, шуңа күрә пеласкларны туган җирләреннән (Борынгы Греция-Пеласгиядән) кысрыклап чыгарганнар, дип уйларга нигез бар.

Аннан соң Гелланик Лесбослының алдарак китерелгән хәбәрендә төрки исемнәрне хәтерләткәннәре дә игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, Пеласкның хатыны Мениппа татардагы ирләр исеме Мөнипне хәтерләтә. Шулай ук Пеней да Пинәй булырга мөмкин. Аминтор исә татарча «имин» һәм «тор» сүзләреннән ясалган исем Иминторны барлыкка китерә. Фрасторга килгәндә, төркиләрдә «ф» хәрефенә башланган сүзләр юк. Булса, алар барысы да алынма сүзләр. Аның каравы, «п»га башланганнары тулып ята. Бу очракта «фрас» – «прәс» булырга мөмкин. Татарлар мәчене «прәс» дип куып

җибәрәләр. Шулай Фрастор – Прәстор була ала. Һәрхәлдә, бу исем төрки сүзләрдән барлыкка килгән дип фараз кыла алабыз. Тагын өзектә «Нан» атлы соңгы патша исеме китерелә. Татарда «наный», «наныем» сүзләре бар. Сүзнең тамыры «нан». Ул кеше исеме булырга да мөмкин. Бәлки Борынгы Греция территориясендә грекларга хәтле төрки кавемнәр яшәгәндер. Соңгы вакытта фәндә Аурупа территориясендә һәм Урта диңгез буйларында арийларга хәтле төркиләр яшәве турында бик дәлилле сүзләр ишетелә башлады. Иберияда (хәзерге Испания) борынгы заманда яшәгән иберларның төркиләр булуы инде исбатланган нәрсә. Грек телендә төрки сүзләрнең байтак булуы да шул хакта сөйли кебек. Ике генә мисал китерәм: грекларның «агора» сүзе халык җыеннары уздырылган мәйданны аңлата. Шул җыеннарда тавыш бирү тәртибе белән идарәчеләр сайлап куелган. «Агора» – төркичә «акыра» сүзеннән барлыкка килгән. Күрәсең, ул заманда «акыру»ның тупас мәгънәсе булмаган, ул бары тик кычкырып тавыш бирүне генә аңлаткан булса кирәк. Шулай «акыру»дан «агора» хасил булган. Икенче мисал: мәшһүр грек шагыйре Гомерның «Одиссея» әсәрендә феак халкының 12 изге басилейны сайлап куюы телгә алына. Һәр басилей кабилә башында торган, ул бер үк вакытта рухи остаз да булган. Без борынгы грек телендәге «басилей» сүзен төркиләрдән кергән дип уйлыйбыз. Сүз «бас» һәм «ил» иҗекләренә бүленә. Хәзер татарда президентны «илбашы» дип атау гадәткә кереп китте. «Басилей» дә шул ук мәгънәне аңлаткан булырга тиеш: «башиле» – «илбашы».



Лемнос утравында кабер өстенә куелган таш такта (стела).

1885 елда француз археологлары Ж.Кузен һәм Ф.Дюрбах Эгей диңгезендәге Лемнос утравында таш стела (тораташ) табалар, анда кулына сөңге тоткан сугышчы һәм ике текст язылган була. Археологлар өчен бу бик кыйммәтле табылдык булып чыга.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Лемнос утравы Эгей диңгезенең төньяк читендә урнашкан, ул Гомерның «Илиада» әсәрендә тасвирланган Труя (Тура) каласы каршында тора. Труя каласы ул дәвердә Троада ярымутравындагы дәүләтнең башкаласы булган. Лемнос утравында табылган ике текст матбугатта басылып чыкканнан соң, этрускларны өйрәнүче галимнәр арасында байтак елларга сузылган бәхәсләр башланып китә. Һәркем таш тактага язылган текстны үзенчә укып, аны иң дөресе дип якларга тырыша. Ялгышлар бик күп була, галимнәр, бер-берсе белән килешмичә, язуларны укуда үз вариантларын тәкъдим итәләр. Тора-бара күп нәрсәләр ачыклана. Лемнос утравында табылган язуларның тиррен халкы язуларына бик якын торуы ачыла. Мәсәлән, немец филологы П.Кречмер Лемнос язуларының этруск язуларына бик якын торуын һәм алар арасында бары тик диалектлар аермасы гына күзәтелүен әйтә.

Лемнос язуларын аңлау мәсьәләсендә иң зур эшне В.Бранденштейн исемле га-

лим башкара. Ул Лемнос һәм этруск телләрен якынлаштыручы берничә пунктны билгеләп үтә: беренчедән, ике телнең дә фонетик яктан бик охшаш булуын; икенчедән, суффиксларның үзара тәңгәллеген һәм аларның сүз ясалышындагы ролен һ.б. үзенчәлекләрне (Нем., 39).

А.И.Немировский, шушы һәм башка тикшеренүләргә нәтиҗә ясап: «Анатолиядә (хәзерге Төркия) табылган борынгы язуларның берсе дә этруск язуына Лемнос язулары кебек якын түгел. Әмма Лемнос һәм этруск язулары бер үк төрле язулар да түгел. <...> Этруск һәм Лемнос язуларындагы аермалар бары тик тиррен телендә сөйләшүчеләр көнчыгыштан көнбатышка таба хәрәкәт иткән очракта гына барлыкка килә алган һәм бу күченеш, башка телләр белән очрашу-кушылу кебек үк, шактый озак дәверләргә сузылган. Шул сәбәпле, Лемнос теле ядкярләре кебек этруск теленә якын торган башка бер язуны табу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. <...>Бу мәсьәләне хәл итү өчен, барыннан да элек, фантазия җимешләре дә урын алган, әмма ышандырырлык фактлары да булган Геродот версиясенә таянырга кирәк», – ди (41-42).

Без инде укучыга Кече Азиядәге Лидия патшалыгы халкының, озакка сузылган ачлык аркасында икегә бүленеп, бер өлеше, күп илләрне, утрауларны әйләнеп узганнан соң, Италиянең уртасына барып урнашуы турында сөйләгән идек. Бу нәкъ Геродот язып алган версиягә туры килә.

Тирреннарның Кече Азиядән (Төркия территориясеннән) көнбатышка таба бәхет эзләп чыгып китүе халык хәтерендә ничек тә булса сакланып калырга тиеш иде. Дөрес, әлегә анда Лемнос һәм этруск язулары белән тугандаш телдәге язулар табылмаган. Бәлки Лидия патшалыгында яшәгән тирреннарның (ул вакытта алар әле лидлар дип аталган) Көнбатыш Анатолиядән күченеп китүен исбатлаучы фактлар бардыр? Әйе, сакланып калган топонимнар шул хакта сөйли икән. Мәсәлән, Лидиядә кайчандыр Торра шәһәре булган. Торраны без Тура булган дип саныйбыз, төркиләр яшәгән төбәкләрдә андый исемле калалар билгеле. Мәсәлән, Себердә Тура каласы булган. Бу атама хәзер дә саклана бугай. Шулай ук лидларда Тарсен-ана исемле алиһә булуы да ачыкланган. Аның барлыкка килүен галимнәр Тарси каласына бәйләп аңлаталар (Нем., 44). Геродот юкка гына Лидия патшалыгыннан халыкның бер өлеше күчеп китүе турында язып калдырмаган. Сәяхәтләре вакытында Кече Азияне дә йөреп чыккан галим шулай ук Көньяк Италиянең Тарент култыгындагы Афина шәһәре греклары нигез салган Фурия каласында да күпмедер яшәгән. Анда да күп мәгълүмат туплаган. Кыскасы, этрусклар тарихы, теле белән шөгыльләнүче галимнәрнең байтагы Геродот версиясен кабул итә.

***

Берничә ел элек миңа телевизордан үземне сискәндереп җибәргән бер хәбәр ишетергә туры килде. Экранда мөлаем йөзле, матур гына ыспай сакаллы, алтын кысалы күзлек кигән бер карт белән журналист әңгәмә корып утыра иде. Мин әңгәмәнең башын күрмәдем, шуңа әле күзлекле картның кем икәнен белмим. Тыңлый торгач, сүз халыкларның борынгы заманнарда кайдан кая күченүе, нинди халыкның генетик яктан нинди халык белән тугандаш булуы турында барганы аңлашылды. Сөйләүче италияле профессор-генетик икән. Аның мине сискәндереп җибәргән сүзләре хәтеремә уелып калды. Ул менә нәрсә диде: «...Мин утыз ел дәвамында Урта диңгез буйларында яшәүче халыкларның 15 мең ДНК үрнәкләрен тикшереп чыктым. Беләсезме, мине бер факт гаҗәпкә калдырды. Кече Азиядәге Лидия дәүләтендә, Эгей диңгезендәге Лемнос утравында һәм Италиянең борынгы заманда этрусклар яшәгән Ветулония каласында яшәгән кешеләрнең ДНКсын тикшереп чыкканнан соң, аларның генетик яктан тугандаш булуын ачыкладым. Мин тарихчы түгел, шулай да бу минем өчен гаҗәеп ачыш булды...»

Соңыннан мин бу картның атаклы генетик Альберто Пьяццо икәнен ачыкладым. Шуннан соң тарихта этрусклар дип аталган халыкның, Кече Азиянең көнбатышыннан күчеп килеп, Италиядә гүзәл мәдәнияткә ия унике кала конфедерациясе төзүенә тәмам ышандым. Күрәсең, пеласкларның, Борынгы Грециядән кысрыклап чыгарылганнан соң, Италиягә килеп урнашуы да хактыр. Тирреннар белән пеласклар, телләре бераз аерылса да, генетик яктан тугандаш халыклар булганнар ләбаса! Шунысы кызык, Лемнос утравындагы пеласклар Труя шәһәренә дә бик якын торганнар. Аларның бер өлеше хәтта Троада ярымутравында яшәгән. Гомер үзенең «Илиада» әсәрендә Трояны греклар һөҗүменнән саклаучылар арасында пеласкларны да искә ала:

«Гиппофоой предводил племена копьеборных пеласков,
Тех, что в Ларисе бугристой, по тучным полям обитали;
Гиппофоой предводил их и Пилей, Ареева отрасль,
Оба сына пеласгийского Лефа, Тевталова сына».

Димәк, Пилей, Арей, Леф, Тевтал, Гиппофоой пеласк исемнәре булган. Аның соңгысы гына грек исеменә охшаш. «Гиппос» грекча «ат» дигәнне аңлата. Икенче юлдагы Лариса (дөресе – Ларисса) шәһәре Фессалиянең башкаласы булган. Борынгы грек тарихчысы һәм географы Страбон да Фессалияне пеласклар ватаны дип атый. Без Фессалиянең Борынгы Грециянең төньяк-көнчыгышында урнашкан дәүләт булуын әйтеп үткән идек. Бу халыкны греклар үз илләреннән кысып чыгаргач, алар Италиягә күчеп килеп, анда Агилла дигән кала төзиләр. Ул соңрак латинча Цере (этрускчасы – Цисра) дип үзгәртелә һәм Этруриядәге 12 шәһәр-дәүләтнең берсе булып китә.

Күрәсең, Борынгы Грециянең төньяк-көнчыгышында яшәгән мөстәкыйль зур өлкә халкы пеласклар греклар белән дустанә мөнәсәбәттә яшәмәгән, шул сәбәпле, алар атаклы Труя сугышы вакытында бу шәһәрне греклар һөҗүменнән сакларга килгәннәр. Бәлки пеласклар соңрак килеп урнашкан труялылар белән тугандаш халык булгандыр, шуңа ярдәмгә килгәннәрдер.

Труя сугышы б.э.к. 1200 елда тәмамлана, ул ун ел дәвам итә. Ул дәвердә, ягъни б.э.к. XII гасырда, пеласклар әле Борынгы Грециядән куылмаган була. Бу хәл соңрак чорга туры килә.

Геродотның тирреннар Кече Азиядән күчеп килгән дигән хәбәре шактый заманнар иң борынгылардан саналып килгән. Әмма тарих фәнендә көтелмәгән ачышлар ясалып тора. Галимнәр, Борынгы Мисырдагы Мәдинәт-Абу храмы диварларына чокып язылган язуларны укып, б.э.к. XIII-XII гасырларда «диңгез халыклары»ның Мисырга яу белән килүе турындагы текстан өр-яңа мәгълүматлар алуга ирешәләр.

Кемнәр булган соң ул Мисырга һөҗүмнәр оештыручы «диңгез халыклары»? Мәдинәт-Абу храмындагы текстта аларның исемнәре дә аталган. Анда лүкү, акайваша, пелешет, шакалуша, шардана һәм турша дигән халыклар телгә алынган. Бу һөҗүмнәр ике фиргавен – Мернептах һәм Рамзес III заманында ике тапкыр ясалган. Мәдинәт-Абу храмындагы текстта аларның исемнәре Мисыр телендә язылган. Галимнәр тарафыннан бу халыкларның сәер исемнәре ачыкланган. Лүкү дигән халык Кече Азиянең яр буендагы Кариядә яшәүчеләр, ягъни карлар икән. Акайвашалар – ахей греклары, пелешетлар – филистимнәр, шакалушалар – Сицилия утравыннан килгән сикеллар, шардана – Сардиния утравыннан килгән сардлар, ә туршалар – шулай ук Кече Азиядәге Лидия дәүләтендә яшәүче лидлар-тирреннар булган. Ул заманда Эгей диңгезе ярларында яшәгән карлар, тирреннар, ахей греклары, диңгез утрауларында яшәүче башка халыклар бик актив тормыш алып барган. Алар оста диңгезчеләр булганнар, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр, җае чыкканда, пиратлык-юлбасарлыктан да баш тартмаган-

нар. Һәркайсы үз көнен үзенчә күргән. Берничәсе, ара-тирә берләшеп, бай Мисырга яу белән дә баргалаган, андагы калаларны талап кайткан. Ә кайвакыт фиргавен гаскәре аларның үзләрен туздырып ташлаган.

Шунысы мөһим: галимнәргә Мисыр язмаларындагы «турша» дигән халыкның ватаны Кече Азиядәге Лидия патшалыгы булуы һәм туршаларның шул ук тирреннар икәне инде билгеле була. Димәк, Геродотның тирреннар турындагы хәбәре дөрес булып чыга.

Бу мәсьәләгә карата күренекле этрусколог В.Бранденштейн да үз фикерен әйтә. Ул, тиррен-туршаларның көнбатыштан килгән «диңгез халкы» булуын тулысынча кире кагып, аларның Кече Азиядәге халык булуын раслый торган дәлилләр китерә: беренчедән, Мәдинәт-Абу храмындагы рельефларда туршалар Кече Азиянең типик халкы буларак сурәтләнгән; икенчедән, хетлар падишаһы Тутхалияша IV текстында «таруиша» исемле халык телгә алына, бу халыкның туршалар булуы ачык күренә, соңгы вакытта аларны Труя халкы белән дә тәңгәл күрәләр (Нем. 33).

Димәк, Геродот язып калдырганча, тирреннар Эгей диңгезе бассейнында күптән яшәгән. Шул сәбәпле, диңгезче греклар аларны яхшы белгән. Грекларның Кече Азия ярларында колонияләре, шәһәрләре дә булган.

Бу очракта тарихчы Дионисий Галикарнаслы фикерен дә әйтеп үтәргә кирәктер. Ул этрусклар тарихы мәсьәләсендә бөтенләй капма-каршы фикердә торган. Бу тарихчы, Геродот кебек үк, Кече Азиядәге Кария дәүләте башкаласы Галикарнас шәһәрендә туа. Б.э.к. I гасырда Римдә яши, анда тарихи хезмәтләр яза. Ул «Борынгы заманда Рим» исемле хезмәтендә Геродот фикеренә кискен каршы чыга: «...лидлар (тирреннар) белән этрусклар арасында бернинди уртаклык юк – алар төрле телдә сөйләшәләр, төрле аллаларга табыналар, гореф-гадәтләре һәм кануннары да башка. Шуңа күрә, минем фикеремчә, этрускларны җирле халык дип санаучылар хаклы, алар беркайдан да күчеп килмәгән, гомер-гомергә шунда яшәгән», – ди (Кондратов, 6. Интернет).

Кыскасы, Дионисий Галикарнаслы якташы Геродотның фикерен кабул итми. Тик шунысын да истә тотарга кирәк – Геродот б.э.к. V гасырда яшәгән, ә Дионисий б.э.к. I гасырда Римдә гомер итә. Әлеге ике галим арасында 400 еллык ара бар. Бу – бик күп вакыт. Дүрт гасыр арасында Кече Азиянең көнбатышындагы Ликия, Кария, Лидия, Мисия дәүләтләрен Рим империясе яулап ала, алар Римнең «Азия» дип аталган провинциясенә әверелә. Тарихчы Дионисий, Кече Азиядәге Галикарнас шәһәрендә туса да, карьера ясау өчен империя башкаласы Римгә барып урнаша, латин телен тырышып өйрәнә. Халыкара телгә әйләнгән латин телендә «Борынгы заманда Рим» исемле һәм башка хезмәтләрен яза. Ул вакытта Рим инде Этрурияне дә күптән яулап алган, бу халык дәүләт теленә әверелгән латин теле йогынтысында ассимиляцияләнгән була. Этрусклар шулай Рим гражданнарына әверелә. Шул сәбәпле, Дионисий Галикарнаслының Геродотка каршы чыгуы бик табигый, бу сәяси яктан да файдалы булгандыр. Ник дигәндә, Рим яулап алган халыклардан латинлашкан империя халкы ясау өчен күп көч куя. XX гасырда СССРда «совет халкы» ясарга тырышуны гына искә төшерик. Империяләр һәрвакыт халыкларның үз йөзен бетерергә, унификацияләргә омтылалар. Шуңа күрә, Геродот язганнар дөреслеккә туры килә дип уйларга нигез бар. ■

Безнең мирас №8 август 2019

ТАССР

Большевизм уты астына

Кави Нәҗми

Мәкалә авторы Кави Нәҗми әдипләр Шәриф Камал, Һади Такташ, Нигъмәт Хәким, Фатих Сәйфи-Казанлы, Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш һ.б. арасында. 1926 ел

«Җидегәнчеләр» эше турында «Татар энциклопедиясе» (2 том, 269 бит) мондый мәгълүмат бирә: «1920 нче еллар ахырында, бер төркем татар-башкорт язучыларын контрреволюцион эшчәнлектә гаепләп, махсус оештырылган җинаять эше. Оешма Г.Кутуй белән Г.Минский 1929 елда Уфага баргач оештырыла, аның җитәкчеләре Г.Кутуй белән Н.Исәнбәт булган, дип исәпләнә. Әлеге эш буенча С.Агиш, С.Борһан, Н.Исәнбәт, Г.Кутуй, Г.Минский, Т.Ченәкәй җавапка тартыла. Ул чордагы көндәлек басмаларда шулай ук Ф.Бурнаш, Н.Гальгаф, М.Бөдәйли, Г.Рәхим, З.Галим исемнәре дә күрсәтелә. Тикшерү 1929-1930 ел-



Brləşegez, bɵten dɵnja eşceləre!

Ataka

№4-5.

Ridkolligiə: Qəvi Nəçmi, Ƣɵmər Ƣəli, Ƣəziz Idlle.

Tatarstan Prolitariat Jazucьlarь Asatsiatsiasь organь; ajƣa ike cƣja torƣan, ədəʙiat, sənƣət həm tənqit zurnalь

QƏVI NƏÇMI

BOL'ŞIVIZM UTЬ ASTЬNA

1. Kɵrəş kiskьnnəşte.

Tatar ʙurzuaziəseneꞑ ədəʙiat frontndaƣь agintlarnnan taƣьn ʙer tɵrkemeꞑ ut astьna eləkte. Bu tɵrkmgə həm anьꞑ tirəsenə doşman sьjnfьnьꞑ kypme kɵce tuplanƣandьr—anьsь nqlь tikşerylərdən soꞑ ƣna ʙilgele ʙulьr. Hər xəldə, prolitariat diktaturasь şartlarnda jəşren ojşma tɵzy kʙek səjasi çinajətkə qiulьƣь çitkən „Çidegəncelər" sanьnьꞑ çidəy ʙlən gnə ciklənye ʙik şikle. Çidegəncelərneꞑ yz ara jazşqan xatlarь da, „Çidegən" programmasь ʙujnca eşləgən ziannarь da, „Çidegən" ne tudьrşqan həm şunьꞑ tuuьna, jəşəyenə mɵmkinnək ʙirgən ʙarlьq faktrlar da ʙu şiklənyneꞑ urnnь ikənnegen kyrsətələr.

Syzne faktrlardan ʙaşlьjq:

Prolitariat rivolytsiəse—ʙurzua sьjnfьn (şul çɵmlədən tatar ʙurzuaziəsen) səjasət həm xuçalьq ɵlkəsndəge urnnnan qolaq qaqtьrьp ƣna qalmadь, ʙəlki anь kul'tura ɵlkəsnnən, mətʙuƣat-ədəʙiat, tiatьr tarmaqlarnnan da sɵrep cƣaru carasьn kyrde. Bu juldaƣь kisken kɵrəş əlʙəttə ʙər-ike jьl ecndə gnə tnmadь. Ul ʙygnge kɵndə də tge jaki ʙu tɵstə yzen kyrsətep, qajʙer caqlarnda ytə kiskьnnek ʙlən ɵskə qalqьp kilə.

„Bzdə ƣomumən sьjnfi kərəş tuqtalmaƣan şiklle, ul ədəʙi frontta da tuqtalmьj. Matur sənƣətneꞑ, şunьꞑ ecndə ədəʙiatnьꞑ sьjnfi tɵse səjasəttəgegə qaraƣanda kyʙerək formalarda kilep cƣa". (Partiə Yzək Komititьnьn matur ədəʙiat turndaƣь rizolutsiəsnən).

Iptəş Kaganovic ta partiəneꞑ XVI ncь sjьznda tyʙəndəgene əjtep uzdь:

„Ədəʙiat szьƣь ʙujnca, ʙigrək tə milli çɵmhyriətlərdə, sьjnfi kɵrəş kiskьnnəşte, ʙu frontta ajruca ujaulьq kirək".

2. Tarixnь aqtarьp qarasaꞑ

Soꞑƣь 10-12 jьl ecndə cqqan tatarca gəzit-zurnal ʙitləren aqtarьp qarasaƣьz da, ədəʙiat frontndaƣь sьjnfi kɵrəşneꞑ kyp misallarьn kyrrsez. Mnə szneꞑ aldьƣzda ʙajtaq ƣna sannь mistik-romantik şaƣirlər: Burnaş, Isənʙət, Syncələj, Dumaui, Cnəkəj, Ƣaʙidof, Bajcurina, Əʙrar Səƣdi həm ʙaşqalar. Səydəgərlər simiəsndəge mişcən santimintal'ьƣьn idiallaştrucь Fatix Əmirxan, Ƣəli Rəxim, Ƣəziz Ƣɵʙəjdullin, Sadrьj Çəlal kʙek jazucьlar. Bolarnьꞑ zur kypcelege yzləreneꞑ tɵp içatlarь ʙlən ʙornƣьlqnь, Ƣəjaz Isxaqflar corьn, ʙurzua ədəʙiatьnьꞑ „parlaq" zamannarьn kire qajtarrƣa caqrdьlar. Eşcelər həm xzmət iəse krəstiənnər qatlauьnnan cqqan jazucьlarnьꞑ, şaƣirlərneꞑ ʙrnce sulularnnan uq alarnьꞑ tɵslərе kitte, ʙurzua ədəʙiatьna tamьr çəjərlek tufraq qalmauьn kyrep tɵn joqьlarь qactь. Alararasnnan qajʙrləre—prolitariat ədəʙiatьn ʙuu, ʙurzua ədəʙi atьnьꞑ gigi-

КУЛЬЯЗМАЛАР ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ

«Атака» журналының «Большевизм уты астына» мәкаләсе басылган бите. 1930 ел

ларда бара: җинаятьләре исбатланмау сәбәпле, гаепләнүчеләр аклана һәм сак астыннан азат ителә. Шуңа да карамастан, алар үз вазифаларыннан читләштерелә һәм матбугатта нык тәнкыйтькә дучар ителә».

Хөрмәтле укучылар! «Безнең мирас» журналы сезнең игътибарга дәһшәтле утызынчы елларның тәүге «хәбәрчесе» булган мәкаләләрнең берсен тәкъдим итә. Ул тәүге мәртәбә «Атака» журналында (№ 4-5, 1930 ел) басылган. Бу язма аша без тагын бер кат: ул чорлар фаҗигасе халкыбызга, бигрәк тә аның зыялы дип атаган катлавына, гыйбрәт булсын иде, дип искәртәбез.

Редакция

1. Көрәш кискенләште

Татар буржуазиясенең әдәбият фронтындагы агентларыннан тагын бер төркеме ут астына эләкте. Бу төркемгә һәм аның тирәсенә дошман сыйнфының күпме көче туплангандыр – анысы ныклы тикшерүләрдән соң гына билгеле булыр. Һәрхәлдә, пролетариат диктатурасы шартларында яшерен оешма төзү кебек сәяси җинаятькә кыюлыгы җиткән «җидегәнчеләр» санының җидәү белән генә чикләнүе бик шикле. «Җидегәнчеләр»нең үзара язышкан хатлары да, «Җидегән» программасы буенча эшләгән зыяннары да, «Җидегән»не тудырышкан һәм шуның тууына, яшәвенә мөмкинлек биргән барлык фактлар да бу шикләнүнең урынлы икәнлеген күрсәтәләр.

Сүзне фактлардан башлыйк.

Пролетариат революциясе – буржуа сыйныфын (шул җөмләдән татар буржуазиясен) сәясәт һәм хуҗалык өлкәсендәге урыныннан колак кактырып кына калмады, бәлки аны культура өлкәсеннән, матбугат-әдәбият, театр тармакларыннан да сөреп чыгару чарасын күрде. Бу юлдагы кискен көрәш, әлбәттә, бер-ике ел эчендә генә тынмады. Ул бүгенге көндә дә теге яки бу төстә үзен күрсәтеп, кайбер чакларында үтә кискенлек белән өскә калкып килә.

«Бездә, гомумән, сыйнфый көрәш тукталмаган шикелле, ул әдәби фронтта да тукталмый. Матур сәнгатьнең, шуның эчендә әдәбиятның сыйнфый төсе сәясәттәгегә караганда күбрәк формаларда килеп чыга». (Партия Үзәк Комитетының матур әдәбият турындагы резолюциясеннән.)

Иптәш Каганович та партиянең XVI съездында түбәндәгене әйтеп узды: «Әдәбият сызыгы буенча, бигрәк тә милли җөмһүриятләрдә, сыйнфый көрәш кискенләште, бу фронтта аеруча уяулык кирәк».

2. Тарихны актарып карасаң

Соңгы 10-12 ел эчендә чыккан татарча гәзит-журнал битләрен актарып карасагыз да, әдәбият фронтындагы сыйнфый көрәшнең күп мисалларын күрерсез. Менә сезнең алдыгызда байтак кына санлы мистик-романтик шагыйрьләр: Бурнаш, Исәнбәт, Сүнчәләй, Думави, Ченәкәй, Габидов, Байчурина, Әбрар Сәгъди һәм башкалар. Сәүдәгәрләр семьясындагы мещан сентиментальлеген идеаллаштыручы Фатих Әмирхан, Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин, Садри Җәләл кебек язучылар. Боларның зур күпчелеге үзләренең төп иҗатлары белән борынгылыкны, Гаяз Исхаковлар чорын, буржуа әдәбиятының «парлак» заманнарын кире кайтарырга чакырдылар. Эшчеләр һәм хезмәт иясе керәстияннәр катлавыннан чыккан язучыларның, шагыйрьләрнең беренче сулуларыннан ук аларның төсләре китте, буржуа әдәбиятына тамыр җәярлек туфрак калмавын күреп, төн йокылары качты. Алар арасыннан кайберләре, пролетариат әдәбиятын буу, буржуа әдәбиятының гегемонлыгын саклау юлында фикерләрен берләштереп, төрле чаралардан файдаланырга керештеләр. Алыгыз шул ук Сүнчәләйнең чыгышларын. Моннан

берничә еллар элек ул «Башкортстан» гәзитендәге мәкаләсендә Октябрьдән соң яза башлаган шагыйрьләрнең әсәрләренә, яңа кадр каләм көчләрен тәрбияләүче «Эшче» гәзитенә иң әрсез кыюлык белән һөҗүм ясый.

Сулдан уңга: Габдрахман Минский, Һади Такташ (өстә), Гадел Кутуй. Такташ белән Кутуйның дуслыгы «Җидегән» яласыннан соң мәңгегә өзелә. 1920 нче еллар

3. Аларның байрагы

Шуңар тел белгечләреннән Җамал Вәлиди чыгышларын өстәгез. 1922 елны ул Гаяз Исхаковның Советлар властена каршы иң актив көрәш алып баруын белгән хәлдә, андый дошманнарны яклап чыгуның сәяси җинаять икәнен бик яхшы аңлаган хәлдә, һичбер тартынмыйча, Гаяз әсәрләрен «современный» дип төсмерли. Аларны татар әдәбиятының «хәят-мамат» төеннәренә әйләндерә. 1923 елда урыс телендә басылган бер китабында шул ук зарарлы карашын аеруча күтәренке тавыш белән яклап чыга. 1928-1929 елларда үзенең «тулы сүзлеге»н төзегәндә, Гаязны популярлаштыру өчен, татар телендәге һәрбер сүздән файдаланырга тырыша. Татар ак эмигрантларының җитәкчесе булган Исхаков турында матбугат-әдәбият аркылы яхшы фикер тудырырга маташу хезмәтен Җамал Вәлиди генә башкарды, дип әйтсәк ялгыш булыр. Җамал ялгыз калмады. Аңар, бер яктан, Галимҗан Шәрәф, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхимнәр – үзләренең Гаяз Исхаков әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә итүләре, иттерүләре белән, югары уку йортларының дәрес программаларына Гаязны кертү өчен көрәшүләре белән ярдәмгә килделәр. Икенче яктан, Садри Җәләл, Нәкый Исәнбәт, Кутуйлар 1927-1929 еллардагы чыгышлары белән үзләренең Гаязчы икәнлекләрен аермачык әйтеп салдылар.

Нәкый әйтмешли: «Татарга татарча яза белүче Гаяз Исхаков».

Кутуй әйтмешли: «Татар әдәбиятында Гаяз Исхаков әсәрләре кебек классик әсәрләр бөртекләп кенә санала».

Садри әйтмешли: «Татар әдәбиятын баету юлындагы иң уңышлы хезмәтләр Гаяз өлешенә төшә».

Бу фактларны бер җепкә тезсәң, нинди нәтиҗә чыгачагы үзеннән-үзе билгеле: болар барысы да пролетариат әдәбиятына каршы көрәштә иң явыз дошманнарыбыздан Гаяз Исхаковны байрак итеп күтәрделәр. Шул черек байрак астына барлык кара көчләрне, пычрак элементларны, буржуа язучыларын туплап, үзләренең сәяси теләкләренә ирешергә омтылдылар. Кайчандыр Гаяз Исхаков: «Бу бүленү, төрләләнү төрек-татар кавемен дәрәҗәсеннән төшертә, әдәбиятыбыз-матбугатыбызның таянчык куәтен кечерәйтә», – дип язган иде (Истанбулда басылган «Әсирлек юлдашы» исемле җыентык, Гаяз мәкаләсе).

Югарыда саналган көчләр, бу мәкаләдә күрсәтелгән милләтчеләр бердәмлеген ныгыту өчен, шул җөмләдән үзләре дә татар буржуазиясенең матбугат-әдәбият

өлкәсендәге таянчык куәтләре булып берләшү өчен, Гаяз әсәрләренә тотындылар. Татар контрларының идеологы булган Гаяз тирәсендә җәмәгать фикерен туплап маташуларына башкача һичбер нинди мәгънә биреп булмый. Шулай булгач, бу фактларның «Җидегән»нең төзелүенә, аның яшәвенә кирәкле оеткы булганлыгы ачык мәгълүм түгелмени? Шулай булгач, «җидегәнчеләр» шундый «таянчык куәт»ләрнең барлыгын сизү, күрү аркасында гына үзләренең яшерен оешмаларын төзи алганнар, дип әйтү – дөрес түгелмени?

Татар пролетариат әдәбиятына каршы көрәшү, пролетариат язучыларына, шагыйрьләренә, тәнкыйтьчеләренә каршы бөтен чараларны кулланып аяк чалу, матур әдәбиятны партия җитәкчелегеннән «азат итәргә» чакыру кебек пунктларны үз программасына керткән «Җидегән» оешмасының Гаяз әсәрләренә таяначагы билгеле түгелмени?

Болар барысы да ачык, дөрес, билгеле.

4. Әзер сукмак буйлап

Шулай ук Сүнчәләй, Бурнаш, Гальгаф, Бөдәйли, Агиев һәм Гайнан Хәйриләрнең пролетариат әдәбиятына каршы чыгышлары да – «Җидегән»не тудыручы шартлар рәтенә керәләр. «Җидегәнчеләр» аларның тәҗрибәләреннән нык кына файдаланалар. Алар тарафыннан салынган әзер сукмакны – буржуа әдәбиятына илтүче сукмакны үзләренә олы юл итеп алганнар. Шулай булгач, «Җидегән»не төзүчеләр үзләренең яшерен эшләрендә шушындый көчләргә таяначакларын искә алмаганнардыр дип кем әйтер? Алар үзләренең программаларын шушы төркемнең әдәбият тармагындагы чыгышларыннан үрнәк алып төземәгәннәрдер дип кем шикләнер? Алар үз оешмаларын кайсы катлау исәбенә үстерү мәсьәләсен куйганда, солтангалиевче шагыйрьләрне, совет җәмәгатьчелегенә дошман булган «Үсү» кебек яшерен оешма членнарын, чыкылдап торган Гаяз Исхаковчылар кадрын онытканнардыр дип кем уйлар?

5. «Җидегән»нең театрга йогынтысы

Пролетариат әдәбиятына каршы чыгышлар болар белән генә чикләнмиләр.

Без монда аерым тикшерүне сорый торган моментлардан татар театрына бәйләнешле кара тапларга (театр забастовкасы, пролетариат язучыларының әсәрләрен репертуарга керттермәү, кергәннәрен кысрыклап чыгару кебек хәлләргә), «Яңалиф» нәшрияты тирәсендә оешкан «кадр»лар мәсьәләсенә кыска гына тукталып узабыз.

«Большой театрны бирмәсәгез, спектакльләргә катнашмыйбыз» сылтавы белән Кутуй тарафыннан оештырылган артистлар забастовкасына, Г.Ильясның «Вахта»сын уйнаттырмау кебек хәлгә, Риза Ишморатның «Данлы чор»ы белән Шәриф Камалның «Ут» исемле пьесаларына каршы юнәлгән һөҗүмнәргә, әлбәттә, очраклы бер хәл дип кенә карау ярамый. Шулай булгач, бу чыгышларга «җидегәнчеләр»не пролетариат әдәбиятына каршы ничек итеп көрәшергә өйрәткән сабакларның бер төре дип исем бирү дөрес түгелмени?

6. «Классиклык» ширмасы артында

«Яңалиф» нәшрияты, 1927-1929 елларда пролетариат язучыларының төп кадрыннан (ТАПП, МАПП, БАПП, Урал АППларга оешкан иптәшләрдән) тулысынча файдалану урынына, Камил Мотыйгый, Сәгыйть Сүнчәләй, Әсгать Айдар, Исәнбәт, Ченәкәй, Җәләл, Фатих Кәрими, Әбрар Сәгъдиләрне төп әдәби кадр итеп ала. Классикларны ничек һәм нинди сүз башлары белән бастыру мәсьәләсендә нык сыйнфый юл тоту урынына, уң оппортунистлык күрсәтә, буржуа язучыларының сәяси характеристика-

Сулдан уңга: Сәйфи Кудаш, үзбәк язучысы Гафур Голәм, Хәсән Туфан, Сәгыйть Агиш. 1965 ел

ларын, кайберләренең Советка ачыктан-ачык каршы чыгышларын томалап калу кебек сызыкка баса. Бу күренеш объектив яктан «җидегәнчеләр»нең эшләренә, аларның пролетариат әдәбиятына каршы көрәш өчен дәртләнүләренә су кою түгелмени?

Әдәбият өлкәбездәге шушындый чирле күренешләрнең, сәяси ялгышларның «җидегәнчеләр»гә азык биргәнлеге күренеп тормыймыни?!.

7. Безнең кимчелекләребез, ялгышларыбыз

Татарстандагы, Башкортстандагы, Мәскәүдәге татар һәм башкорт пролетариат язучыларының оешмалары эчендә сыйнфый уяулыкның җитәрлек дәрәҗәдә нык булмавы, үз кимчелекләребезгә каршы большевикларча тәнкыйтьнең начар оештырылуы, әдәби оешмаларда членнарның сәяси йөзләрен ныклап тикшермәү, пролетариат арасыннан әдәби кадрлар җитештермәүнең чамадан тыш йомшак булуы, матур әдәбият өлкәсендә эшләүче коммунист көчләрне берләштерү мәсьәләсендә реаль чаралар күрелмәве, хәтта шул берләшүне кыенлаштыра торган группачылык чыгышларына җимергеч отпор бирелмәве аркасында, дошман элементлар иркен сулыш алдылар. Шулай булгач, менә шундый кимчелекләребездән, ялгышларыбыздан «җидегәнчеләр»нең бик киң файдаланулары турында ике фикер булу мөмкинме? Әлбәттә, юк.

8. Казан белән Уфа богемачылары

Пролетариат диктатурасы урнаштырган тәртипләрне бозып, яшерен оешма төзү кебек зур сәяси җинаять эшләүчеләр күбесенчә богема, фәхеш оешмалары белән нык бәйләнештә булалар. Моның мисаллары байтак. Менә – Уфа богемачылыгында авызлыкланып, бер яктан өй тормышында совет этикасына бөтенләй зарарлы чыгышларга, икенче яктан «Үсү» оешмасы төзүгә хәтле барып җиткән Гайнан Хәйринең үзе турында язган сүзләре: «Әйләнәсенә без утырган мәрмәр өстәл янына ике шешә сыра килеп утырды. Йоттык. Музыкантлар уйныйлар. Нindидер украинча киенгән биш кыз баткакка каткан идәнле зал эчендә орчыклана» («Безнең юл» журналы, 1927 ел).

Уфа шагыйрьләреннән Ченәкәй, Агиш, Карнайларның Минскийга язган хатлары шуны ук кабатлыйлар. «Синең хатыңны ачканда бүлмәмдә бер Әминә, бер Җәмал, бер Маһирә бар иде». «Бүген баш авырта. Кичәге эчүләрнең газабын күрәм. Кесәдә бер тиен дә акча калмаган». «Әллә нәрсәләрне уйлап йөрәк шундый яна. Пиво гына аны баса алмый. Кырык градус кирәк була». «Кичә генә Батыр дигән бер егет белән «Башпром» пивноенда утырып, талашып чыккач, бүген баш авырта».

Шуннан Уфадагы кызларны ничек итеп кулга төшерү юлларын өйрәткән пычрак сүзләр төркеме тезелә. Һәрбер хаттан очсыз-кырыйсыз порнография сөреме саркый.

1923-1924 елларда Казан богемачыларының «Өйләнмәүчеләр, кияүгә бармаучылар» исемле яшерен оешмасын төзүчеләрдән берсе булган Кутуйга да, Әсгать Айдар, Камал Зәлиләрнең «төнге рәхәтләр»енә компаньон булган Минскийга да Уфа каласында яңа дуслар, бергәләп типтерүчеләр, алданучы кызлар табыла.

Димәк, кешелек йөзен югалткан, таркалган, үзенең сатлык вөҗданын аракы парлары белән сылап тынычлатырга өйрәнгән элементлар бер-берсен шундый фәхеш оясында, эчемлекле өстәлләр артында очратканнар. Ченәкәй теле белән әйтсәк, «Планнар, юллар, юллыклар, куллыклар» мәсьәләсен шушында тикшергәннәр.

Шулай булгач, Казан белән Уфада тамыр җәйгән богема оялары буржуа әдәбиятының таркау көчләрен туплауга актив булышлык иткәннәр, «җидегәнчеләр»нең кендек аналары шунда табылган дип әйтсәк, һич кенә дә ялгышмабыз.

9. Хәзерләнәләр

Инде «Җидегән»нең үзен актарып карыйк.

Ченәкәйнең «Башкортстан» гәзитендәге (13 август номеры) хаты буенча «Җидегән»нең 1928 ел, җәй уртасында, Уфа каласында төзелгәнлеге беленде. Бусы аның «азан әйтелеп, исем кушылган» чагы булгандыр. Югыйсә, яшерен оешма төзү хәзерлеге элегрәк (гыйнвар аенда ук) башланганга охшый. Минскийга килгән хатларның байтагы шундый хәзерлек барганлыгын аермачык раслап торалар. Уфага барырга җыенган Кутуй белән Минскийны Уфа тормышы, халкының төрле катлавындагы настроение, яшерен оешмага тартырлык көчләрнең характеристикалары белән таныштыру хезмәтен Ченәкәй башкара. Менә аның хәзерлек чорындагы хатларыннан кайбер өземтәләр: «Безнең бер «Шыр тилеләр түгәрәге» бар: Сәгыйть Агиш, Ислам (фелдьшер), Галәви, Ченәкәй». «Нәкыйнең «Культур Шәнгәрәй» дигән пьесасы бар. Мин аны Казан репертуарына бирергә димлим. Шәп нәрсә». «Менә мин нәкъ 31 кеше белән хат язышам. Уйлап кара, берәр хаттан да айга 31 хат язарга кирәк». «Гыйнвар аенда Нәкый Исәнбәт белән Мәскәүгә барырга уйлап торабыз». «Димәк, минем хат сиңа тапшырылмаган. Башка берәүгә очраган була. Әгәр шулай булган булса, бик күңелсез һәм үкенечле хәл. Мин ул хатка ниләр генә язмадым». «Син бу хатны алу белән ул хатны эзләргә кереш. Техникумдагы берәр дус-дошманың кулындадыр. Почмак саен сүз йөрткечләр куеп булса да, аны табарга тырыш». «Әдәби түгәрәгебезнең эшлекле

кисәкләреннән өч фамилияле А.Гали (Галәви-Галиев) Казанга китте. Син теге югалган хатны тапмадыңмы? Тыңлап йөр. Син Галәви белән кат-кат очрашып, озак-озак сөйләш». «Кайчан Уфага киләсез? Көтәбез. Планнар. Юллар. Юллыклар. Куллыклар».

Бу хатлар – Чинәкәйнең яшерен оешмада кирәкле член булырлык теләге, «ымлашып» хат язу осталыгына өйрәнеп җиткәнлеген ачып бирәләр.

10. Татар милләтчеләренә сәҗдә итүчеләр

Башкорт шагыйрьләреннән дә кайберләренең татар милләтчеләре йогынтысына чумганлыкларын, татар милләтчеләренә тәлинкә тоту кебек түбәнлеккә төшкәнлекләрен түбәндәге хатлар һичбер шәрехсез-нисез аңлатып торалар.

Менә С.Агиш хатларыннан берничә юл: «Гайнанның шигырьләр мәҗмугасе, күп ялганлаша торгач, татар телендә чыга. Минем дә бер шигырьләр җыентыгы чыгар чыгуын, ләкин башкорт телендә бастырырга туры килер. Башкортча бастырмасаң яхшырак булыр иде дә, бик шәп бер пәлтә кирәк булганлыктан гына быел шулай эшләргә туры килә». «Быел бәлки «Безнең көлү», «Күләгә» исемле җыентыкларымны бастыра алырмын. Ләкин алар башкорт телендә булырлар инде. Мин аны теләмим дә, хотя». «Чинәкәй Казанга барам дип сөйләнгән иде. Бара бугай. Ул сиңа тулы мәгълүмат бирер. Дус булырга әйбәт кеше». «Чинәкәйнең «Киләләр!» дигән сөенеч хәбәре буенча көтәбез. Чинәкәйдән Казан-Мәскәү турында доклад сөйләттек. Ул синең хакта матур гына тукталды». «Мортазинны Казанга озатабыз. Серләреңне бу кеше алдында һичбер чигенмичә сөйли аласың. Кыскасы, ул – безнең кеше». «Гомумән, соңгы вакытта Казан хакында кызык кына уй керә башлады. Теге Маннур дигәнегезне боздыгыз. «Кызыл яшьләр»дә Нәкый Исәнбәтне сүгеп үзегезчә нинди мөгез чыгарган булдыгыз инде? Янәсе, сез Галимҗан яклы кеше дә, шуның өчен Нәкыйне сүгәргә кирәкмени?»

Шушындый хатлар алышу нәтиҗәсендә «Җидегән»не төзеп җибәргәч, Кутуй белән Минскийларның да Нәкый турындагы фикерләре кинәт үзгәрә. Яшерен оешма дисциплинасы буенча үзгәргән мондый карашларның, бер-берсен «илаһи уптым» якларга керешүләренең мисалларын без бу мәкаләнең актыгында санап узарбыз. Хәзергә «Җидегән»не төзү алдындагы настроениеләрнең хәлен күрсәткән тагын берничә хат белән танышып үтик.

Менә Амантай хатлары: «Яшь юксыл» бит Башкортстан гәзите түгел. Чит губерналардан язмалар булганда мин «Яшь юксыл»ны бөтенләй Башкортстан хәбәрчеләреннән коткарырга хәзермен. Җибәргән әйберләреңнең барысын да токтарсыз басарга тырышырмын».

Менә Али Карнай хаты: «Уфаның үзенә күрә ташка үлчим шагыйрьләре, язучылары, тәнкыйтьчеләре бар. Менә шул халык, төрле группаларга бүленеп, төрле юллар белән, бер-берсен батырырга тырышып йөриләр».

Яшьләр матбугатының башында торуыннан файдаланып, Башкортстандагы эшче-керәстиян хәбәрчеләрен читкә тибәрә алуы белән масаючы Амантайлар, группа көрәшләре аркасында яшерен оешмага көч җыйнарлык уңайлы шарт туганлыгын хәбәр итеп торучы Карнайлар тагын байтак кына хәлләр турында Кутуйларга сигнал бирәләр. Совет матбугатында эшләү белән һичбер ничек бергә җыела алмый торган бу хатлар пролетариат әдәбиятына дошман элементларның яшерен оешма төзү дәртләрен тагын да ныгыталар, Уфага җыелып шул турыда сүз беркетү теләкләрен канатландыралар.

*Басмага **Миләүшә Талипова** әзерләде.*

Ахыры киләсе санда ■

ТАССР

Агымсуларны эшкә җигәсе бар

Фәрит Хатипов

Әле кайчан гына, күп дигәндә бер-ике гасыр булыр, адәм баласы электрның ни икәнен дә белмәгән. Патша, корольләр дә шәм яктысы белән канәгатьләнергә мәҗбүр булган. Авылларда, шәм булмаган җирдә, аны чыра алыштырган. Тора-бара мәгыйшәткә кәрәчин лампасы килеп керде. Җитешле кеше өендә ул – якты, фәкыйрьнекендә сүрәнрәк яна иде.

Хәзер исә хәятне электр энергиясеннән башка күз алдына да китереп булмый. Аны файдалану даирәсе көннән-көн арта бара. Ул азга гына сүнеп торса да, зур кыенлыклар килеп чыга. Ихтыяҗ арта, бәясе күтәрелә бирә.

Сугышка кадәр Татарстанда башлыча җылылык электр станцияләре корыла. Аннан соңгы елларда зур гидроэлектростанцияләр алгы планга чыга. 1955 елда Куйбышев электр станциясе сафка баса. 1979 елда Түбән Кама ГЭСының 1 нче, 2 нче агрегатлары файдалануга тапшырыла. 16 гидроагрегат елына 1,3-2 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе бирә.

Матбугатта игълан ителгән мәгълүматларга караганда, Куйбышев ГЭСы су өслегенең мәйданы 6,15 мең квадрат километр тәшкил итә, ул – Аурупада иң зур сусаклагыч. Түбән Кама буасының мәйданы 1084 квадрат километр килеп чыга. Ошбу территориягә Андорра, Лихтенштейн, Люксембург, Мальта, Сан-Марино, Бәхрәйн, Мальдива, Сингапур, Гонконг, Бермуд утраулары, Виргини утраулары (Британия), Биргини утраулары (АКШ) – 12 дәүләт иркен кереп утыра ала. Әле аннан соң да 473 квадрат километр мәйдан артып кала. Кайбер урыннарда диңгезнең киңлеге 30 чакрымга сузыла, бер ярдан икенчесе күренми, су офык белән тоташа. Шул төбәктәге уңдырышлы басу-болыннар, урман-куаклыклар, зиратлар су астында калды, йортлар, каралтылар күчерелде. «Авыллары су астында калгач...» шигырендә Равил Фәйзуллин болай дип язган иде:

«Акчарлак!
Бәргәләнмә ул дулкында!
Әти чардуганы өстендә!..»

Куйбышев плотинасы янындагы суның тирәнлеге – 41 метр, Түбән Кама сусаклагычында 1978-81 елларда су 62 метрга кадәр күтәрелде. Әйтергә кирәк, тигез җирдә елганы күтәрү, җирне кадерсезләү, исраф итү дөнья халыкларында хупланмый, бу гамәл итәк кисеп җиң ямау кебегрәк карала. Франсуа Рабле, мәсәлән, «Гаргантюа һәм Пантагрюэль» романында бер инсанның, урман кисеп, юан агачларны яндырып, шуның көлен сату хисабына көн күрүеннән көлә. Урман-кырларны юк итү хисабына электр энергиясе җитештерү дә шундыйрак хәлне хәтерләтә. Мәгълүм булганча, кайбер мәмләкәтләрдә, киресенчә, җирне диңгез һәм океаннардан тартып алу чарасын күрәләр.

Э.Хакимов фотосы

Хикмәт җирдә генә дә түгел. Әле әйтеп киткән зур масштаблы югалтулар, фаҗига кешеләр күңеленә тирән яра сала.

Шул ук вакытта чамадан тыш куәтле станцияләргә генә йөз тоту, гигантомания, зурдан кубу кәсәфәте асылда ГЭСлар төзүне бөтенләй туктатуга китерде, дип әйтергә була.

Бүтән җирдә ничектер, безнең Пучы якларында агым көче башлыча тегермән төзүдә кулланылды. Тегермәннәр арасында инешкә корылганнары да бар. Андыйларны күргәч, кечкенә болак авыр ташны ничек әйләндерә ала икән, дигән сорау да күңелгә килеп киткән иде. Ләкин, болай уйлаганда, аның эчке мөмкинлекләре искә алынмаган, күрәсең. Анда елга ярларыннан чыкмаслык кына итеп күтәрелгән су горизонталь турбинага – ятып торган тәгәрмәч канатларына төшә. Ул калаклардан читкә акмасын, куәте кимемәсен, куласага гына хезмәт итсен өчен, чарыкның баш-башын томалап, ябып куялар. Турбина милкенә әйләнгәч, су басымы бик актив, йогынтылы

көчкә әйләнә, чарыкка җан кертә. Тагын шунысын да истән чыгармыйк: вал яхшы майланган, кытыршылык, каршылыклар бетерелгән подшипникка урнаштырыла, ул, турбинага кагылу белән, әйләнергә тора. Шуларның бөтенесе механизмны кеше ихтыярына буйсындыра, күндәм-карусыз итә.

Пучы халкы, гадәттә, Билтески һәм Матвеевка (Кәҗә авылы) тегермәннәренә йөри иде. Алар һәр икесе дә Ык елгасына корылган. Ык – инеш түгел инде, мул сулы дәрья. Биредә агымның кирәк кадәрлесе генә турбинага юнәлдерелә дә артканы, үзе бер елга кадәресе, бүтән үзәнгә борып җибәрелә.

Безнең авыл янында зур су юк. Бар булганы – Сарашлы инеше. Шуңа күрә бүтән авыллар янындагы елга һәм күлләргә кызыгып карый идек. Тора-бара гына Пучы белән Әнәкнең текә ярлы урыннарында, ТАССРның ул чактагы мелиорация һәм су хуҗалыгы министры Минтимер Шәймиев башлангычы белән, тирән сулы, балыклы капиталь плотиналар төзелде.

Ыкның куәте, ике җәпкә аерылып китүе, чарыкны бик җиңел әйләндерүе, файдалы эшкә яравы безнең ише малайлар күңелендә соклану, горурлану тойгылары, якты хисләр уята иде. Үсә төшкәч, шушы манзара, хыялый детальләр беән бизәлеп, төшләргә керә торган булып китте. Тегермән алды мәйданында атлар, арбалар тезелеп китә, агай-эне, үзара гәпләшеп, сабыр гына чират көтә. Аеруча күңелле, рәхәт шөгыль таш арасыннан ларга коелган җылы онны кыска саплы агач көрәк белән капчыкка тутыру була торган иде.

Элегрәк елга буендагы һәр авыл янында диярлек тегермән корылган. Аны төзүне борынгы бабаларыбыз йорт җиткерү кебек гадәти, фарыз эшкә санаган булса кирәк. Ул тирә-юньгә үзенә бер төрле ямь, хозурлык биреп торды. Аның тирәсендә яшьләр еш кына кичке уеннар оештырды, җырлап-биеп күңел ачты.

Тегермән буасының суы, язгы ташуны исәпләмәгәндә, беркайда да җир өстенә чыкмады, җәелмәде. Шул ук вакытта плотиналар, халык ышануы буенча, суның качуына, елганың саегуына юл куймады.

Тора-бара эстафета электр станцияләренә тапшырылды. Ошбу процесс Балтач районының Таузар иле авылында шактый үзенчәлекле оештырыла. Биредә тегермән гүяки киң күңеллелек, юмартлык күрсәтә, Хәтнә елгасының бер өлешен электр станциясе белән бүлешә: суның бер тармагы электр энергиясе җитештерүгә китә, икенче җәбе тегермәннең үзенә юнәлә. Аларның икесен дә берьюлы эшләтергә дә була, һәркайсын аерым-аерым эшләтү мөмкинлеге дә калдырыла.

Хәтнә – зур елга түгел. Шулай да биредә корылган станция 25 киловаттлы энергия биреп тора, Таузар иле өйләрен, урамнарын, ферманы яктырта, радиоузел шуның көче белән эшли.

Ошбу объектларның урнаштырылышында да үзгәлек бар. Алар агымсу өстендә түгел, елгадан читтә, коры җирдә корыла. Һәммәсе әзер булгач кына су арык буйлап турбиналарга җибәрелә. Бу станция узган гасыр уртасында 5 еллап хезмәт күрсәтә. Картлар, моның өчен колхозчылардан акча түләтелмәде кебек, дип сөйли.

Хәтнә станциясе Балтач районында тәүге электр корылмасы иде. Аннан соң Шушма елгасында, Яңавыл, Салавыч, Лызи авылларында 50шәр киловаттлы станцияләр корыла. 5 елдан соң алардан файдаланмый башлыйлар, ә Хәтнә елгасы, мөһим йомышы бар кебек, һаман да ашыга-ашыга йөгерә бирә.

Татарстан – тарлавыклар иле түгел, ләкин биек ярлы елгалар юк, дип тә әйтеп булмый. Казансу, мәсәлән, баштан алып ахырга кадәр ике ягы да текә ярлар буйлап ага. Аны яр биеклегендә күтәргәндә дә суы читкә чыкмый. Бу чакта инде елгада бик зур көч тупланган була. Тик шулай да андый ук елгалар җөмһүриятебездә күп түгел.

Әмма берсе дә өстәл өсте кебек тигез җир буйлап акмый. Һәркайсының күпмедер биеклектәге яры бар. Мондыйларга станция корганда суны аз гына, яр биеклегендә генә күтәрү дә җитә. Турбина өчен суның зур биеклектән төшүе генә лазем түгел. Анда басым, авырлык үзе мәсьәләне уңай хәл итә. Кечерәк ГЭСлар төзүне нәкъ менә шундыйлардан башлау хәерле булыр кебек күренә.

Турбиналарны эшләтү турында сүз барганда, гадәттә, югарыдан төшкән су басымына гына игътибар ителә. Елганы күтәрмичә, агым көчен генә файдалану мөмкинлеге бөтенләй искә алынмый. Шундый берьяклы караш аркасында бу көнгә кадәр тик агым басымына гына көйләнгән бер ГЭС та корылмады. Хәтта тау елгаларының агымы да бу эшкә көйләнмәде. Докторлык диссертациясен яклау мәшәкатьләре белән йөргәндә миңа күп тапкыр Алма-Атага барырга туры килде. Анда иҗат йорты яныннан гына тирән ярлы, текә үзәнле, зур куәткә ия шарлавык бар. Уйгырлар шул суның бер өлешен, сөзәгрәк арыкка юнәлдереп, җир өстенә чыгара һәм басуны сугару өчен файдалана. Бу – бик зирәк, акыллы фикерләү нәтиҗәсе.

Әлеге елга бер үк вакытта арзанлы электр ташкынын бирү вазыйфасын да күндәм башкара алган булыр иде, чөнки аны күтәреп кору кирәкми. Җитез куәтле агым болай да текә тарлавыктан төшә, әмма аңа электр бирү вазыйфасы йөкләнмәгән.

Турбинаны агым көченә җайлаштырганда киң канатлы чарыкны бастырып, вертикаль куялар. Техникада бу яңалык түгел. Түбән Кама ГЭСында турбиналар нәкъ шул рәвешле урнашкан. Аерма тик шунда: Түбән Кама станциясендә су өстән коя, күтәрелмәгән елгада исә турбинаны агым көче генә хәрәкәткә китерә. Һәр ике очракта да чарыкның ярты ягы ябып, каплап куела.

Агым аның эчендәге канатларга кагылмый уза, су икенче якка, ачык канатларга килеп бәрелә. Канатлар, кузгалып, агымга юл бирә. Монысы артыннан ук агым арттагы канатлар белән очраша. Су турбинаны әйләндерүдән гайре бер тарафка да китеп котыла алмый. Ул бер-бер артлы канатларны әйләндереп кенә агымын дәвам иттерә ала.

Шулай да агым көче белән эшли торган турбина әйләнеше югарыдан төшкән басым белән хәрәкәткә килүче чарык әйләнешеннән кайтышрак. Әмма аның үз мөмкинлекләре, үз өстенлекләре бар. Иң зур өстенлеге – су бастырып, басу-кырларны, урман-болыннарны исраф итмәү.

Турбиналар урнаштыру хисабына елга бермә-бер тарая. Су, нигә минем ирекне чиклисез, дигәндәй, ярсып, куәтлерәк ага башлый. Бакчада су сиптергәндә шлангның башын бераз кысып карагыз, су ераккарак китмәсме?! Киң дәрьяда шлюз хисабына да агым бераз кысыла төшә. Бу чаралар вал әйләнешен күпмедер тизләтүгә китерә.

Монда тагын шестернялар ярдәмгә килә. Әгәр тотрыклы әйләнеш бар икән, төрле зурлыктагы шестернялар әйләнеш тизлеген күп тапкыр арттыра ала. Моның ни икәне инженерларга гына түгел, һәр шоферга, велосипедчыга да яхшы таныш. Шулай итеп, тизлекне арттыру проблемасы бик җиңел хәл ителә.

Киңрәк дәрьяда янәшә берничә турбина куела. Дәү чарыкларны урнаштыруда аратирә Таузар иле төзүчеләренең тәҗрибәсе дә ярап куярга, ягъни станция төзелеше дәрьядан читтә башкарылырга мөмкин.

Димәк, су электр станциясен коруның, турбиналарны урнаштыруның ике ысулында да принципиаль яңалык юк. Аларның һәркайсы инде күп тапкыр сыналган, эшкә яраклы икәнлеге күптән исбатланган. Үзгәлек – башкада. Елганы күтәрткәндә буа йөзәр чакрымга сузыла. Бу арада инде башка станция төзеп булмый. Ә суны күтәртмичә, агым көче белән эшли торган станцияне исә адым саен тезеп чыгарга мөмкин.

Карап торышка җил куәтенә көйләнгән генераторның да гайрәте әллә ни түгел. Аның эшчәнлеге әле һава торышы үзгәреше белән дә бәйләнгән. Ләкин, шуңа да карамастан, һаман яңалары төзелә тора. Үзләрен аклыйлар, күрәсең. Күпләрнең эш нәтиҗәсен бергә кушкач, хәйран куәтле энергия барлыкка килә булса кирәк. Тамчы, тама-тама, күл хасил итә.

Моңарчы эшләп килгән энергия чыганакларның һәммәсе дә икенче бер нәрсәне киметү, юкка чыгаруга нигезләнгән: йә алар газ, мазут, ташкүмер ягу хисабына эшли, йә җир мәйданы су астында кала.

Интернет мәгълүматларына караганда, Зәй ГРЭСының бер блогы сәгатенә 40 тонна мазут яндыра, 12 блокка тәүлегенә 11520 тонна, 20 миллион 736 мең сумлык ягулык кирәк була. Айлык, еллык күләмне исәпләсәң, бик зур саннар килеп чыга. Өственә, ТЭЦ, ГРЭСлардан ургылып чыккан төтен атмосферага тарала. Ягулык материалларының берсе дә файдаланган саен артып, үсеп тормый. Җир дә чиксез түгел. Ул әле, су астында калудан тыш, юллар, шәһәрләр төзү өчен дә даими кимеп тора.

Тик акыл һәм хәстәрлек белән эш иткәндә, гидростанцияләр генә нәрсәне дә булса киметүне, юкка чыгаруны таләп итми. Аларның энергиясе бушка килгәнгә охшап тора. Су үзе дә кимеми. Дәрьялар миллионлаган еллар буена тын гына агып торган, саклап тотсаң, Арал диңгезе язмышына дучар итмәсәң, яр буйларына агачлар утыртсаң, тирә-юньдәге урманнарны кисмәсәң, чыганакларны – чишмәләрне карап, чистартып торсаң, алар әле алга таба да ил-көнгә озак дәверләр күндәм хезмәт итәр, дип өметләнергә була.

Принципта җил дә кимеми, тик шулай да аңа мөнәсәбәттә дә алдын-артын уйлап эш итү хәерле. Сугыштан соңгы елларда Алма-Атаның читендә, тирән тарлавыкта куәтле плотина корылды. Аның вазыйфасы силне тоткарлау, хәлсезләндерүдән гыйбарәт. Укучыларга ул күбрәк Медео шугалагы буларак таныштыр. Төзеп бетергәч, аның башка бер нәтиҗәсе дә билгеле булды. Алма-Ата таулар арасындагы иңкүлеккә, чокырга утырган. Шуңадыр:

«Алма-Атаның таулары,

Өзелә камыт баулары», – дип тә җырлыйлар. Монда һаваның алмашынып, җилләп торуы бик мөһим. Ә менә теге плотина гигант тарлавыктан исә торган җилне күпмедер дәрәҗәдә бикләп, буып куйган, калага үтә торган һаваның күләмен беркадәр киметкән. Кайберәүләр башкаланың Астанага күчерелү сәбәбен дә әнә шунда күрә. Билгеле, рельеф үзгәлегенең ролен дә истән чыгарырга ярамый. Әйе, урыны белән җил дә дефицитка әйләнеп куя икән.

Татарстанда 10ар, 100әр, хәтта 500әр чакрымнарга сузылган 500гә якын дәрья бар: Идел, Чулман, Агыйдел, Нократ, Ык, Зөя, Олы Чирмешән, Иж, Шушма, Илләт, Дала Зәе, Казансу, Мишә, Актай, Гөбенә, Тәмте, Сарман, Кече Мишә, Кече Чирмешән, Чишмә (Шушма), Минзәлә, Сөн, Кичү һ.б. Күбесенең исеме җырларга кергән, халыкның рухи хәятендә кадерле урын алган. Алар хозурлану объекты, күңелгә рәхәтлек бирүче, иркәләүче, юатучы күренеш буларак вөҗүдкә кереп калган. Шулай да елгаларны, дәрьяларны милли байлык дип санау, нишләптер, гадәткә кермәгән. Боларның һәркайсының куенында электр ташкыны, алтын ага. Тик ул су белән яшерелгән. Күрер өчен күңел күзе кирәк. Әйткәндәй, электр тогын үткәрү сыйфаты да суга тиккә генә бирелмәгәндер кебек тоела.

Менә шушы йөзәрләгән агымсуларның тик берсе – Чулман гына электр энергиясе бирүгә хезмәт итә. Калганнары моның ни икәнен дә белми. Милли байлыкның бу тармагы, аның иң зур өлеше әле икътисади үзләштерелмәгән.

Гәрчә агым көче белән эшли торган станциянең җегәре искитәрлек булмаса да, бу бит әле, ни дисәң дә, өстәмә энергия. Аны булдыру өчен, зур күләмдә мазут, газ, ташкүмер, торф яндыру да кирәк түгел, һава да бозылмый, атмосферага экологик зыян да килми.

Электр станциясе кору су тегермәне төзүдән катлаулырак түгел. Тегермән кебек, аны һәр елга буенда торгызырга була. Белгеч күзәтчелегендә, станцияне эшлекле, булдыклы аерым фермер да корып, арзан энергиясеннән файдалана ала. Мин кайчак уйлап куям: су электр станцияләрен күпләп сафка бастырган тәкъдирдә алар хәтта ягулык станцияләрен дә, ТЭЦ, ГРЭСларны да алыштыра алмас идеме икән? Алыштырса, бик күп ягулык материалы янга калыр, җан ияләре дә иркен сулап куяр иде...

Түбән Кама ГЭСы никадәр генә куәтле булмасын, энергиясе сәнәгатьнең, хуҗалыкның бар тармакларына да җитеп бетми. Өсти тору сорала. Бу җәһәттән кайбер эшем ияләре Түбән Чулман сусаклагычын тагын да күтәрергә, ягъни яңа җирләрне су астында калдырырга, халыкны кабат ярсытырга киңәш итә иде. Әле шунысы да бар: чамадан тыш куәт тә хәвефсез түгел. Моның шулай икәнен Саяно-Шушенск ГЭСындагы коточкыч авария дә раслады. Моннан тыш, Чулман һәм Агыйдел бассейннарында бер-берсеннән шактый якын арада үтә хәвефле, хәтәр АЭСлар кору планы да баш калкыта башлаган иде. Менә шулай: аяк астындагы ышанычлы, файдалы, хәвефсез чыганакларны шәйләмибез, инсанны борчый торган гамәлләргә барып тотынабыз. Югыйсә, якында гына мул сулы Нократ ага, Зәй, Ык елгалары дә сәнәгать үзәкләреннән ерак түгел.

***

Дөрес, бәгъзе пошмас җаннар мәсьәләгә башкача да карарга мөмкин. Ягъни аларның:

– Нигә өстебезгә артык мәшәкать йөкләргә? Әле бит югарыдан да күрсәтмә төшмәде, – дип фикер йөртүе ихтимал. – Моңарчы яшәдек бит әле агымсуларга тимичә дә...

Яшәвен яшәдек анысы, ләкин нәкъ менә шундый психология аркасында ифрат зур байлыгыбыз бү көнгәчә файдаланылмый ята. Кече һәм урта энергия чыганаклары төзелмәде, төзелгәннәре дә сүтелде. Түбән Кама ГЭСы фонында аларның дәрәҗәсе бик нык түбәнәйде. Әйтерсең, бездә бер галим дә, инженер да юк. Әгәр елгасыз төбәктән килеп чыккан берәр эшмәкәр шушы хәлне күрсә, моңа бик нык гаҗәпләнер иде. Аның алдында үзебезгә дә күңелле булмас иде, әлбәттә.

Хәзер төрле илләрдә электр энергиясе бирердәй башка чыганакларны (әйтик, Кояшнымы яки бүтәннеме) файдалану юлларын эзлиләр. Нишлисең бит, әгәр аларда бездәгедәй дәрьялар агып ятса, Кояшка ук үрелмәсләр иде.

Дөнья цивилизациясе раслаганча, нефть, газ сатып, запасларны киметә барып кына, җөмһүрият ерак китә алмый. Елгаларны эшкә җигү исә – ышанычлы, тотрыклы, перспективалы гамәл. Күп санлы агымсуларның куәте тулысынча үзләштерелгән тәкъдирдә һәркайсының җегәрен бердәм энергетика системасына тоташтырырга мөмкин. Ул тулысынча җөмһүрият милке булачак. Яңа ГЭСлар челтәре республикабызның икътисади куәтен ныгытачак. Энергиянең артыгын күрше мәмләкәтләр белән дә бүлешергә, аларга сатарга да мөмкин. Хәзер бит бездә социализм түгел, баеп китүдән курыкмаска да була.

Энергия муллыгы җөмһүриятебез эчендәге электрга түләү бәясен дә киметәчәк, дип фараз кылам. Боларга өстәп, киң мәйдандагы зур төзелеш күп санлы яңа эш урыннары да булдырачак... ■

ТАССР

Бу язма берничә рәсемне шәрехләү яисә аңа кереш рәвешендә генә барлыкка килде. Телгә алынган тема, югыйсә, киң, тирән һәм һәрьяклы тикшерүгә, анализлауга лаек. Минем исә игътибарыгызны берничә фактка гына юнәлтеп узасым килә.

Беренчедән, дәһшәтле 1552 елда Казанны яклап шәһит киткән бабаларыбыз истәлегенә куеласы һәйкәл офыкта әле дә чамаланмый. Хөкүмәтнең бу хактагы 93 нчы карары (26 февраль, 1999 ел) бүгенге көндә дә гамәлдә булса да, хәзер, газиз җиребез һәм татар халкы һәр фронтта җиңелеп килгән көндә, мондый изге эшне ахырына җиткерү кебек «тиле уй» бер генә «сәламәт акыллы» җитәкченең дә башына килә алмый. Гәрчә, үз вакытында, әлеге карарны гамәлгә ашыру максатыннан конкурс игълан ителеп, сынчы Н.Т.Хаҗиәхмәтов белән архитекторлар С.А.Мамлеева һәм Л.Н.Иванова проекты җиңүче дип табылса да. Ул чакта һәйкәл урыны да тәгаенләнде: Нургали (Тайницкая) манарасы яны.

ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛЛАР СӘЛАМЕ...

Рүзәл Мөхәммәтшин

«Революция милләтчелек аермаларын бетерде». К.Чеботарев рәсеме. 1924 ел

«Причал» журналы тышлыгы. 1925 ел



Казан алыну истәлегенә куелган әхрам-һәйкәлне Татарстан Республикасы төзелү һәйкәле итеп үзгәртү проекты. Казан сәнгать-техника институты студенты В.Сотонин эскизы. 1920 нче еллар

Икенчедән, Казанны яулап алганда гомерен җуйган илбасарлар хөрмәтенә әхрам-һәйкәл XIX гасырда ук төзелгән. Ике төп милләтнең күңелен тигез күрергә тырышып сәясәт корган җөмһүрияттә мондый гаделсезлек татарның җанын талкып-йолкып тора, билгеле. Хәер, шунысы да бар: елга уртасында калганнан бирле (1950 нче еллардан соң) әхрам-һәйкәлнең хәле күз алдында мөшкелләнә – нигезе юыла, бинаны су ашый, төрбә өлешен язгы ташу басып, туганнар каберлеге һәрдаим шәрәләнеп, хәкарәтләнеп кала...

Аерым искәртик: әхрам-һәйкәл 2005 елдан бирле тулаем чиркәү карамагында, безнең җөмһүриятнең алда бәян ителгән хәлләргә бернинди катышы юк.

Өченчедән, баксаң, тарихи хәтер мәсьәләсендәге мондый сансызлык күренеше тешне кичә-бүген генә сызлата башламаган икән. Кул сузымындагы йөз ел элек тә, ул, кургаш хис булып, бәгырьләргә утырган. Йөз ел элек тә ул хистән арыну юлларын тәкъдим итүчеләр табылган. Әлбәттә, Казан алыну вакыйгасына карата үзгә мөнәсәбәтне чагылдырган монументаль сәнгать әсәре калыкмый торып, безнең халкыбыз күңел тынычлыгы тапмаячак. Вакыт күрсәтер.

Әлегә, һичбер гамәлгә өндәмичә, берничә сурәт күрсәтеп узыйк. Урыс фамилияле авторлар ясаган бу рәсемнәр, һичшиксез, Татарстан Республикасы оешуның 100 еллыгын билгеләп үтүгә әзерләнгән көннәрдә аеруча... хәер, актуаль үк, димичә, игътибарга лаек, дип чикләник.

Искәрмә.
Рәсемнәр Наил Вәлиевнең «Константин Чеботарев, Александра Платунова. В поисках пути в искусстве» китабыннан алынды. ■

«БӘЙГЕЛӘРДӘ БӘЙГЕ ТОТКАН КАВЕМ...»

Таң ярала...
Безгә, димәк,
Язган гомер чигәргә...

***

Канатлыга һәрбер читлек – зиндан,
Канатсызга – оя.

Газинур Морат

Газинур Морат – узган гасырның 70 нче еллары ахырында шигърият мәйданына килгән талантлы буынның бер вәкиле. Шагыйрьнең тәүге шигырьләре 1970 нче еллар башында Кукмара районының «Хезмәт даны» газетасында күренә башлый. Казан дәүләт университетында укыган вакытта шигырьләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре республика көндәлек матбугатында бик еш басыла. Татарстан китап нәшриятында бер-бер артлы аның «Җир хәтере» (1985), «Мин дөньяны тыңлыйм» (1988), «Тылсымлы тел» (1989), «Оча җырлар» (1991), «Ачык дәрес» (1995), «Түбә» (1998), Җәяүле кошлар» (2002), «Әкияткә ышанмаучы малай» (2003) һ.б. китаплары дөнья күрә.

2007 елда, «Төнге әверелеш» китабы (2005) өчен, Г.Морат Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге премиясе белән бүләкләнә. 2016 елда исә «Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» китабы Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Шагыйрьнең гражданлык лирикасында чагылыш тапкан кеше хокукы, шәхес хөрлеге, ирек-бәйсезлек темалары беркайчан да актуальлеген югалтмый:

Өйлә мәле...
Юлда әле
Һәр юлаучы, юламан.
Якты эзләп килешебез
Төнгә илтер юллардан...

Сүзем Газинур Моратның «Кош хокукы» китабы, анда урын алган шигырьләре турында. Җыентыктагы шигырьләрнең күбесендә милләтебез киләчәге, халкыбыз язмышы, шәхес иреге турында сүз бара. Шагыйрь китапның алгы өлешендә бирелгән «Канатлы сүз» шигырендә, җәмгыятебездә әле уй-фикернең дә бәйсез була алмавына борчылып, болай ди:

Ирекле, бәйсез уеңны
Көпчәкләр үтте таптап.
Урам ташларында ятып
Калды тик шәүлә-таплар...

Көпчәкләр бу шигырьдә символик мәгънәгә ия. Ул – илдә булган репрессияләр, хөр фикерле кешеләргә каршы юнәлтелгән «тәртипләр». «Көпчәк»нең уйларны гына түгел, кешеләрне дә изәргә сәләтле булуын искәртә шагыйрь.

Әдип иҗатындагы кош, кошчык образына да символик мәгънә салынган. Китап исемнәренә генә игътибар итик: «Җәяүле кошлар», «Кош хокукы».

Тәңре – табигать тә безнең
Ихтыярда асылда –
Талга кунып сайрар былбыл
Читлек куначасында.

Җырлыймы ул, елыймы ул –
Безгә барыбер – хозур!

Иреккә сусаган җанның
Ләгънәте, каргышы да
Шагыйрәнә аның, –

дип яза ул «Былбыл» шигырендә. Кош – канатлы һәм ирекле. Ул – азатлык символы. Шагыйрь белән килешмичә мөмкин түгел: ирек сөюче былбылны да читлектә «сайратырга» тырышабыз түгелме?! Чыннан да, «җырлыймы ул, елыймы ул – безгә барыбер» бит. Шәхес ирегең, азатлыкка омтылган күңелне сурәтләүче шагыйребезнең, үзе әйтмешли, каргышы да тормыш ваклыкларыннан өстен – шагыйрәнә ул!

«Кош хокукы» шигыренә аерым тукталырга кирәктер. Һәрбер юлы афоризмга тиң бу шигырьдә шәхес иреге, шәхес хөрлеге, кеше хокуклары турында гаҗәеп матур, тирән мәгънәле юллар бар:

Хакны әйтергә дә хокук кирәк.
Әйтим, дисәң ярып турысын,
«Птичье право» дигән гыйбарәсе
Искә килеп төшә урысның...

Рус халкы бөтенләй хокукы булмаган кеше турында: «У него птичьи права», – дип әйтә. Кош хокукы кадәр дә хокукыбыз булмавы, милләтнең үз дигәнчә яши алмавы аеруча борчый аны. Шагыйрьнең:

Үз хәлеңне күршеләрдән сора –
Ут-күршеләр яши күршеңдә...
Хакны әйтергә дә хокук кирәк,
Кош хокукы кирәк кешегә, – дигән юллары азатлыкка омтылганнарның җан авазы булып яңгырый.

Газинур Морат шигырьнең алдагы өлешендә аерым бер шәхес хөрлеге турында гына сүз алып бармый, ул халык иреге, халкыбызның азатлыгы турында мөнбәрләрдән яңгырарлык итеп болай дип белдерә:

Ирек яуларга да хокук кирәк,
Сорап алып булмый ирекне.
Кошлар хокукына ия халык
Бәйсез халык, – димәк, ирекле!

Бу урында язучы Рәфыйк Шәрәфиевнең Газинур Морат иҗаты турындагы фикерен китерү урынлы булыр:

«...Һава ярып, әнә, кошлар оча,
Син очасың бары төшеңдә», – дигән юллар бүгенге хәлебезгә ишарәдер. Җәяүле кошлар – без икән бит ул. Канатландык, дип шатланышкан булабыз тагын! Бик иртә тынычланганбыз, әле көрәштән суынасы түгел икән! Әмма көрәшче шагыйрь китап кадәр китапка мәгънәви ачкыч булган шигырендә мондый фикерләр белән генә чикләнә алмый. Чиксез тоелган караңгы төн аръягында гына булса да бер яктылык нуры кирәк безгә. Шагыйрьгә дә, аның укучыларына да. Һәм әнә ул яктылык:

«Империя калыпларын ватып,
Хөр мәмләкәт төзи халыклар», – ди Газинур Морат шул ук әсәрендә».

Шагыйрьнең «Канатлы барс» шигыре дә әлеге уйлануларыбызның кайтавазы булып яңгырый:

Очып түгел – тәпиләп тә
Ничә гасыр кичелгән...
Очар иде – чарасы юк –
Канат очы киселгән.

Бәйсезлеген югалткан халыкны әнә шулай канаты киселгән кошка тиңли ул. Канатсыз кош ничек очсын соң?! Шагыйрь дә чарасыз.

Әйе, хөр мәмләкәт турындагы хыял белән бергә, шагыйрь күңелендә төшенкелек, милләтебезнең бүгенге хәленә ризасызлык та бар. Сүзебезне раслау өчен, «Аран» шигырендәге юлларны китерик:

Бәйсезлегең бәйдә бәргәләнә,
Бәйсезлегең бәйле әлегә.
Бәйгеләрдә бәйге тоткан кавем,
Бәйсезлегең тоткын хәлендә.
Бәйгеләрдә бәйге тоткан Атың,
Тышаулаган килеш аранда,
Сугымчыны көтә...

Бу шигырьдәге Ат образы да символик мәгънәгә ия. Ат – хөрлек, азатлык турындагы хыялыбыз ул. Татар халык иҗатында «Һәрбер ирнең йөрәгендә иярләнгән ат ята» дигән мәкаль бар. Ат – татар халкы өчен иң кадерле, иң газиз хайван. Шагыйрь бәлки шуңа күрәдер дә Ирек турындагы хыялны АТ белән чагыштыргандыр.

Публицистик пафослы исемсез шигырендә ул, кешеләргә мөрәҗәгать итеп, милләтне коткарырга чакыра:

Аваз килә Идел төпләреннән:
Сез кичәргә тиеш Иделне.
Шулай гына коткарырга мөмкин
Ирегеңне, туган илеңне, –

дип, Г.Морат татар дәүләтчелеген торгызу өчен көчебезне, акылыбызны тупларга өнди.

Әдип «Сталинизм» дигән кыска гына шигырендә тираннарга, халыкларны буйсындыручыларга, татарны кимсетүче затларга булган нәфрәтен белдерә:

Үз иле зиндан булса да,
Йөрер ул ирек эзләп –
Чит халыкка ирек даулар,
Ирегең ирексезләп...

«Черек күл» дип исемләнгән шигырендә дә, репрессия чорында «халык дошманы» дип әрәм ителгән милләтебезнең асыл ул-кызларының исемнәрен атый-атый, тарихтан гыйбрәт алырга чакыра шагыйрь:

Күпме табут кайтты илгә,
Күпмесе – безгә кордаш...
Кай зиратта ята, димсең,
Якташың Фәтхи Бурнаш?
Кай зиратта ята, димсең,
Хөр уйлы гали җаннар –
Мирсәет Солтангалиев,
Тинчурин, Галимҗаннар?!.

Ирек даулап ачлык игълан иткән, мәйданнарда көрәшкән әдип, үзенең «Сусанин» шигырендә, үткәннәрне тасвирлап, болай ди:

Тарихларны кичә-кичә
Хәлдән тайдык. Сусадык.
Юл сорадык чишмәләргә –
Юл күрсәтте... Сусанин.

Чишмәнең ирек, яшәү символы икәнен һәммәбез аңлый. Шул ук вакытта тарихтан да хәбәрдарбыз: Сусанинның кая алып барасы аңлашыла. Әмма өметсезлек белән башланган әлеге шигырендә дә үз укучысын юатырдай сүзләр таба ул:

Без дә чыгарбыз хак юлга –
Гасырларны кичәрбез.
Ирек дигән чишмәләрнең
Ятып суын эчәрбез.

Шулай була күрсен! Газинур Моратның шигырьләрен укыгач, аның әнә шулай халкыбыз язмышы өчен борчылуын, татар халкы алдында үзен дә җаваплы тоюын тагын да ныграк аңлыйсың. «Ачлык» поэмасында мондый юллар бар:

Алып буйлы халык идек юкса,
Яралган соң нинди каннан без?
Илсез калмас, телсез калмас өчен,
Ачлык тотар көнгә калганбыз.

Бу – мөрәҗәгать кенә түгел, ә шагыйрьнең җан авазы да! Инде Туган тел турында сүз чыккач, әдипнең бу шигъри юлларын да искә төшерик:

Тузга язылмаган сүзләр эзлим,
Туган телем –
Туңган телемнән.
Тузга язылганны сөйли-сөйли
Телсез кала яздык ил белән...

Тел өчен көрәшнең кискенлеген аңламаганнарга аңларлык итеп язган шагыйрь. Бу бүгенге көндә тагын да кискенрәк, актуальрәк яңгырый.

Әйткәнемчә, Г.Моратның «Кош хокукы» китабында Шәхес хөрлеге, Кеше хокукы, Милләт азатлыгы темасына язылган шигырьләр аеруча зур урынны алып тора һәм, үзең дә сизмәстән, син шагыйрьнең теләктәшенә әйләнәсең. Нәкъ син уйлаганнарны язган өчен рәхмәтле булып, укуыңны дәвам итәсең.

Шагыйрьнең «Канатлыга һәрбер читлек – зиндан, Канатсызга – оя», – дигән юлларын мәкаләгә эпиграф итеп алган идем. Аның сүзләрен куәтләп, канатлы булыйк, диясе генә кала.

Фидания Леронова,
Казан шәһәренең 15 нче урта мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы ■

«ТАТМЕДИА» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Татарстан китап нәшрияты,
«Безнең мирас» журналы редакциясе

ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс **2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә.

Конкурска үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

Конкурска юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

Безнең мирас №8 август 2019

ТАССР

Безнең заман һәм замандашлар

Роза Хәбибуллина

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә йөз ел тула! Безнең буын – шул йөз елның балалары, революция рухында тәрбияләнеп үскән, укыган, эшләгән, яшәгән. Кадерле, бик кадерле ул үткән гомер! Буш ара булмаган ул, тулы, шатлыклы да, тетрәндергеч фаҗигале вакыйгаларга да бай гомер!

СССР дигән илне таркатып, ил, халык байлыгын үзара бүлешеп үзләштергән яңа буржуазия Октябрь революциясеннән соңгы йөз елны каһәрләп, тарихтан сызып ташларга, без яшәгән заманны гел каралтып, пычратып күрсәтергә тырыша.

Юк, без кичкән гомер мәгънәсезгә, заяга узмады, егерменче гасырда халкыбыз бөек максатларга, үзгәрешләргә, җиңүләргә иреште, шул җиңүләрдә безнең буынның да өлеше зур!

Бала чагыбыз, мәктәп еллары сугыш чорына, яшьлегебез – сугыш яраларын төзәтү, илне торгызу елларына туры килде. Күп авырлыклар кичердек, күп нәрсәләрдән мәхрүм идек. Ләкин авырлыклардан соң тормыш яхшыра барды. Матур тормышка омтылдык, бәхеткә туры юл – белем, дип уйладык. Безгә юллар ачык иде: бушка укыдык, эшкә урнаштык, диплом алып, социализм төзибез, дип, дәртләнеп эшләдек; бушка дәваландык, хөкүмәт бушка фатир бирде, яраткан хезмәтебезне намус белән башкардык. Гомеребезнең куанычлы- шатлыклы еллары булды. Менә шул елларда социализмда яшәп алдык: илдәге иң авыр хезмәт башкарып та, хезмәтенә тиешле бәя бирелмәгән авыл халкы – колхозчыларга дәүләт йөзе белән борылды: акчалата түләү кертелде, пенсияләр бирелде, колхозлар ныгыды. Миллионер колхозлар үсеп чыкты. Бәяләр тотрыклы булды. Эшсезләр, хәерчеләр, ачлар булмады! Иң очсыз нигъмәт – ипекәй иде! Илебез ныгыды, космосны беренче булып яулады, дәүләтебез чикләрен көчле армиябез саклады.

Балачак хыялы

Заман турында уйланулар кадерле хатирәләрне яңартты. Илленче еллар. Тугызынчы сыйныфта укый идем. Стенага эленгән тәлинкәгә охшаган репродуктордан Болгариянең Казанлык дигән үзәнендә роза гөлләре үстерү турыда сөйлиләр.

...Әле таң алсуланып сызылып кына килә. Кошлар да берән-сәрән генә хәбәрләшәләр. Үзәнлектә Җирнең иң матур, иң зиннәтле роза чәчәге әкрен генә, сак кына бәбәкләрен ача, тирә-якка нәфисләрдән дә нәфисрәк, җанны, күңелләрне эретерлек хуш ис тарала... Бу затлы хуш исне саклап калыр өчен, хатын-кызлар чәчәкләрне кояш чыкканчы камыш кәрҗиннәргә җыялар. Шундый ук саклык белән генә ул гүзәл чәчәкләрне фабрикага илтәләр. Биредә алардан алтын бәясеннән күпкә кыйммәтлерәк роза мае алалар. Бу алсу таң да, гөлгә кунып сайраучы былбыллар да, әкрен генә яфракчыкларын



Роза һәм Ильяс Хәбибуллиннар, Казан. 1960 нчы еллар башы

ачкан гөлчәчәкләр дә күңелемне ымсындырып, җаныма гомерлеккә кереп урнаштылар, тормышка ашмас хыялыма әйләнделәр...

Бик теләсәң, хыяллар да тормышка аша икән. Институт тәмамлап, үзем укыган мәктәптә укыта башладым. Шул вакытта гади кешеләр дә чит илләргә чыга башлады. Мәгариф хезмәткәрләре профсоюзына Болгариягә юллама сорап гариза яздым. Санаторий, туристик юлламаларның бәясе түбән иде безнең заманда. Балачак хыялларым канатында коштай талпынып, роза гөлләре иленә җыенам. Мөслим аэропотында «кукурузник»ка утырып Казанга очканда миннән дә бәхетле кеше булмагандыр! Очкычның «сикәлтәләрен» дә сизмәдем.

1967 елның 18 июлендә кич белән Казаннан «Татарстан» поездына утырып юлга чыктык. Группа утыз кешедән тора, күбесе – Казаннан.

Башкала безне яңгыр белән озатып калды. Вокзалда бик күп озатучылар: сөйләшәбез, хушлашабыз, көлешәбез! «Татарстан» – Казан белән Мәскәү арасында йөри башлаган өр-яңа, искитмәле чиста, уңайлы поезд икән. Йомшак купеда без дүртәү. Юлдашларымның өчесе дә – Казаннан. Егерме көн чит илдә бергә ял итәсе сәфәрдәшләрем мине бик кызыксындыралар: кемнәр икән? Без бер-беребезгә карап елмаябыз, танышабыз. Зур кара бәрхет күзле, озын кара керфекле, куе кара кашлары

кушыла язган, кабарынкы иренле, шәрык гүзәленә охшаган кыз Миләүшә исемле икән. Дәрәҗәле кызларга хас җитдилек, тыйнаклык сизелә аңарда. Тәгъзимә апаның яшен чамалый алмыйм, бик тә мөлаем, гел елмаеп кына тора, тарих фәнен укыта икән. Алар Миләүшә белән туганнардыр, дип уйладым. Флера – яшь, нәфис, чибәр кыз: кара кашлы, кара чәчле, күзләре зәп-зәңгәр! Зәңгәр күзле брюнеткалар – сирәк очрый торган гүзәлләр, шуңа күрә ятраклар, кайчак озын кара керфекләр ышыгындагы сөрмәле күзләр кешегә сагаеп, салкынча карыйлар кебек тоела. Флера югары белемле инженер кыз булып истә калган. Фамилиясе бик матур – Рамазанова. Дүртенче кеше – мин. Ике кызымны әнкәйгә калдырып киттем. Сәяхәт кылырга яратканым өчен, әнкәй миңа: «Зимагур», – ди. Мәскәүгә иртән барып төштек. Одесса поезды кичке уннар тирәсендә генә китәргә тиеш икәнен белгәч, көн буе Мәскәүдә йөрдек. Мәскәүдә, кая барсаң да, истәлекле урыннарга тап буласың: Свердлов мәйданында Зур театр янында булдык, анда әле реставрация бара. Кич белән Киев вокзалындагы ресторанга кереп ашадык.

Украина буйлап

«Татарстан» поездыннан соң, Мәскәү-Одесса поезды һушыбызны алды: иске, купшакланган, пычрак. Арыганлыктан, бернигә карамый ятып йокладык. Икенче көнне иртән Украина буйлап барабыз: тип-тигез, ямь-яшел далалар, пирамидаль топольләр, җимеш бакчалары, алтын төсенә кергән иген басулары буйлап поезд чаба. Коридорда ике урыс абзые сөйләшә:

– Басуларын утамаганнар, чүпле, – ди берсе. Типик шәһәр кешеләре, хәзерге заманда басуны утамаганны, чүпкә каршы гербицид файдаланганны белмиләр. Чыннан да, басулары чүпле. Безнең Мөслим басулары искиткеч чиста, быел мул уңыш көтелә. Мин киткәндә бодай кырлары алтын төсенә кереп калды. Районыбыз өчен горурланып куйдым!

Украина авыллары бакчаларга күмелеп утыра, вокзалларда алма, помидор-кыяр сатучы хатыннарның әллә нинди матур, көйле украинча сөйләмнәренә сокланып, гаҗәпләнеп бардык.

Сугыш афәте

Бер тукталышта сугыш вакытында фашистлар бомбага тоткан җимерек вокзал бинасын күрдек. Төзәтмәгәннәр, истәлек, дошманнарга нәфрәт булып тора... Тирән уйга чумдым. Сугыш минем күңелемдә пичәтләнеп калган. Йөрәкләрне өшетеп, сызгырып, улап килгән бомбаларның тере кешеләр өстенә төшеп шартлавын ишетәм. Таш диварларның гөрселдәп ишелүен, утка чорналуын күз алдына китерәм. Монда кемнәрнеңдер газиз гомерләре киселгән. И Ходаем, балалар да булгандыр анда... Шул уйдан җаным тетрәнә. Мин бит балалар укытучысы, ике бала анасы да! Бөек Ватан сугышы елларында украин халкы күпме югалтулар кичерде, күпме шәһәрләр, авыллар җимерелде. Бу җирләр кеше каны белән сугарылган. Юлдашларым да көрсенеп куйдылар. Моңа кадәр булган шатлыклы, кояшлы кәеф сүрелде. Купега кергәч тә сүз шул турыда дәвам итте.

Көтелмәгән очрашу

Көтмәгәндә, яшел кыр-болыннар зәңгәр диңгезгә әйләнде! Ничек, Одессага килеп тә җиттекмени? Миләүшә дә, мин дә, Тәгъзимә апа да вагон тәрәзәсенә капландык!

Миләүшә
Маннуровна
(Шәйхиева)

Купега, ашыгып, Флера килеп керде дә, сөенче алгандай:

– Кызлар, Днепр! – дип сөрән салды.

– Днепр?!

– Кременчуг сусаклагычы!

Иң беренче уй – «Чуден Днепр при тихой погоде... Редкая птица долетит до его середины!» Менә сиңа Днепр! Кайда монда ярлар?! Иге-чиге юк, офык диңгезгә чумган! Днепрның дулкыннарына карап, күңелем хәтер киңлекләрен гизә. Гоголь, Тарас Бульба, Запорожье казаклары... Коллык газабын кичергән шагыйрь Тарас Шевченконың «Завещание»се телгә килә:

«Как умру – похороните на Украине милой,
Посреди широкой степи выройте могилу...»

Днепр ярында күмелгән кобзарь Тарас Шевченкодан ерак та түгел, Канев шәһәре янында немец фашистлары белән бәрелештә язучы Аркадий Гайдар геройларча һәлак була, аның да кабере Днепр ярында. Җимерек вокзалдан соң туган сагышлы гамь, кечкенәдән китапларын укып, рус телем ачылган Гайдарны хәтеремә төшерде... Днепр... Гражданнар сугышында минем әткәй – Шакир Галимов Днепрны кичкәндә каты яра-

ланган. Кан агып хәлсезләнгән егетне шул мәхшәрдә бер солдат табып, медсанбатка илткән. Госпитальдә эткәйгә операция ясаган хирург, яңагыннан снаряд ярчыгын алганда: «Твое счастье, солдат, когда осколок попал в тебя, он был уставшим, иначе тебя не было бы в живых», – дигән. Таныш булмаган солдатка да, хирургка да гомер буе рәхмәтле эткәй искә төшереп сөйли иде.

Днепр белән очрашу күңелемдә менә шундый истәлекләрне кузгатты.

Одессада

Кояшлы иртәдә Одессага килеп төштек. Безне Болгариягә алып барасы теплоход төнге унбердә генә кузгалачак икән! Барыбыз да диярлек экскурсия автобусына күчеп утырдык. Шәһәрнең иң истәлекле, данлыклы урыннарында – Диңгез буе бульварында, Потемкин баскычында, опера театрында, Пушкин һәйкәле янында, язучы Куприн әсәрләрендәге атаклы «Гамбринус» кафесында, Дерибасов урамында йөрдек. Монда тормыш бик үзенчәлекле тоелды: кояшта бронза төсенә кергән сөйкемле одессалылар ашыкмыйча, үз көйләренә йөриләр, шәһәр бик тыныч – шау-шу, кабалану сизелми. Мондый матур, яшеллеккә, чәчәкләргә күмелгән, җиләс диңгез җиле иркәләп искән шәһәрдә кешенең холкы шулай булырга тиештер...

Одесса порты – халыкара зур порт, гаваньда нинди генә кораблар, лайнерлар юк! Таможняда төрле милләт кешеләре: негрлар, карасу төсле гарәпләр, кысык күзле әллә кытайлар, әләлә япуннар; Үзбәкстаннан, Пензадан, Кировтан, тагын әллә кайлардан безнең кебек меңнәрчә СССР туристлары. Бик каты арып-алҗып, ниһаять, «Үзбәкстан» теплоходына кереп урнаштык. Беренче классны каютага тагын дүртәү, тик бу юлы бөтенләй башка кешеләр белән туры килдем. Юынып, чиста урыннарга яткач, йоклап киткәнне сизмәдек тә. Юлдашларым – якташларым диярлек: Бондюгтан – өч инженер кыз, химия заводында эшлиләр. Итәнгә кадәр берни сизми йоклаганбыз. Безне йокыдан каютадагы радио бик шат, кунакчыл тавыш белән уятты:

– Хөрмәтле ял итүчеләр! Сезне ресторанга иртәнге ашка чакырабыз!

Теплоходта гаҗәеп оста ир-ат коклар эшли икән: бик тәмле, татлы ризыклар белән сыйладылар. Безнең ял башланды. Сөенеч: беренче каттагы палубада сай бассейнга фонтаннан диңгез суы коелып тора! Кояшта кызынып, фонтанда коенып рәхәт чигәбез. Вакыты-вакыты белән радиодан хәбәр итәләр: «Хәзер һаваның җылылыгы 26 градус, җил – 3 балл, диңгездә – ике балл, җирнең иң якын ноктасы – Румыния ярлары». Алда тоташ зәңгәрлек – горизонт юк! Мин бу саф зәңгәрлеккә биһуш! Бәхетле!

Варна

Менә безнең теплоход Варна гаванена якынлаша. Болгария байрагы беркетелгән катерда лоцман килеп, безне причалга озата, теплоход әкрен генә туктый. Болгария җиренә музыка астында аяк басабыз, шатлыклы, дулкынландыргыч мизгелләр. Шунда, сискәндереп: «Бу бит чит җир, чит туфрак», – дигән уй сызылып үтте. Ап-ак озын автобусларга утырабыз. Кулына микрофон тоткан уртача буйлы, кыска кара бөдрә чәчле бик матур, сөйкемле ханым безгә елмаеп эндәште:

– Сезне Болгариягә килүегез белән котлыйм! Мин сезнең гидыгыз булам, Христина Дмитриевна дип мөрәҗәгать итәрсез. Без хәзер сезнең белән Варна шәһәренең Ленин проспекты буенча «Алтын ком» («Золотые пески») курортына юнәләбез. Ул утыз километр ераклыкта. Сулда сез Юрий Гагарин исемендәге стадионны күрәсез. Аны спортчылар һәм комсомолецлар төзеде.

Гидыбыз русча чиста матур сөйли, ул әйткән атамалар шундый таныш, чит ил икәне сизелми дә, гүя без үз ватаныбызда! Автобусыбыз нәкъ диңгез буенда урнашкан «Акация» дигән отельгә килеп туктады. Автобустан төшүгә, диңгезнең дымлы һавасына кушылган роза чәчәкләренең татлы исе хушны алды, барыбыз да «аһ!» иттек: тирә-якта – бар җирдә розалар! Якында гына зәңгәр диңгез чайкала... Аяк астында ап-ак ком.

– Вам повезло, море рядом с отелем, – диде гидыбыз. Бондюг (хәзер Менделеев) кызлары белән без тагын бер номерга дүртебез урнаштык! Зур, иркен бүлмәбез – почмакта, ике якта да лоджияләр, шезлонглар! Диварлар киңлегендәге диңгезгә караган тәрәзәләрдә алсу пәрдәләр, күңелле! Кызларымнан да уңдым: өчесе дә дуслар, яшьтәшләр, шаяннар, чып-чын туристлар – Чехословакиядә һәм Германиядә булганнар! Мин исә чит илдә әле беренче тапкыр.

«Кәкре юкә» рестораны

Әйберләребезне урнаштырып, кичке ашка ресторанга киттек. «Кривая липа» дип атала икән без егерме көн йөрисе ресторан. Безнең туган телебездә «кәкре каен» гыйбарәсе генә бар, беркатлыларны терәтә торган. Болар «кәкре юкә», дип, ресторанга кушканнар. Зур залда үзебезнең өстәлне эзләп таптык. Утлар балкып яна, официанткалар кояштай елмаеп каршылыйлар. Ак җитен эскәтер җәелгән өстәл уртасында яңа гына суыткычтан алынган озын муенлы шәраб шешәсе, ялт-йолт килгән биек тәпиле кыйммәтле юка фужерлар, кеше саен минераль су шешәләре, биек вазада туралган ап-ак ипи, тирән керамик савытта алма тора. Без биредә үзебезне олы кунак кебек тойдык: шулкадәр сый-хөрмәт таң калдырды: кыйммәтле шәраб, яшелчә салаты, ике төрле гарнир белән зур кисәкле (кызганмыйча салганнар!) тапталып йомшартылган ит, десертка – алма һәм пирожное.

Юлда кызудан кибегеп килгәнгә, шешәләре парланып торган минераль суны шундук эчеп бетердек. Озын шешәдәге «сухое» дигән шәрабка беребез дә кагылмый утыра идек, җитәкчебез Мәһди:

– Кызлар, бар нәрсә юлламага кергән, эчегез, аның бит градусы әз, – диде. Кояш нуры уйнап-янып торган шәрабне салып, очрашу хөрмәтенә бокалларны чеңләтеп алдык. Җитәкчебез градусы юк, дисә дә, рестораннан күтәренке күңел белән, шаулашып-көлешеп чыктык.

Ашлар, итле нигъмәтләр, яшелчә һәм җиләк-җимеш тел йотарлык һәм мул. Болгариядә ашаган ипинең тәмен аңлатып бетерерлек түгел, аерым тәм. Беренчедән, ул йомры ак калачны мич төбенә салып пешерәләр, диделәр; икенчедән, андый бодай бары Болгариянең Добруджа үзәнлегендәге кара туфракта, ясалма сугару белән үсә, гаҗәеп мул уңыш бирә, хәтта иң коры елларда да үз илләрен, үз халкын туйдырырга җитә, дип сөйләде Христина Дмитриевна. Безгә алган саен, ипине өстәп торалар, чөнки ул ашап туйгысыз иде.

Төркем җитәкчеләре

Татарстаннан килгән безнең төркемдә Мөслимнән – мин, Бондюгтан – Фаилә, Флера, Миңнур; Зәйдән – кранчы рус хатыны, калганнар – Казаннан. Еллар үткәч кенә, Казанның танылган интеллигенция вәкилләре белән булганымны аңладым.

Җитәкчебезне Мәһди, диделәр. Озын буйлы, сөйкемле, университетта укыта, доцент. Экскурсияләрдә пионер лагеренда, консерв заводында, Болгариянең Социалистик Хезмәт Геройлары белән очрашуларда бергә булдык. Бу курорт дигәне гел ялдан

тора, һәркем үз иркендә йөри, кояшта кызына, диңгездә коена. Шунысы бик нык истә калган: Мәһди барыбызга да ачык йөзле, мөлаем, беркемне дә кисәтеп йөрмәде, ә менә җирән чәчле ханым (аны төркемнең врачы, диделәр), якташларыбызга бер-ике мәртәбә кыек-кыек сүзләр әйткәләде. Шуңамы икән, ул ханымны төштә бик мәзәк итеп күрдем: имеш, Гитлер ниндидер төймәгә баса, төкрекләрен чәчә-чәчә кемгәдер акыра, сүгенә, чәче-башы тузган, күзләре акайган, борын астындагы җирәнгеч мыегы сикерә. Аның янында теге җирән чәчле безнең доктор утыра, имеш, ул – Гитлерның хатыны икән. Иртән кызларга төшемне сөйләгән идем, рәхәтләнеп көлделәр. Шуннан соң аны үзара «Гитлер хатыны» дип йөрә башладылар. Ничек шулай кергәндер, югыйсә, Гитлерның хатыны чибәр Ева Браун икәнен беләм бит инде. Җимерелгән вокзалны күргәч, тетрәнү хисеннән Гитлер төшемә кергәндер, мәлгунь. Төркемнең парторгы Казан медицина институтында философия укытучы Иван Степанович Богуцкий икәнен белдек. Иван Степанович төркемне нык күзәтте: совет туристларының әхлакый йөзен саклау тапшырылган бит аңа!

Күп еллар үткәч, «Без кырык беренче ел балалары» китабын һәм башка әсәрләрен бик яратып, исем китеп укыганнан соң, безнең белән Болгариягә барган җитәкчебез Мәһдинең язучы Мөхәммәт Мәһдиев булуына шикләнмәдем, чөнки аны университетта укытучылар да, студентлар да Мәһди дип йөрткәннәр.

Бу истәлекләрне язу теләге тугач, бар кыюлыгымны җыеп, Гәүһәрия Мөхәммәт кызына шалтыратырга булдым. Гәүһәрия ханым әтисенең 1967 елда Болгариядә булмавын ныклы ышаныч белән әйтте. Көндәлегемдәге: «Җитәкчебез – Мәһди, университетта укыта, доцент», – дигән юллар сәерсетә... Университетта башка Мәһди булмагандыр бит инде?!.

Флора

Флора Гайевна (Таһирова)

Барыбыз белән ачылып сөйләшкән, аралашкан кеше Флора Таһирова булды. Ул бик сирәк профессия кешесе – Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет академия театрында эшләүче врач-фониатр, җырчыларның тавыш ярыларын дәвалый, күзәтә. Татарстан солистлары гына түгел, башка өлкәләрдән дә җырчылар аңа килә икән. Флора – балетмейстер Гай Таһиров белән атаклы актриса Галимә Ибраһимоваларның кызы. Флора төскә-биткә матур, коңгырт чәче бөдрә, зур күзле, ләкин аксабрак йөри. Көн саен диярлек яңа күлмәк кия, таяныр өчен йөрткән зонтигына да күлмәге төсендәге чехол кидертә. Танышкач, кызганган идек. Бер вакыйгадан соң, Флорага караш үзгәрде. Программа буенча безне табигатькә пикникка алып бардылар. Урман аланында гади агач өстәлләр тезелгән, аларга җитен эскәтерләр җәелгән, өстәлләр өстендә балчыктан ясалган кув-

шиннарда куе кызыл төстәге йөзем шәрабе, яшелчә һәм җиләк-җимешләр. Чишмәгә куелган итле шампурларны су агымы әйләндерә. Аланга тәмле булып кыздырылган ит исе тарала... Читтәрәк урнашкан чегән оркестры уен коралларын көйли, тикшерә. Өстәлләр артына тезелешеп утырып, авызларны камаштырган йөзем шәрабын авыз итеп, борычлы-суганлы сарык итеннән пешкән шашлык ашагач, оркестр уйнап җибәрде. Берничә көйдән соң, яшь кенә скрипкачы янына Флора барып басты. Нәрсәдер аңлатты, теге егет башын какты. Менә скрипкачы уйный башлады. Чиста, көчле тавыш белән аланны яңгыратып, Флора җыр башлады: «Аве Мари-йа-а-а!... «Без тетрәнеп киттек, аркадан, чемердәтеп, нәрсәдер йөгерә... Халык, ашаудан туктап, исе китеп тыңлый. Урман да тыңлый... Чишмә дә тынган... Ананың бөеклеген, изгелеген данлаучы Шуберт музыкасы, Флора башкаруында көчле, илаһи аһәң булып яңгырап, җиһанга аша! «Аве Марийа-а-а!...» Флораның моңы көчәйгәннән-көчәя, дога булып, күкләргә ялвара! Без бөек музыка дулкынында йөзәбез... Күңел җырның озак яңгыравын, туктамавын тели... Җыр һәм музыка тынганнан соң, һушка килеп, алкышларга күмдек Флораны! И шатланабыз! Флораның йөзе алсуланган, елмая, зур күзләре шатлыктан балкып яна! Үзенә төбәлгән күзләрдә соклану, гаҗәпләнү күреп, тантана итә! Менә нинди ул! Ходай аңа нинди талант бүләк иткән! Талант – бәхет бит ул! Әнә бит аның җыры халыкны нишләтте! Флораның тавышы опера җырчыларыныкы кебек иде. Мин соңыннан Флораның концертын Казан телевидениесе тапшыруында тыңладым. Ул бик талантлы иде.

Хөрмәтле укучым! Язмышлар гаҗәеп үрелгән, бәйләнгән! Мөслимдә Галимә Ибраһимованың бертуган Илһамия апасы яшәде, аларның бер уллары, дүрт кызлары булып, кызларның барысы да миңа бик таныш. Зәйнәп исемлесен укыттым. Флораның фотосын миңа Казаннан Зәйнәп җибәрде, рәхмәт яугыры!..

Пикник югары кәефтә дәвам итте. Болгар артистлары концерт күрсәттеләр. Биючеләре, барыбызны да чакырып, үзләренең биюләрен өйрәттеләр: җитәкләшеп, аланда зур түгәрәк ясап, «хоро» биедек! «Йөзем суы»ннан кыюланган кызларыбыз пыр тузып биеделәр дә, дәртләнеп китеп, музыкантларга рәхмәтле булып, чегән егетләрен кочаклап үбә башладылар, егетләр – шат, елмаялар: «Спасибо!» – диләр. Кайберләре, парлашып, күздән юк та булдылар. Группабызда матур, яшь хатын-кызлар күп, консерваториядән дә берничә кеше бар иде. Безнең яндарак утырган парторг Иван Степановичның коты очты:

– Кара нишлиләр?! Барыгыз, җыегыз аларны, кайтырга кирәк! – дип безгә, минем кызларга куша. (Иван Степанович, минем укытучы икәнемне белгәч, «тәрбия эшендә» катнашырга тиеш, дип уйлады бугай!)

Кем җыйсың аларны! Музыка уйный да уйный. Башка ил туристлары да, безнекеләргә кушылып, җырлый-бии башладылар. Озын буйлы, тузгыган чәчле, шорты кигән Бельгия егете, зәңгәр күзле Казан Флерасын эләктереп, кош мамыгыдай очырта! Ниһаять, җыелышып беттеләр, автобуска төялдек, берәү дә югалмады, исән-имин кайтып җиттек.

Ахыры киләсе санда ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



ЙОКОХАМА

Мин, тел белмәгәнемә күрә, башта берара Йокохама шәһәрендә яшәп, япон милләтенең гореф-гадәтен күзәтергә, телен өйрәнергә, дигән фикердә идем. Шул сәбәпле, хәтта Япониянең башкаласы Токиога да берничә көн бармадым. Гел Йокохамада һәм әйләнә-тирәсендә йөрдем, өйрәнергә, мәгълүмат тупларга тырыштым. Бик күп кеше күрдем, холыкларын, табигатьләрен өйрәнә алмасам да, үзләрен таныдым. Иртә дә, кич тә күрешә-күрешә, алар белән бер-ике генә булса да сүз алышырга тырышам. Турыдан-туры язып укый торган тел булмаганга, мин япончаны өйрәнер өчен гаять авыр тел, дип уйлый идем. Тик сөйләшүдәге җиңеллек һәм сүз төзелеше ягыннан безнең төрки телгә якын булуы миңа бик нык өмет бирә һәм бик тырышып өйрәнә идем. Мәсәлән, япон телендә бер җөмлә әйтеп, шуны төрки теленә әйләндереп әйтергә теләсәк, сүзләре бер үк тәртиптә тәрҗемә итеә: Ниһон-ну кутунә – вәһ муҗкәси-нәй. «Япон теле авыр түгел».

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Ниһон-ну – Япония, япон; кутунә-вәһ – теле; муҗкәси – авыр; нәй – түгел.

Шулай итеп, бик тырышып япон телен өйрәнәм. Ник дигәндә, кая гына барсаң да, тел кирәк. Авылларга һәм кечкенә шәһәрчекләргә җәяү генә барам, кайтам. Каршыма очраган һәр япон кешесеннән диярлек ни дә булса сорарга туры килә. Шулай тырыша торгач, атна-ун көн дигәндә, Токиога барып кайтырлык тел өйрәндем.

Ул көннәрдә Япониядә халык бәйрәмгә хәзерләнә иде. Шәһәрләрдә дә, бөтен авылларда да бәйрәм алды сөенече, күтәренкелек, ыгы-зыгы булганга, япон кешеләренә дә бераз туктап сөйләшеп торырга мөмкинлек туа иде. Бу нинди хәзерлек, нинди бәйрәм була – болар турында японнарның үзләреннән ишетеп белергә тели идем.

Японнарда реклама юлы белән танытуга искиткеч зур әһәмият бирелә. Бигрәк тә менә мондый зур бәйрәмнәр вакытында, һәркем үз сәнәгатен һәм сәүдәсен танытырга тырыша. Беркөнне иртән иртүк, авылларга юл тоту теләге белән, Йокохамадан чыктым. Шуны күрәм: Йокохама шәһәре байраклар эчендә калган, сөйләп аңлата торган түгел. Шәһәр читенә чыктым. Башта бер автомобиль очрады: эчендә музыка уйный, бөтен як-ягына игъланнар, рекламалар асылган. Моны күреп, әлбәттә: «Бу нәрсә?» – дип сорамый калып булмый. Шулкадәр гаҗәеп нәрсәләр бар: ишен бик сирәк очратырсың.

Бер ун минут үттеме-юкмы икән, бер кешене очраттым: буе телеграф баганасы кадәр иде. Кыска гына буйлы бер япон кешесе ике озын колгага баскан, киеменең җиргә кадәр асылынып торган ак итәгенә рекламалар беркеткән, шулай йөри. Болар, әлбәттә, кешене сөйләшергә, сорашырга мәҗбүр итә торган нәрсәләр.

Ул көнне якынча утыз километр юл йөргәнмендер, шактый авыл күрдем. Японнарның авыллары һич кенә дә безнең авылларга охшамаган. Шундый авыллар бар, алар шәһәрләргә караганда да төзегрәк. Кайберләре исә, анда-монда сибелешкән берничә генә йорттан гыйбарәт, бер тигезлектә берничә йөз йорт булыр һәм боларның нәкъ уртасында гаять зур мәктәп тора. Авыллар буйлап йөргән саен, бар нәрсә турында да сорашып белешергә мәҗбүр булам, ә бу исә минем тел өйрәнүемә сәбәп була иде. Шул рәвешле, авыллар буйлап сәяхәт иткәндә, тел мәсьәләсенең бераз булса да чишелүенә ирешә башладым. Бигрәк тә кыш көннәрендә япон авылларында эш азая икән, шуңа алар минем кебек кешеләр белән аралашуны бик теләп кабул итәләр.

28 ноябрьдә Токиога барырга карар кылдым. Ул көнне иртән иртүк тордым, аяк табаннарыма көч насыйп булсын, Токиога юлга чыктым. Йокохамадан Токиога ярты сәгать саен поезд, биш минут саен трамвай китә. Тизрәк тә барырмын, дип, авыллар аша үтә торган шоссе юлына чыктым. Һава да бик матур. Якынча 35 километр ераклыкта урнашкан башкалага җәяү киттем һәм сигез сәгать дигәндә барып та җиттем.

Юлда барганда авылларда күргән хәлләрне, вакыты җиткәч, тәртибе белән язарман. Биредә кыскача гына шуны әйтәм: япон авыллары, нигездә, безнең татар авылларыннан бик аерылмый. Бер катлы кечерәк кенә өйләр. Тик шунысы бар: япон авыллары бик төзек һәм авыллар арасында шоссе юллар салынган. Бу юллар буйлап баручы матур, ару рикшалар очрый. Ике-өч авыл үтүгә, гаять зур мәктәп күренә.

Нәкъ өйлә җиткәндә, Токио шәһәренә килеп җиттем. Шәһәр читендә, Шинакава станциясе янында урнашкан чәйханәгә кердем, анда бер сәгать тирәсе ял иттем.

Шул бер сәгать эчендә күргәннәрем дә гаҗәпләндерде. Бу – шәһәр чите, безнең Истанбулдагы Топкапы яки Әдирнәкапы кебек. Ләкин биредә тормыш шундый итеп кайный ки, мондыйны безнең Истанбулның Сиркәҗисендә дә, Галатасында да күрә алмассың.

Бу җирдән шәһәр трамвай юлы башланып китә, тимер юл икәү. Электрлы трамвайлар, өзлексез, бер-бер артлы егерме адым ара белән барсалар да, барысы да шыгрым тулы. Шәһәргә бара торганнары да, кайта торганнары да халык белән тулы. Бу кадәр кеше кайдан килә, кая бара, ник болай йөри? Шаккатарлык хәл! Моннан бер кырык адым читтәрәк поезд тимер юлы үтә. Ул да шәһәрне коршап диярлек йөри, поездлар ун минут саен үтеп тора. Поезд юлы да икәү: поезд берсеннән килә, икенчесеннән китә.

Шул ук вакытта рикшага утырып йөрүчеләр дә аз түгел. Бер рикша үтеп китте дә артыннан карап калдым: номеры 11862 иде. Димәк, шәһәр эчендәге рикшаларның саны бик күп. Минем кебек җәяү йөрүчеләр дә аз түгел, агач башмакларын шакылдатып йөгереп диярлек үтеп китәләр. Бигрәк тә хатын-кызлар йөгерә. Боларны күреп, гаҗәпләнмичә мөмкин түгел.

Ул байраклар белән бизәлгән урамнар! Кайбер йортлар өстән аска бер кат күлмәк кидерелгән кебек торалар. Телеграф баганалары да нәкъ шулай ук бизәлгән. Ул махсус хәрәкәт итә торган игъланнар, музыка белән автомобильләрдә йөртелә торган рекламалар – болар барысы да игътибарны бик нык җәлеп итә, бөтен нәрсә җанлы кебек тоела.

Шәһәр буйлап кичкә кадәр йөрдем. Урамнар бик киң, ике тарафка да йөри һәм электр белән эшли торган трамвайлар, бөтен җирдә халык ташкыны. Кич бер ашханәгә кердем, бераз сөт эчтем, икмәк-фәлән белән тамагымны туйдырдым. Бераз шунда утырып ял иттем. Биредә дә кеше бик күп. Ашханә кечкенә генә, ләкин искиткеч ару. Бөтен җиргә камыштан үрелгән келәм җәелгән. Бар кеше дә аяк киемен сала, без мәчетләрдә утырган шикелле утыралар. Һәр кешегә утырыр өчен мендәр бирәләр. Болар ризыкларын ике таяк белән тотып ашыйлар. Ашханәдә эшләүчеләрнең барысы да хатын-кыз. Сәгать тугыз тулганда ашханәдән чыктым. Бөтен шәһәр электр уты белән яктыртылган иде. Урамда очраган бер полиция кешесеннән: «Бу кайсы җир?» – дип сораган идем, ул: «Шимпаши», – дип җавап бирде. Токиода бу иң атаклы урамнарның берсе икән.

Бер сәгать тирәсе биредәге халык ташкынына түзеп йөрдем. Әле сулга, әле уңга китмәкче булам, ләкин бераздан, йөргән җиремдә йөрүем яхшырак икәне аңлашыла.

Төнге сәгать 11гә кадәр йөрдем. Сәгать 10нардан соң, халык азая башлады, агач башмакларның шакылдавы да кимеде. Шулай булуга да карамастан, урамнардагы халык, җанлылык Йокохама белән һич тә чагыштырырлык түгел, Токиода чынлап та тормыш кайный иде.

СӘҮДӘ ИГЪЛАННАРЫ-РЕКЛАМАЛАРЫ

Япония бу яктан Аврупа белән дә чагыштырырлык түгел иде. Биредә бөтен сәүдә реклама, таныту һәм игълан белән бара.

Мин Йокохамада да рекламаларның күплегенә бик гаҗәпләнгән идем. Аннары Йокохамадан Токиога кадәр машина юлының, поезд һәм трамвай юлларының һәр ике ягы да төрле төсле, рәсемле игъланнар белән бизәлгән булуын күреп тагын бер гаҗәпкә калган идем. Тик Токиода бу кичке рекламаларны күргәннән соң, юлда килгәндә күргәннәрем боларның «баласы» гына булып калды. Биредә электр уты белән яктыртып язылган игъланнары булмаган бер генә йорт, бер генә бина да таба алмассың. Йортларның ишекләре, урамдагы телеграф баганалары, махсус игълан алачыклары, күктә эленеп торган игъланнар – чынлап та шаккатарлык иде. Бигрәк тә Җиндән исемле бер япон кешесе бер дару уйлап тапкан, халык арасында бик мәшһүр булган бу даруга «Җиндән дару төймәсе» диләр. Әлеге кеше бары тик реклама өчен генә дә елга 350000 йен акча тота икән, бу якынча 40000 лира дигән сүз. Токиода ул кешенең

© The New York Public Library

адмирал киеме киеп төшкән фотосурәте белән бергә игъланы эленмәгән бер генә урам да юк. Урамнардагы бөтен игъланнар, рекламалар ел әйләнә электр утлары белән яктыртыла икән.

Бу даруның үзенчәлегенә килсәк, ул кешенең сулышын сафландыра, авыз исен китәрә икән. Авыз исен китәрә торган бер дару уйлап тапкан һәм җитештерә торган кеше бары тик игъланнары өчен генә дә елга 40000 лира тота икән, аңлашыла булса кирәк: Япониядә бу дару күпме кулланыла һәм бөтен япон милләте авызларын хуш исле итәр өчен никадәр акча тоталар!

Бөтен Япониядә – ир-атмы, хатын-кызмы – кесәсендә бер тартма «Җиндән дару төймәсе» булмаган бер генә кеше дә күрә алмассың. Төркиядә сигарет ничек булса, Япониядә «Җиндән даруы» шулай: һәрвакыт, һәркемнең кесәсендә әлеге дару бар.

Дәрәҗәле, зур сәүдәгәрләрнең игъланнары тагын да тантаналырак, тагын да аллы-гөллерәк, тагын да шаккатыргычрак. Боларны күргән кеше, башка бернәрсәгә дә карамыйча, бары шулар белән генә дә вакыт үткәрә ала. Ул автомобильләр, музыка, уен-көлке белән таныту, игълан итүләр ташкын кебек ага, әйтерсең лә дөнья үзе рәсми демонстрациягә чыккан. Сәгать 11дә Шимпаши урамыннан станциягә таба юл алдым. Станциягә килүгә, поездга утырдым да Йокохамага кайтып киттем.

Бик арыганмын, кайтып урын-җиргә ятуга, көндез күргәннәрем турында уйлана-уйлана йоклап та киткәнмен.

Иртән торгач, бераз язуларымны яздым, бераз тел өйрәндем. Телне һичшиксез булырга тиешле бернәрсәгә охшатасым килә, чөнки тел булмаса, кешенең хәле бик мөшкел. Тел белмәсәм, минем хәлем рус шәркыять белгечләренең хәленнән дә битәррәк булачак.

ЯПОННАРНЫҢ БӘЙРӘМЕ

Бүген – японнарның бик зур бәйрәме. Дөресен генә әйтсәм, японнарда бәйрәм башка халыкларның бәйрәменә һич кенә дә охшамаган.

Көнбатышта яшәүче халыклар, бәйрәмдә ял итәбез, дигән булып,

кибетләрен, эш урыннарын бикләләр, завод-фабрикалар эштән туктый, ял итә. Японнарда исә, киресенчә, бәйрәмдә бөтен кеше көне-төне 24 сәгать буе туктамыйча сәүдә итә. Ул көн өчен махсус сәүдә урыннары ачыла. Моннан тыш, бер генә завод-фабрика да эшеннән туктамый, киресенчә, җитештерүчәнлеген арттыра гына төшә. Бер япон кешесе: «Бәйрәм – сөенеч көне. Минем эшем алга китеп, ул көнне 1 акчага гына булса да артыграк табыш алсам, тагын да сөенәчәкмен», – ди. Бу хакта фабрика эшчеләре белән дә сөйләштем: «Бәйрәм көннәрне эш күбрәк тә була. Ул көннәрдә эш хакыбыз да күпкә артыграк түләнә. Без бик канәгать калабыз», – диделәр.

Аврупалыларда исә, бушка вакыт үткәрү, эчеп исерү, бурычка керү – бәйрәм була. Японнар ул көнне барлыгына 1 акча артык барлык өсти алса – ул көнгә сөенеч һәм бәйрәм көне, диләр икән.

Менә шул сәбәпле, японнарда мондый зур бәйрәмнәрдә кибетләр төнлә дә эшли. Бу бәйрәмне кайда үткәрермен икән, дип уйланып йөргәндә, таныш кешеләрем арасыннан Ниҗи исемле бер сәүдәгәр:

– Бүген Токиога барам, теләсәгез, бергә барырбыз, – диде.

– Бик теләп, бик шатланып, – дип җавап бирдем.

– Трамвайларда кеше бик күп була, поезд белән барырбыз. Бераз иртәрәк кузгалсак, яхшы булыр. Соңгы бер-ике көндә кеше бик күп, бүген исә бигрәк тә күп булачак.

Урамга чыктык, мин яшәгән җирдән станциягә таба җәяү киттек. Урамнар халык белән тулып ташкан. Станциягә көч-хәл белән барып җиттек. Биредәге халык ташкынын исә сөйләп аңлатырлык түгел. 10 минут саен бер поезд китеп тора, шулай булса да, без поездга утырганчы берәр сәгать үткәндер. Вагонга кергәч, көчкә генә утырыр урын таптык. Нәкъ сәгать бердә Токиога килеп җиттек. Әле станциядә үк Ниҗи җәнапларын югалттым һәм берүзем калдым. Станциядә трамвайга утырдым да Вину бакчасына киттем. Урамнарда кешеләрнең күплегеннән трамвай бара алмый, акрын-акрын хәрәкәт итә иде. Вину бакчасына бары сәгать икегә генә барып җитә алдым. Биредә дә кеше аз димәс идем, тик бакча бик зур, киң, шул сәбәпле, сизелми.

Кайчандыр, бу мәйданда йөз меңләгән кеше катнашында берлек килешүе төзелгән. (Вину бакчасы турында аерым бүлек булачак. – *Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе*). Бер урында ораторлар, чыгып, зур төркем булып җәелгән халыкка мөрәҗәгать итеп сөйлиләр. Мин бер тапкыр бөтен бакчаны йөреп чыктым.

Аннан соң сарайга якын гына урнашкан Хибих бакчасына таба киттем. Монда да халык ташкыны, бөтен җирдә милли көйләр ишетелә.

Бу бакча шәһәрнең нәкъ уртасында урнашкан, биредәге халыкның сыйныфы да башкарак. Күбесенчә – яшьләр. Модалы аврупача киенгән кешеләр бик күп, аврупа кешеләре дә аз түгел.

Монда Йокохама кешесе булган бер таныш укытучыны очраттым. Бу кеше бераз русча да белә. Азрак сөйләшкәннән соң, миңа: «Әйдә, моннан урамга чыгыйк. Хәзер бөтен министрлар һәм илнең зур кешеләре сарайга Микадо җәнапларын бәйрәм белән тәбрикләргә киләчәкләр. Үткәннәрен карап калырбыз», – диде.

Акрын гына Кандабаши урамына таба киттек. Килеп җиткәч, юлга якын бер урынны сайлап шунда бастык. Рикша арбалары сарайга таба агыла иде. Бу рикшаларның ике кеше тартып баручылары да, өч кеше тартып баручылары да бар икән. Җигүле ат арбасында баручылар бик сирәк күренә. Дәүләт кешеләре һәм илнең зур шәхесләре барысы да сарайга килделәр.

Басып торган җиребездә берәр сәгать тамаша кылганнан соң, кабат Шимпаши урамына юл тоттым. Анда «Кокомин» газетасының баш мөхәррире Токотоми җәнаплары белән күрешергә киттем. Газета идарәсе зур герблар белән бизәлгән, матур, купшы лампалар, ишектән керүгә, музыка, милли көйләр ишетелә. Токотоми җәнаплары рәсми киемен кигән, эш башында булуына карамастан, мине урамнан керә торган ишеккә кадәр үк килеп каршылап, хөрмәт күрсәтте.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

ЗАМАНЕ ИҖТИҺАД МӨНКАРЫЙЗМЫ, ДӘГЕЛМЕ?

Габдулла Буби


عبدالله بوبی
زمان اجتهاد منقرضمی دگلمی؟
ناشری: ملت
Казань
ЭЛЕКТРО-ТИПОГРАФІЯ
Миллятъ
1909.

بسم الله الرحمن الرحيم
زمان اجتهاد منقرضمی دگلمی؟
عقول بشر کون بکون ترقی طابقان وبو ترقینک آث...
ایک جاهل وایک احمق آدملرنک بیله کوزلرینی قاماش...
درجه‌ده کورنوب طورغان بر زمانده بو سؤالنی صو...
و «قرآننی فهم فقط ایسکی کشیلره مخصوصدر، آنلر منقرض...
زمان، قیامته قدر بونداین آدملری یاکادان طودرماس ز...
نه قدر سفالت ایسه، آنکا جواب ویرو قصدیله آلتون...
عمرنی ضایع قیلمقلقده حقیقتده شول‌قدر سفاهتدر. لکن...
نه‌وقت حقیقت کوبونچه طورغانی وار؟ کاشکی اگر حقیقت...
خیاللر آره‌سینه کروب غایب بولماسه ایدی، علم اسمندن...
وهملر یازلماز وبزده بو رساله‌نی قارالاماغه مجبوریت...
ایدک. اساسی عقل ایله فکردن عبارت اولان وهر برحکمن...
فکرگه خطاب ایدن اسلامنی اجتهاد حریتندن تقلید بو...
آطارلر و کتاب ایله سنت بتونلای جیمریلوب بونلر او...
وفلاننک سوزی قائم بولور دیوب کیمنک خاطرینه کلو...
اگرایش خاطره کلور درجه‌سنده گینه قالسه ایدی، او...
قایغرماز ومسلمانلر باشینه بو بلالرده کلماز وصبیلر آنا...
راقی ایچوگه قدر هر برقباحتلرینی کورکام صانادقلری...
صوگغی لریمز ایسکی‌لرنک، مقصد وغایه‌لرینی برده آ...

Буби Г. «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме?»

«Нәрсә сөйләгәннәренә кара, кем сөйләгәненә карама». Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә хөрмәтле китабында: *«Шундый колларыма сөенеч бир, ул колларым сүзне ишетерләр дә, ул сүзнең күркәмрәгенә иярерләр, бу сыйфаттагы коллар Аллаһының хаклыкка күндергән коллары. Шулай ук бу сыйфаттагы коллар – саф акыл ияләре»* [Коръән: 39:17-18], – дигән. Шуның өчен дә имам Газали, тәкълидтән чыгып, һәрбер мәзһәбтән дәлиленә карап сүз алуны мөкаллидләрнең тәлфыйк[1], дип әйтүләренә каршы «Мөнкад минәд-даләл» исемле китабында тәкълид түбәнчелегеннән тикшерү урынына менүен бик шатланып, рәхмәт белдереп язган. Дөрес, бик мәгълүм мөкаллидләр тәлфыйкны хәрам, диләр. Ләкин аның хөрмәтенә нинди дәлил бар? Әгәр бер кеше дәгъва кылса, рәхим итсен! Безгә күрсәтеп карасын. Боларның һичбер дәлилләре юк, фәкать болар Аллаһ Тәгаләнең: *«Яһүдләрдән Тәүратны белмәүчеләр дә бар. Алар ата-бабадан калган ялган хорафат сүзләрне генә беләләр. Алар хакны белмиләр, мәгәр, ялган, ясалма динне хак дин дип төшенәләр һәм шул сукыр төшенүләре белән эш кылалар»* [Коръән: 2:78], – дигән адәмнәре кебек. Китап әһелләренең галимнәре дә китапларын үзгәрттеләр,

*Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында. Текст хәзерге әдәби телгә якынайтылып бирелә.
[1] Тәлфыйк – төрле мәзһәбтәге карашларны бергә кушу, җыю, берләштерү.

төрле ялгыш аңлатулар белән Аллаһ хөкемнәреннән чыктылар. Үз хыялларын барлыкка китереп, шуны китаплары каршысында игътибар иттеләр. Туры юл вакытындагы элекке изге буын кешеләре белән мактандылар һәм шуны үз бәхетләренә җитә, дип уйладылар. Шул сәбәпле, аларның диннәре нигезеннән чыкты, бозылып бетте. Без менә бу хәбәрләрне укыйбыз, аларны мыскыл итеп көләбез, бик гаҗәпләнәбез. Әмма үзебезнең аларга тәмам ияргәнебезне һәм әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәламнең: *«Сез һичшиксез үзегезгә хәтле яшәгәннәрнең гадәтләренә хәтта һәр карыш, һәр терсәк буе кадәр иярәчәксез»*, – дигән сүзенә дәлил булуыбызны бер дә сизмибез. Бу аятьләрнең ялган тәкълидкә дәлиллекләрен, әүвәлгеләр йөрәгенең шуңа туплануын, ул вакытта наданнан, галимнән ышануны фәкать дәлил белән хөкемнәрне тик риваять белән алуларын һәм, дәлилсез диелсә, ничек [аңа] һич тәкълид кылмаганнарын бер дә акылыбызга китермибез. Дөрес, шәригать туры юлда булучы акыл иясенә иярүдән тыймыйдыр, ләкин үз артыннан ияртүченең дәлилен белмичә торып, аның туры юлда булучы акыл иясе икәнен каян белергә кирәк? Шуның өчен дә Аллаһ Тәгалә югарыдагы аятьләрдә, ата-бабаларына дәлилсез ияргән адәмнәрне гаепләгәннән һәм хурлаганнан соң: *«Коръәнгә ышанмаучы яки аның хөкемнәрен тотмаучы кяферләрнең мисалы бер кеше тарафыннан кычкырып чакырылган хайван кебек. Ул хайван тавышны ишетеп, чакыруны белсә дә, башка сүзнең мәгънәсен белми. Шул хайван сыман, кешеләр хак сүзне ишетүдән саңгыраулар, хак сүзне сөйләүдән телсезләр һәм гыйбрәтләрне күрүдән сукырлар – шуның өчен Коръәнне һич аңламаслар»* [Коръән: 2:171], – дип, бу чагыштыруны китергән. Ягъни бу мөкаллидләрнең хәле куй белән көтүче хәле кебек. Көтүче бер сүз, бер тавыш бирсә – куйлар килгән, башка бер аваз белән [бирсә] – киткән һәм бу тавышлардан һичбер нәрсә аңламаган, килү-китү сәбәпләрен һич белмәгән кебек, дәлилсез бер ышануны таныган һәм аңлатмасыз бер фикыһны кабул иткән адәмнәр дә килү-китүдән [башка] бернәрсә дә аңламаслар. Бу аять бик ачык күрсәтә ки, акылсыз тәкълид – кәферләр эше; динне дәлил белән белмәгән, бәлки коры тану белән кабул итеп алган адәм бу аять буенча мөэмин түгел. Иманның максаты – хайванны бәйләгән кебек, адәмне бер багана, бер мәзһәбкә бәйләп кую түгел, бәлки кешеләрнең акылларын гыйлем һәм мәгърифәт дәрәҗәләреннән югары менгезү. Димәк, менә бу адәм хәерлекне – хәерлек дип белеп эшләр һәм начарлыкны – начарлык дип, начар тәмамлануын белеп, кире кагар.

Димәк, бу вакытта безгә алга киткән милләтләрне исламга чакыру да мөмкин булыр. Әгәр без бүген алга киткән милләтләргә: *«Менә безнең шәригатебез бу: мөҗтәһидләр тарафыннан төзелеп беткән, Коръән белән хәдисне аңлау вакыты узганлыктан, сез боларны аңламассыз! Шуның өчен сез, Коръән белән хәдискә каршы булса да, фәкыйһләр сүзен алачаксыз һәм заманыгыз файдасына муафыйкмы, түгелме – бер дә карамыйча, шуның белән гамәл кылачаксыз! Менә сезнең мөселманлыгыгыз шушында һәм адашуыгыз моның капма-каршысында»*, – дип әйтсәк, боларның исламга мәхәббәтләре төшәрме? Болар, үз акыл һәм фикерләрен үтереп, элекке фәкыйһләр сүзенә баш ияргә һәм үзләрен ахмак һәм юләр дияргә риза булырлармы? Боларны Күһистаниларга, Вәлвәлиҗиләргә ничек ышандыру кирәк? Юк, болар элекке фәкыйһләр сүзе белән түгел, бәлки акылга сыешлы юл белән йөриячәкләр. Әгәр динебезне, тәкълид ияләре уйлаган кебек, болай тар бер рамка эчендә күрсәтсәк, ул вакытта кая алга киткән чит милләтләрне үзебезгә, исламга якынлаштыру; киресенчә, үз арабыздан мәгърифәтле адәмнәребезне дә (Аллаһ күрсәтмәсен) исламнан биздерәчәкбез һәм үз аягыбызга үзебез балта орачакбыз. Димәк, боларны ислам даирәсендә җыю һәм милли көчебезне куәтләү өчен безгә тиеш булган нәрсә – исламны тикшереп, асылындагы гадилегенә кайтару һәм һәркемгә үз акылынча

аңларга рөхсәт бирү. Менә бу вакытта мөселманнар Аллаһ Тәгалә: *«Без китап биргән кешеләр Аллаһ китабын хак уку белән укыйлар, һәр сүзенә ышанып гамәл кылалар, алар хак мөэминнәр»* [Коръән: 2:121], – дип мактаган кебек, тышкы ягына катмаслар, тәкълидләргә ябышмаслар, хыяллар һәм карашлар белән канәгатьләнмәсләр, серле Коръәнне аңларлар, йөкләмәләр файдасын һәм кануннар хикмәтен белдерерләр, иске фикерләрне изгеләштермәсләр. Димәк, боларның иманнары куәтләнеп, дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырлар. Болар Аллаһ Тәгаләнең: *«Аллаһ китабына ышанмаучылар – һәлак булучылар»* [Коръән: 2:121], – дип гаепләгәне кебек, диннәрен аңламыйча, төрле тәкълид һәм уйдырмалар белән измәсләр, бидгать төрләре һәм гадәтләр тоташтырып, бозмаслар, үзләре фикерләрләр, ләкин башкаларны үз фикерләренә чакырып, фикер хөрриятенә каршы төшмәсләр. Бәлки һәркем Аллаһ китабы, Рәсүл сөннәтенә кайту максатында булыр, элекке имамнарның сүзен нигез [итеп] тотып, Коръән белән хәдис төрле ялгыш аңлатулар белән аларга яраклаштырылмас, бәлки аларның сүзе Китап белән Сөннәткә муафыйк булса – кабул ителер, юк икән – кире кагылыр һәм сәхабәләр белән табигыйннарның, мөҗтәһид имамнарның: *«Каршылыклы иҗтиһад мәсьәләләрендә һәркемгә хөррият»*, – дигән сүзләре белән дә гамәл булыр. Дөрес, бу вакытта, ихтимал, мәзһәб һәм каршылыклар күбәер, ләкин әүвәлге гасыр мөҗтәһидләре кебек фанатизмсыз булган вакытта низаг һәм аралар өзүдә һич мәгънә булмас. Димәк, бер адәм акыл иясеннән булдымы, иҗтиһад мәсьәләләрендә үз фикере белән гамәл кылыр, Коръән һәм Сөннәткә чакырган адәмнәрдән нәфрәтләнеп качмас һәм аны бозыклыкта, көферлектә [гаепләп], сүкмәс. Фәкать мөмкин кадәр һәрбер нәрсәне аңларга тырышыр, булдыра алганча көч куяр һәм шәригать дәлилләреннән шәригать хөкемнәрен чыгару өчен кодрәтен сарыф итәр. Элеккеләрне олылауда һәм соңгыларны күтәрүдә арттырып җибәрмәс. Тәфсир гыйлемендә, хәдис гыйлемендә элеккеләр ирешкән дәрәҗәгә ирешү мөмкин түгел, димәс һәм белер ки: кайберәүләр мөҗтәһид булу өчен тәфсир гыйлемендә, хәдис гыйлемендә һәм болар туктаган гарәп гыйлемнәрендә тирән белем иясе булуны һәм кешеләр гадәтләреннән хәбәрдар булуны шарт дисәләр дә, Мохтар Шатыйбиның «Мүвәфәкат»ында әйтелгән кебек, гарәп гыйлемнәренең текстын һәм стилен аңлап, шәригать максатларын белү җитәдер. Шуның өчен дә мөҗтәһид [китергән] бер хәдиснең сахих (дөрес. – А.Г.) һәм зәгыйфь булганлыгы кебек, иҗтиһад чыганагы булган фәннәрдә дә мөҗтәһид булмаучыга иярүне дөрес күргәннәр. Хәтта имам Әбү Хәнифә дә бердәм рәвештә танылган мөҗтәһид була торып, аның заманында, аеруча Гыйракта хәдис риваятьләре күп булмаганлыктан, хәдисләрдән бик азын гына белергә бәхетле булган. Аллаһ Тәгаләнең бар иткән нәрсәләрендә булган сөннәте көн саен прогресста, шуның өчен дә, диннәрнең ахыры булган ислам иң камил дин булганлыктан, бу заманда элеккеләр дәрәҗәсендә, бәлки алардан галимрәк кешеләрнең бар булуы бик мөмкин һәм Аллаһ Тәгаләнең кодрәтенә һәм сөннәтенә бик муафыйк. Шуның өчен әфәндебез [Мөхәммәд] галәйһиссәлам: *«Кем безнең әмеребез булмаган нәрсәләрне сөйләсә, шулар кире кагылыр»*, – дип, дин турысында Аллаһ белән Рәсүленнән башкага таяныч юк икәнлекне аңлаткан кебек, дүрт имам үзләренә тәкълидтән тыйганнар. Әбү Хәнифә белән иярченнәре: *«Безнең сүзләребез белән, аларны без кайдан алганны белмичә, фәтва бирергә беркемгә дә рөхсәт ителми»*, – дигәннәре кебек, икенче бер урында Әбү Хәнифә тагын: *«Әгәр минем сүзем Китап һәм Сөннәткә каршы булса, сез аны ташлагыз!»* – дип аңлаткан. Мәлик бине Әнәс әйткән: *«Мин адәм булганлыктан, савабым да, ялгышым да булыр, шуның өчен сез минем карашым хакында фикерләгез! Әгәр Китап белән Сөннәткә муафыйк булса – тотарсыз, юк икән – ташларсыз»*. Шулай ук бер мәртәбә имам Мәлик Хәрам мәчетендә хәдис сөйләгән вакытында Пакь

бакчага (пәйгамбәр (с.г.в.) җирләнгән урынга. – А.Г.) ишарә ясап: *«Фәкать бу кабер иясенең сүзе кире кагылмас. Башкаларның һәммәсенең сүзе кире кагылыр»*, – дигән. Имам Шафигый да: *«Хәзрәти Рәсүлдән башка һичкемгә дәлилсез ияру дөрес түгел»*, – дигән кебек, имам Әхмәд тә: *«Динеңдә һичкемгә тәкълид кылма! Рәсүлебез белән сәхабәләреннән риваять кылынган нәрсәләрне генә тот!»* – дигән һәм шулай ук бер урында: *«Миңа да, Мәликкә дә, Шафигыйга да, Әүзагыйга да һәм Сәүригә дә тәкълид кылмагыз, бәлки алар алган җирдән (дәлилдән) алыгыз!»* – дип аңлаткан.

Менә дүрт имам үзләренә тәкълиднең дөрес булмавын бердәм рәвештә белдергәннәр. Болар иҗтиһад кылырлар һәм карашыбыз шушы дип бәян итәрләр, ләкин һичкемгә, моны алу тиешле, дип әйтмәсләр иде. Теләгән кеше алыр, теләмәгән кеше – юк, һәркем ихтыярлы иде. Әбү Хәнифә: *«Бу минем карашым, әгәр бер адәм моннан хәерлене китерсә, мин аны кабул итәчәкмен»*, – дигән кебек, имам Мәлик тә, Һарун әр-Рашидтә адәмнәрне «Әл-мөваттаә» белән гамәлгә көчләү турысында киңәшендә: *«Рәсүл сәхабәләре мәмләкәтләрдә таралдылар, һәрбер кавем алдында башкалар ишетмәгән хәдисләр бар»,* – дип, аннан тыйды. Имам Шафигый да: *«Әгәр бер адәмгә Рәсүл сөннәте билгеле булса, ул сөннәтне һичкемнең сүзе белән кую – дөрес түгел»,* – дип хәдис кабул итүендә үз сүзен ташларга киңәш итәр һәм үз шәкертләрен үзенә тәкълидтән тыяр иде. Имам Әхмәд тә үзенең фәтваләрен язудан һәм җыентык төзүдән баш тартыр иде. Болар үзләренең кайбер хөкемнәрдә хата кылачакларын бик ачык белерләр һәм бик ачык әйтерләр иде, болар һичбер вакытта үз фәтваләрен: «Менә бу хөкем катгый рәвештә Аллаһ белән рәсүленең хөкеме», – дип әйтмәсләр иде. Әгәр Әбү Хәнифәнең хөкеме билгеләнгән Аллаһ хөкеме булса, аңа Шафигый да, Мөхәммәд тә, Әбү Йосыф та һәм башкалар да – һичберсе каршылык кылмаслар иде. Әгәр ахыргылар уйлаган кебек, остазны олылау дип әйтү аның һәрбер сүзен һәм һәрбер фигылен дәлилсез, хәтта дәлилгә каршы булып, тәкълидтән гыйбарәт булса, иң элек сукырларча тәкълид кылган [кешеләр] Мөхәммәд белән Әбү Йосыф булырлар иде. Сез, мөкаллидләр! Остазыгызны олылауда арттырып: *«Изге ул, хата кылмас»,* – дип сез дә иң надан бер ахмакка сукырларча тәкълид кыласыз һәм пәйгамбәрләрдән башка һичбер изгенең хатадан азат түгеллеген хәтерегездән чыгарасыз һәм кыйбланы, күзе күргән вакытта да күзенә ышанмыйча, йолдыз белән нәтиҗә чыгарган адәм кебек кыланасыз. Аңлы күзегез белән шәригать дәлилләрен күрә торып, аннан качасыз һәм фәкыйһлар сүзенә тәкълид кыласыз! Шул ук вакытта, фәкыйһлар сүзен күргәндә шул үз күзегез иде, сез ышана торган кәлям китапларының һәрберсендә акыл гыйлем сәбәпләреннән санала торып, сез шәригать дәлилләрен аңлау турысында акылның гыйлем сәбәбе булуын инкяр итәсез! Бу сәбәпле, үзегез дәгъва кылган бу китапларга һәм бу хатасыз адәмнәргә тәкълидтән чыгасыз, сез үзегез бу имамнарга тәкълид тиешле, дисез. Шул ук вакытта, боларның, элекке заман изгеләренең: *«Һичкемгә тәкълид дөрес түгел»,* – дип бердәм рәвештә кабул ителгән фикерләренә һәм иҗмагларына каршы киләсез! Үзегез бу дүрт мәзһәбтән чыгу дөрес түгел, дисез, үзегез исә: *«Алардан соң [һиҗри белән] бишенче гасыр ахырына кадәр иҗтиһад бар иде»,* – дип әйтеп торасыз! Хәтта бишенче гасырдан соң да бик күп галимнәрнең иҗтиһадлары тапкырлык дәрәҗәсендә нык булган нәрсәләрдән: Тафтазани «Хашия-и Гудади»дә әйткәндер ки: *«Кавем сүзеннән, фәкыйһ мөҗтәһид булмыйча һәм мөҗтәһид фәкыйһ булмыйча, күз алдына китермәү аңлашыла, мөфти фәкыйһ булырга тиеш иде»*. Димәк, мөҗтәһид булуы да мәҗбүри булырга тиеш. Хәтта шафигыйлар казыйга да мөҗтәһид булуны шарт иткәннәр, хәнәфиләрдә иҗтиһад иясеннән булмаган казыйны, иҗтиһад иясе булган мөфтинең кул астында булса гына, билгеләү дөрес, дигәннәр, «Һидая» [китабы] казыйның иҗтиһад иясеннән булуын шарт иткән. «Шәрхе һидая» «Мохтасарел-

викая» һәм «Мөлтәкый әл-әбхәр» [китаплары] иҗтиһадны фәкать яхшырак шарт дисәләр дә, «Фәтхел-кадыйр» [китабы]: *«Мөҗтәһид булмаган кешенең хөкеменә ияру Шафигый, Мәлик, Әдһәм мәзһәпләре һәм безнең галимнәребездән Мөхәммәд алдында дөрес түгел»*, – дип аңлаткан. «Мәҗмәгыль-әнһәр» [китабында] «Фәтх»тән: *«Карар кылынган кануни караш нигезендә: мөфти – ул мөҗтәһид »,* – дигән сүзне тапшырган. Димәк ки, мөҗтәһид булмаган кеше казый итеп билгеләнүнең дөреслегендә капма-каршы фикерләр булса да, мөҗтәһид булмаган кешене мөфти итеп билгеләү бердәм рәвештә дөрес түгел. Димәк, әгәр шулай икән, мөфтиләр һәм казыйларны хезмәткә билгеләү һичбер вакытта бетмәгән иде. Шуңа күрә иҗтиһад заманы да һичбер вакытта бетмәскә тиеш. Шуның өчен дә «Фәтхел-кадыйр» [китабы]: *«Фикыһны галим, китап һәм хәдис иясе, сәләтлелеге яхшы, кешеләр гадәтләрен белгән адәмнең иҗтиһад итүе вәҗиб, һичкемгә тәкълиде дөрес түгел»*, – дип катгый [рәвештә] әйтелгән.

Сез, мөкаллидләр! *«Дүрт имам бик борынгы һәм үзләренә иярүчеләр бик күп, димәк, аларның сүзләренә ышану тиеш»,* – дип, күплек һәм борынгылык белән дәлил эзлисез! Шул ук вакытта, әгәр дөреслек күплек һәм борынгылык белән булса, насаралык һәм аннан күбрәк мәҗүсилек дөрес булырга тиеш иде. Ихтимал, сез әйтерсез: *«Табиб дару үләннәренең табигатьләрен (сыйфатларын. – А.Г.) тәҗрибә кылырга йөкләнгән булмаган кебек, без дә өлешчә хөкемнәрдә иҗтиһад белән йөкләнмәгәнбез»,* – дип, ләкин табиб тәмам аңлашылган һәм табибларның бердәм фикере белән хасил булган нәрсәләрне генә яңадан тәҗрибә кылырга йөкләнмәгән; әмма тәмам аңлашылып җитмәгән нәрсәләрне, хаклыкка ирешү өчен, кабат тәҗрибә кылып карарга, анысына тырышу һәрбер табибка тиеш. Безнең имамнарыбыз исә бик күп каршылыкларга кергәннәр, тәһарәт, гаурәт каплау мәсьәләләрендә дә бердәм фикергә килмәгәннәр; хәтта Шафигый иярченнәре: *«Шафигый, элекке мәзһәбен куеп, яңа мәзһәбкә кайтты»,* – дигәннәре, хәнәфиләрнең Әбү Хәнифәдән бер мәсьәлә турысында капма-каршы сүзләрен сөйләгәннәре кебек, бу имамнарның һәрберсе бер вакытта бер хөкемне кылып, икенче вакытта аңа бөтенләй башка икенче хөкемне биргәннәр. Димәк ки, болар хөкемнәрне кылып, катгый дип карау дәрәҗәсенә һич якын килмәгәннәр. Шуңа күрә дини хөкемнәрне караган һәрбер акыл иясе шәригать дәлилләреннән үзе нәтиҗә чыгарырга тиешле. Дөреслеккә ирешсә, ике саваплы, хата кылса, бер саваплы булыр. Димәк, кешенең хөррият һәм ихтыяр хикмәтләрен саклап, хөкем чыгару белән шөгыльләнүе үз-үзен хаталы булу мөмкинлеге белән әсир итүдән хәерлерәк. Димәк, мөкаллидләрнең: *«Заман ерак киткән, тикшерергә безнең кодрәтебез юк. Шуның өчен дөрессезлекне бездән артык белгән һәм хатасы бездән азрак булган элекке бер имамга тәкълид дөреслеккә якынрак»,* – дип әйтүләре – ялган сүз һәм ялгышлыгы да үз-үзләренә мәгълүм. Чөнки элеккеләр каршылыклы фикерләргә кергән нәрсә дә – бер тарафны, сезнең әйтүегезчә, дәлилсез, хәтта шәригатьнең ачык текстына каршы булса да, алуга өстенлек бирү, хәтта кире кагылган өстен күрү һәм Аллаһ йөкләмәгән нәрсәне йөкләү.

Ихтимал, сез, мөкаллидләр тагын әйтерсез: *«Әгәр без Китап, Сөннәт һәм иҗмагтан дәлилен тапмаган бер нәрсәне шәригатебездән санамасак, гыйбадәтебездә дә, мөгамәлә итүебездә дә шәригать хөкемнәре бик тараерга [мөмкин] һәм хокукый эшләребез дә шәригать җавабы белән бәйләнгән булмыйча, һәрберебез гыйбадәт һәм мөгамәләләр өлешләрендә фикеребез белән гамәл кылырга мәҗбүр булырга тиешле булабыз. Шул ук вакытта, мөгамәләләр тәртибе тәртип булмаудан хәерлерәк»,* – дип, ләкин сез үзегез дә, бәлки аңларсыз ки, тәртип кәгазьгә тәкълид кылуда түгел, бәлки иҗтиһад һәм хөррияттә. Гыйбадәт һәм мөгамәләләрдә, бер мәзһәбтә булмаса, дүрт мәзһәб арасында каршылыксыз бер мәсьәләгез юк ки, хәтта тәкълидегездә тәртипфәлән күз алдында булсын. Әгәр иҗтиһад һәм хөррият юлын тотсагыз, шәригать

дәлилләрен карар, заман хәлләрен һәм урын табигатенә муафыйк булган якны ихтыяр кылыр [идегез] дә, бу тәртип юклыктан котылыр идегез. Дөрес ике-өч адәмнең сүзләренә туры килгән гамәл чикләнмәгән адәмнәрнең сүзләренә туры килгән гамәлдән асатрак төсле күренә, шул ук вакытта, хакыйкатьтә, ике капма-каршы булган сүз арасын җыю нәкъ үзе шикелле үк капма-каршы сүз арасын җыю кебек мөмкин түгел. Шул ук вакытта, сезнеңчә дә иҗтиһад заманы [һиҗри белән] бишенче гасыр ахырына кадәр үтмәгәнлектән, сез ияру дөрес күргән мөҗтәһидләр дә чикләнмәгән. Шул ук вакытта, бу әмер турысында һичкем гади фикере белән эш йөртүе мөмкин түгел, бәлки Китап белән Сөннәткә һәм яхшы кешеләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу вакытта мөҗтәһидләр бер урында җыелып, күпчелекнең карашлары белән хөкем һәм карар бирүләрендә, кая капма-каршы сүзләр, бәлки ике капма-каршы сүз чыгарга да мөмкин түгел. Менә бу вакытта ун гасыр элек узган кешеләрнең исәпләре белән йөрү ахмаклыгы ихтыяр кылынмас, халык һәм җәмгыятьнең югары катлавы карашында изге шәригатьнең кадер-хөрмәте китмәс, Бохара халкы кебек, Мәхкәмәи шәргыядән качып, Иван хөкеменә бару булмас.

Сез Аллаһ йөкләмәгән нәрсәләр белән үзегезне йөкләп маташасыз! Әгәр исламда мәгълүм йөкләмәләрдән күбесе хәерле булса, Аллаһ Тәгалә аны игътибарсыз калдырмас һәм сезне аннан тыймас иде. Шул ук вакытта, Аллаһ Тәгалә бер урында дингә караган эшләр турында: *«Китапта һичнәрсәне язмыйча калдырмадык»* [Коръән: 6:38] – дип, дини әмерләрне тәмамлаганын сөйләгән хәлдә, тагын бер урында: *«Менә бүген динегезне төзеп бетереп тулы иттем, бирәсе нигъмәтләремне дә ислам дине белән бергә биреп бетердем һәм риза булып ислам динен сезгә ихтыяр кылдым»* [Коръән: 5:3], – дип, Аллаһ йөкләмәгән нәрсәне йөкләүдән тыйган.

Менә Аллаһ Тәгалә сезгә булган хәерлекне өйрәтте. Заман белән урынның каршылыгы сәбәпле, төрле булган хөкемнәрне сезнең өйрәнүегезгә һәм ихтыярыгызга куйды, хәтта кеше тормыш гамәлләрен мөбах[2] дип белеп эшләсен! Тәкълид тәкъдирендәге кебек, Аллаһ әмеренә ирештемме, юкмы дип дулкынламасын! Һәрбер заман һәм һәрбер урынга мөнәсәбәт булган хөкемнәр кылып, катылык һәм тарлыклардан котылсын! Ләкин сез болай кылмадыгыз! Бәлки бөтенләй Аллаһ әмеренә каршы [булдыгыз], тәкълид сәбәпле харап булдыгыз! Нәкъ яһүд һәм насара юлларына иярдегез! Боларның да папа һәм монахлары, дин исеменнән төрле катылыклар кылдылар да, кешеләрне изеп, хайваннан ким бер дәрәҗәгә төшерделәр, болар нишләсәләр – [кешеләр] шуңа иярделәр. Халыкка фарыз һәм илаһи китапларны карау, хәрам һәм очаллалык мәгънәләрен исәпләү көферлек иде. Европага Әндәлүс мөселманнары аркылы гыйлем, мәгърифәт керә башлагач, гыйлем белән берләшүе мөмкин булмаган насаралыкның югары катлау янында кадере бетте, гыйлем ярдәмчеләре һәм насаралык ярдәмчеләре арасында бик дәһшәтле, канлы вакыйгалар узды, ахырдан, гыйлемнең насаралыкны җиңүе белән тәмам булды. Менә хәзрәти Гайсә галәйһиссәламнең дине, үзгәртелеп, гыйлемгә каршы бер хыянәткә сугылганы өчен, шушы кызганыч хәлгә очрады. Менә боларны белергә һәм тәкълидтән, ислам гыйлемгә каршы, дип әйтүдән тәүбә кылырга кирәк иде! Ләкин, кызганыч ки, сез шул юлда һаман дәвам итәсез! Шушы бозык юл белән исламны сакламакчы буласыз, әгәр сез бу юлда дәвам итсәгез, насаралык башына килгән бәлане (Аллаһ күрсәтмәсен) ислам башына китерәчәксез!

Текстны басмага филология фәннәре кандидаты
***Айдар Гайнетдинов** әзерләде.*

Ахыры киләсе санда ■

[2] Мөбах – тыелмаган һәм боерылмаган эш, ул гамәлне үтәсәң дә, үтәмәсәң дә ярый.

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

ХАТИРӘТ [1]

Сәгыйть Сүнчәләй

Партанет, 19 октябрь, 1919 ел

Мин Кырымдамын. Ялта өязе Партанет авылында. Аюдаг төбендә. Хуҗалык йапиюрем[2]. Партанет – Кырым авылларының, хосусан диңгез буендагы авылларның иң кечкенәсе вә минем нәзарымда иң гүзәледер. Утыз чамасында өе бар. Өч йөзләп кешесе бар. Мәлчәэм[3] Сабин Гарифның өендә... илһ[4] .

Русиядән аерылдыгыма биш ай тула. Казаннан яңача май 22сендә киткән идем. Казаннан вә әтрафыннан занымча бизгән идем. Әмма туган ил газиз икән шул. Монда яшәгәндә бу ачык беленде. Хәзер Казанга, Уфага, хосусан Хвалыйнга бару бер хыял төсле генә күренә. Анда калган таныш вә дуст сималары хәзер гаять газиз тоела. Шул Галимҗаннар, Әмирханнар белән кочаклашып күрешер идем бер, дип уйлыйсың.

Кырымга килгәннән бирле, кулыма һич каләм тотып, тукта, ни дә булса языйм әле, диелгәне юк иде. Шимди тәмам йирләштем. Димәк, яза башлаячакмын. Иншa Аллаһ, әдәби әсәрләр дә яза башлаячакмын. Әлегә кадәр илһам да килгәне юк иде, яхуд килсә дә, мин белмәгәнмен. Фәкать зиһенемдә бәгъзе бер шигырь парчалары гизә иде. Әмма ул парчаларга һич кызыкмыйм. Алар бары да йалы[5] буйлап арабада

[1] Хатирәт – хатирәләр, истәлекләр. Текст басмага Зөфәр Рәмиев әзерләгән «Сәгыйть Сүнчәләй. Әсәрләр һәм хатлар». (Казаан: Тат. Кит. нәшр., 2005. – 367 бит) дигән җыентыктан алынды.
[2] Йапиюрем – итәм.
[3] Мәлчәэм – тору урыным.
[4] Илһ (ила ахириһи) – һ.б.
[5] Йалы – яр.

килгәндә сикергәләнгән фикер кисәкләредер. Әмма минем гаям[6] башкадыр. Минем гаям – китап язудыр, әсәр язудыр. Парчалар заманы башымдан кичкән булса кирәк ки, аларга мәхәббәтем дә буйлә юктыр.

Мин бу көнгә кадәр хәятемне тәртипсез рәвештә үткәрдем. Симферопольдә шәраб эчеп, Саглимаримы, Салгирмы – ниндидер бер кечкенә елга аркылы күпердән үтүдән, мәсирәмезнең[7] пианосыннан[8], бер бетмәс вальсыннан башка бер шәй япмадым[9]. Сәяси хезмәт... әһәмиятсез иде, затән сәламәтлегем дә аңар җитәрлек түгел иде. Соңра төзәлә вә анда пляжда кызынып ятудан, обедка йөрүдән, бакчада улашмактан[10] башка шәй белмәдем. Әмма аннан (каралудан башка) бер кач тәэсират алдым. Әүвәлән, Хәнифә – шәфыйка[11] ханым. Минем Кырым кызын беренче күрүем иде. Соңра «Россия» мосафирханәсендә бер һәфтә[12] мусыйкы тыңлап яшәдем. Бу гаять күңелле һәм кәдәрле[13] иде. Соңра тәфтиш[14]-фәлән... Төркия хольясе[15]. Капуданнар[16] илә күрешү илһ. Аннан соң Ялтага килдем. Ялтаның молы. Алушта. Яһудияләр. Сәрхуш егетләр. Иллюзион «Бонжури». Фәләстин балалары. Жанна. Луся. Эскрипкәдә бер көй иҗадым. Фазыйлә. Хәят ханым белән таныштык. Янә Ялта. Ялтада бер ай микъдары хәят. Тозсыз хәят. Казанлылар илә кичерелгән бер төн – бакча сәхнәсендә рояль өстендә куну.

Соңра Кечек Ламбат. Анда бер һәфтә. Җәяү Алуштага бару. Кечек Ламбаттан Партанетка төшү. Ахирел әмер газиз Партанетта калу. Хәер, Симферопольдә бер шигырь язып быраккан[17] идем. Фәкать шул.

Шимди язарга керешәчәкмен.

Ватанга хатлар яздым, әмма ирешәчәклегенә ышанмыйм.

Партанет, 28 октябрь

Һаман язарга керешкәнем юк. Ниятем – пьеса язу. Әмма зиһенемдә, мөгаен, бер мәүзугъ[18] юк. Шигырь язудан имтинагъ итәм[19], чөнки яхшы яза алмам дип куркам. Бер көн сызгалап карадым. Әмма мәгънәсез булды һәм җаным гаять сыкылды[20]. Газаплану дәрәҗәсенә җиттем. Минем әүвәлдә дә газапланган төннәрем бар иде, ләкин бүген булмаса, иртәгә яза алырмын өмиде белән йобана идем, әмма монда йобаныч алырлык бер кеше дә, бер шәй дә юк. Якын адәм юк. Милләттән ерак тору мәгъкуль тоела. Затән, мин милләттән шимди сакынам[21]. Хвалыйн, Мастак һәм Уфа өязендәге авыл вакыйгаларыннан соң милләт юк ул. Бар гөруһлар, дияр булдым. Бар халык, гафил гавам. Казан Печән базарының милләтеннән дә инсан бизәр булды түгелме? Гавам Гейне дидеге кебек либеральный түгел, бәлки ифрат либеральный һәм хәтта кырмызый[22]. Әмма гавам – көтүдер, консерватордыр. Хаким мотлактыр. Көтүлеге белән бергә залим падишаһтыр.

Партанетның кышы башланды. Яңгырлар яугалый. Көн саен кунакка йөрим. Җәвиз, йөзем ашыйбыз. Туйлар-фәлән... бүген хәстәлек хис итеп ята идем. Мич як-

[6] Гая – теләк.
[7] Мәсирә – юл.
[8] Пиано – биредә: моңсу, тыныч
[9] Япмадым – эшләмәдем, тапмадым.
[10] Улашмак – эшләмәк.
[11] Шәфыйка – шәфкать туташы.
[12] Һәфтә – атна.
[13] Кәдәрле – сагышлы.
[14] Тәфтиш – тикшерү (тентү).
[15] Төркия хольясе – Төркия турында уйлау.
[16] Капудан – капкачы (таможня хезмәткәре, чик сакчысы).
[17] Быраккан – ташлаган.
[18] Мәүзугъ – тема.
[19] Имтинагъ итәм – тыелып торам.
[20] Сыкылды – сыкранды.
[21] Сакынам – читтә торам.
[22] Кырмызый – кызыл.

тым, ис чыкты, башка тиде, ахрысы. Янә открыткалар яздым, әмма җитәчәкме соң! Әниләргә һәм Мәстүрәгә яздым. Укыйм «Мәгълумате әдәбия». Күпреле әсәре. Аһ, теле! Бәгъзе сәхифәләре һич аңлашылмый. Гомумән, бөтен китабыннан бер шәй аңламак, ягъни ядта калдырмак мөхаль булыр[23], ахрысы. Бу, шөбһәсез, телдәндер. Гыйбарәләре: мәсәлән, «Вәкаигы харикыльгадә вә мөшәүвәшә[24], гарамият[25] мөттәһид, фөтүхате[26] гаклим тәхәүвелате иҗтимагыя[27] бер кәлимә илә ифадә иделиюр[28]...» Яшәсен безнең Казан теле! Хакыйкатән! Тәбәррүк.

Бәни әсфәр кауменең (кытайларның) Яурупага кырмызый байрак белән һөҗүм ихтималлары сөйләнелде. Бөек хадисәнең муаффәкыятьлеге[29], әмма җиһанны тетрәтеп зур инкыйлаб ясавының никадәр тәэсире вә сәмәрәле булуы сөйләнелмәде. Татарларның өмидләре дә шул этрафта, кызыл инкыйлабтыр. Ислам галәменең бөтен азатлыгы шуңа багълыдыр.

Сүнчәләй

Партанет. Хәятем яхшырды. Башка бүлмәгә күчтем. Сабыя ханым тәрбия итә. Декабрь керде. Әмма һавалар көзге һавалар. Ягъмур. Ул булмаса, җәйге һава чыгачак. Эссе булачак. Декабрь булса да, йөзем, айва, армуд, хөрмә вә алма ашыйм. Эскрипкә – бөтен юанычым. Алуштада иҗат итдекем көйне яратып чалам[30]. Балаларга «Тәфтиләү» («Кайт, әй, нәнес...») һәм «Гөлчәчәк» («Карадыңыз кайда йөр...») үгрәтдем. һәр көн Мәстүрә ядыма килә. Аһ, дим, ул да монда булса иде! Хәят ханым һәрвакыт картада Мәстүрә хакында фал ачып карый. Аңар юл чыга, бер гаскәри адәмнән, агыр сүзләр ишетеп, алдана вә кайгыра. Гашыйкының сүзләренә дә яна, көя илх.

Шигырь яза башладым. Акчурага хат яздым. Тазара башладым. Мәхмәт Әмин шигырьләрен укыйм. Дантенең «Җәһәннәм»ен укымактамын. Иптәшләр /.../

2 декабрь, 1919

Иптәшләр килә, дип, милләт тә куана. Алар якынлаштылар. Мин, алар килсә, /.../ барыр идем, Ватан берлән хәбәрләшер идем, әнием белән һәм Мәстүрә белән. Ялтага барып килдем, хәстә ятам. Бернәрсә дә яза алмавыма кайгырам. Ялгыз өмидем: Ватанга кайтып язу. Хәл юк. Декабрь, 26. Бүген тышта яз кебек һава иде. Кояш кыздыра. Балкунда рәхәтләнеп газеталар укып утырдым.

Сүнчәләй

Иптәшләр Кырым эченә керделәр. Гаять куанам. Кардәшләр хәлен белермен вә чакырсалар, кайтырмын дип куанам.

«Пәйгамбәр» вә «Кайгы» шигырьләрен яздым. Көннәр гаять җылы. Аз чык, кар бар иде. Бөтен көн вә кичәләр /.../

Яшәсен олуг әмәлле[31] ләшкәрләр[32].

***Сүнчәләй,** 25 гыйнвар*

<...> Яхшы фикерле ачлар (?)! Дантенең «Чистилище» вә «Рай»ын укый башладым».

Иптәшләр килмиләр. Мин дә күңелсез, моңсыз утырам. Яңгырлар ява. Ят ил биздерә башлады. Ай, биздерә башлады! Ялгызлык, ялгызлык бик фәна! Ватан-

[23] Мөхаль булыр – мөмкин булмас.
[24] Вәкаигы харикыльгадә вә мөшәүвәшә – гадәттән тыш һәм катлаулы вакыйгалар.
[25] Гарамият – мәхәббәт маҗаралары.
[26] Фөтүхат – яулап алулар.
[27] Тәхәүвелате иҗтимагыя – иҗтимагый үзгәрешләр.
[28] Ифадә иделиюр – аңлатылыр, әйтелер.
[29] Муаффәкыятьлеге – уңышлылыгы.
[30] Чалам – уйныйм.
[31] Әмәлле – ышанычлы, өметле.
[32] Ләшкәр – гаскәр.

га кайтсаң да ятсаң иде. Бал ашасаң... Март уртасы, әмма көзге җилләр исә. Бездә шимди яхшыдыр... Верхарнның «Зори»сын яза башладым. Бер пәрдәсе бетте. Соңра «Олуг җәза» (комедия) башладым. Болай, шаярып. Март 12, яхуд 14, юк 15е булса кирәк. «Рус театр тарихы»н укыйм (Варнеке әсәре) һәм В.Белинский «Мәдәнияте гатика тарихы» һәм тарихы нидер...

Кавказдан качтылар, унар парахуд һәр көн хәстәле вә зингелеләрне Кырымга ташыды.

Кырымның һәр күшәсе[33] тифле вә милләт белән тулды. Истамбулда инглизләр 300 парламент әгъзаларын вә вәли гаһедне[34] капатканнар[35]. Җәмигъларга каравыл куйганнар. Зур ачлык башланды. Чем хуже – тем лучше, диләр. /.../лар яза башладым: «Сукыр музыкант»ның беренче пәрдәсен, Метерлинкның «Сукырлар»ын бетердем. «Таң»ның 2 нче пәрдәсен башладым. Хәстәлегем каты. 20 март.

Сүнчәләй

Деникин төште. Врангель килде, утырды – тәхеткәме? «Кол»га. һәр кичә утырып язам. Сөвенеп язам / .../ яңа башладым. Портукал ашыйм. Алушта, Жанна, казык. Чәчәкләр. Һәдия. Төшләр. Хисапсыз төшләр. 21-22 март йокысында төш: Мәстүрәне эзләдем. /.../ Иргә чыккан, имеш... /.../ Габидуллина Әминә. Томанлы төшләр. Беренче апрель. Күңелсез. Кол (көл?) кебек калды сәясәт дөньясы. Гәрчә алынган хәбәрләр шаигъ улды[36]. Иҗат хафалары.

Сабияләр, чәчәкләр вә Лермонтов. «Таң»ның...

Тарихы гомуми вә тарихы сәнәгать язмак фикере бар. Ләкин нафилә[37]. Шигырь язылмый.

1 апрель

Туган илгә кайтырга күп калмады, юл ачыла, бары, күп булса, бер ай! Мин бик куанам. Монда яшәр хәл калмады. Сөекле Ватан! (Бәйнәлмиләлченең Ватаны хакында лаф. Кайда ихтилял – шунда Ватан ич миңа.)

«Олуг җәза»ны бетердем. «Таң» 3 пәрдә бетте. Аһ, сабияләр, чәчәкләр. Француз теле. Бүген Аюдагка балалар белән чыктык. Һәдия, Шәмсенур... Хәстәмен.

13 апрель

Юк, өмидләр гүяки бәгъзан[38] кырыла. Юллар ачылмый, иптәшләр килми. Эч поша, һавалар бозык-томанлы, караңгы. Кояш юк. Кояшсыз миңа хәят юк. Нурсыз мин хәстәләнәм. 3-4 төрле авыру белән газапланам. Күз авырый, баш, җигәр[39], эч вә ма әшбәһе[40] /.../

Авылдан бизә башладым. Ашадыгым ялгыз. Сөт, әйберләр юк. Төшләр, төшләр! Алла сакласын! Укыйм психология, франс үз теле вә пәйгамбәрләр – /.../ калмады.

20 апрель

«Олуг җәза»ны бетердем. Уйнамас (?) интереслы булыр дип уйлыйм. Уйнап кына алынсам да, ахыры авыр килде, һәрвакыт шулай. Башта җиңел күренә. Соңра... Французча дәвам итәм. «Таң»ның ахыр пәрдәсен башладым. Кырымда һәлак булабыз, ахрысы. Ачлык, кыйммәтчелек. Кайтырга юл юк. Бәла булды.

21 апрель

---

[33] Күшә– почмак.
[34] Вәли гаһедне – патша варисын.
[35] Капаткан– кулга төшергән.
[36] Шаигъ улды – таралды.
[37] Нафилә – файдасыз, бушка.
[38] Бәгъзан – кайвакыт.
[39] Җигәр – бавыр.
[40] Ма әшбәһе – шуның кебекләр.

Кәеф начар. Өмидләр вәйран оулды. Кырымга зур афәт төште. Кырымның алыш-бирешче, /.../ парачыларына каһәр төште. Әмма безнең кебек мосафирларга да бәласе тиде ләбаса! Хулиган акларның ахмаклыгына, үзен-үзе йобатуына шашарлык... Мин ишетәм, Кырымда калган кырмызыйлар да, ахрысы, бары да спекулянт булып, идеяләрен оныттылар! Анатолийга чыгып китү арзусы да күңелгә килде. Бәлки, андан Кавказ аркылы кайтып булыр, дим.

24 апрель

Эсер Кайбиш кунак булды. /.../ балалар төште. «Тунманнар»га (?) җырлаттык. Моннан килгән мәҗрухлар (ике). Кырымда җәйгә калу арзусы да күңелдә туды. Беренче кәррә чәрәшнә авыз иттек. Рәхәт. Эссе вә ягмурлы һава. Яңа бүлмәгә күчендек безләр.

5 май

Таудан яшелләр төште, икмәк алды. Җитәр кардәшләр арасында кан түгү, диләр. 21-22 май төнендә төшемдә Мәстүрәне күрдем, чиркин[41] күрдем. Картаймыш. 10 ел инде, һаман мәктәпне бетерә алмыйм, инде мөселманча укырга телим, ди. Бите, муены җыерчыкланмыш. Соңра мәнзумә сөйли вә мин сары кәгазьле китап тышына язам. Ахыргы сәтыры[42]: «Яд итмәгез сез бези»... Икенче көн. Икенче көн яхшы күрдем. Нәгыймә яхшы, имеш, Дилбәр. Углы Солтан, имеш, үзе якты йөзле, имеш. Баласын бераз сөйдем дә, син Солтан атлымысың, дидем. Әйе, диде. «Таң»ны язып бетердем. «Психология»не укыйм. Әсәрләр язылып бетте. Әмма һичбереннән риза түгелмен. Шигырь язганым юк диярлек. Ватан сагышыннан тәмам өшәндем. Кимә булса, Төркиягә чыгып, аннан үтәргә уйлыйм. «Фөкара»[43] булдым иштә. Картайдым да галибән[44]. Бу иптәшләргә каты ачуланам... Моннан соң ни җәмәгать, ни милләт, ни сәясәт илә у [...] ашачакмын, һич! Бөтен хәятемне әдәбиятка, музыкага вә театрга багышларга ният иттем. Әмма бәгъзан әдәбиятны пока онытырга да исәп бар. Метерлинк язылды, һәб[45] мәгънәсез.

23 май

Кырымга килгәнемә бер ел булып үтте. Күңелне каты хәсрәт басты. Юл ачылмый. Башка бәла булды бу, [бер юл сызылган, танылмый], (28енә) гүяки ул тиҗарәт[46] ачмыш, без фәкыйрьне дә /.../ Әмма... язылар[47] һәб бетте. чемоданнарга ремонт яптым[48], хәзерләнәм. Бәлки, дим, килеп тә чыгарлар. Керән(?) хисапсыз күп ашалды. Яхшы. Май бетеп бара. Ураза җанны сыка[49].

29 май

Аклар Севастопольне алдылар. Димәк: мануым. Инша Аллаһ, юанам. Рәхәт. Кадира бакчасында истирахәт[50] иткәлим дә кәрәз ашыйм. «Мөсафалы». Укыйм: Челпановның «Ми вә җан»ын. Укып чыктым «Психология»сен. Янә укыйм Котляровскийның Лермонтов хакындагы китабын. Карт кешенең әсәре дә карт була шул. Төшемдә Тукайны вә әшнәләрене күрдем. Мәрхүм гаять ачык йөзле иде. Төштә дә ул ресторанда өстәл янына җирләшкән иде. «Таң»ны карап чыгам.

30 май

[41] Чиркин – ямьсез.
[42] Сәтыры – юлы.
[43] Фөкара – ярлы.
[44] Галибән – ахыры, күрәсең.
[45] Һәб – бөтенесе.
[46] Тиҗарәт – сәүдә.
[47] Язылар – язу эше.
[48] Яптым – ясадым.
[49] Сыка – борчый.
[50] Истирахәт – ял.

Яңа бер әсәр («һаилә») язу һәвәсе килде. Ул да олуг бер революционер. Планын хәзерли башладым. 7 пәрдәле булачак. Ахырында каһарман һәлак була. Кала ялгыз сүзләре вә иманы. Диңгез буе яхшы. Эссе. Укыйм Хәмиднең «Илхан»ын, /.../ «Нәзария әдәбиясе»н дә.

1 июнь

Хакка мең шөкер: кимә килде. Мин дә, Аллаһ насыйп итсә, бу көннәрдә «каршы»га (Анатолийга) сәфәр кыйлачакмын. Ният: аннан Кавказны кичү дә Әстерхан аркылы (бабам каберен зиярәт максады белән) Хвалыйн, Казан вә Уфага бару. Мин бик шатмын. Хәзерләнәм. Языйларым бетте. Укыйм Веселовскийның тәнкыйтьләрен. Яхшы яза. Карт ананың «аһ, мәйнем...» дип җырлап агълаганы онытылмас! Бу серле (?) җаным-тәнем белән Ватанга омтылам. Ләкин Шәрекънең ишәкләрен дә күреп китәргә телим. Шаять, Иранны да күрермен. Ялтада мөгаллим юбилее булды. Шигырь укыдым. («Даһилар»ны һәм «Рәсүлләр»...) 7 июньдә бәйрәм булды /.../. Шакир Мөхәммәдъяров вә Нәҗип-тилеләр белән күрештем. Аллаһ җәзаларын бирде. Яхшы.

10 июнь

Әл дә киталмый хафа чигеп утырам. Кимә Ялтада. Тышта каты җилләр. Күңел өстем авыр, тыгыз. Нишләргә дә белми аптырадым.

Ризага, соңра Карс яки Батуми аркылы Бакуга һәм Әстерханга барырга ният.

14 июнь

Һаман китә алмый торам бит. Бик омтылам да, юк! Хәзер ихтилал шигырьләрен аерым дәфтәргә яздым. «Музыкант»ны һәб уйлыйм. Бераз үзгәртергә телим. Төшләр күрәм. Төшемдә һәрвакыт Ватанны күрәм. 17 июньнән /.../. 18ендә Таһирны сөйдем. Миннән күчтәнәч көтә икән, шикәрле бүләк. Бардым базарга, кердем Шәрәфләр кибетенә. Шәрәф (Гыйльметдин), акчаң юк, дип, бирмәде, бәһале күрсәтте. Минем исә акчам аз яки юк иде. Соңра, кичә төш күрдем. Озын баскычлы китапханәгә мендем, төшәргә дигәндә, юксәктән егылачак вә һәлак булачак идем. Баскыч саллана вә җимерелеп төшәргә хәзерләнә иде, көтепханә сахибен чакырдым, килде чыкты һаман шул Шәрәф. Бу адәм миңа хыянәт итте, ахрысы, дошман! «Баб»ны басмады, ахрысы...

Аллаһ аларга күңелле калдырмас!

Авыл яхшы. Сабыя ханым бик яхшы тәрбияли. Бармудлар, шәфталулар ашыйбыз, тут та ашадык, туйдык.

Сишәмбе, 23 июнь

Бик авыр настроениедәмен. Ике-өч көн инде, һич рәхәтләнә алмыйм. Йокым качты – ашау-эчүдән дә калдым! «Музыкант»ны төзәттем. Челпановның «Мы и душа» – укудамын. Соңра Морозовның «Пророки». Инша Аллаһ, китәрмен дип ышанам. Бу көннәрдә ихтилалга нык катнашу фикереннән ваз кичү нияте белән мәшгульмен. Дим: ватанда да мондагыча яшәргә кирәк. Ихтилалга иштиракым[51] файдасыз (хосусан үзем өчен вә үз хәятем өчен) булыр дип уйлый башладым. Моннан соңра әсәремдә дә исканияләр язарга, беренче нәүбәттә «сәгадәт эзләү» булачак. Моны шул «Музыкант»та үткәрергә хәзерләнәм. Шигырьләрдән парчалар (мәсәлән, «Кайда сәгадәт, кайда ямь?») алырга...

***Сүнчәләй,** 25 июнь* ■

---

[51] Иштиракым – катнашуым.

«ХӨСӘЕН МИРЗА» ТРАГЕДИЯСЕ ТУРЫНДА

Фәтхи Бурнашның бу әсәре 1918-1919 елларда языла. «Аның тәмам булмаган бер нөсхәсе «Һиҗрәт» исеме белән сәхнәгә куела башлаган иде, – дип искә ала автор үзе. – Тулы килеш ул «Җирсезләр» исеме белән Казан театрында куелды[1]. Беркадәр төзәтелгән хәлдә, бу соңгы исеме белән ул 1926 елда сәхнәгә куела башлады»[2]. Бу чорда, ягъни гражданнар сугышының кызган бер вакытында крепостнойлык чорын чагылдырган әсәр иҗат итүенең сәбәбен драматург шулай аңлата: «Ни өчен яздым? «Чөнки бездә шундый бер караш бар иде – янәсе, татарлар арасында крепостнойлык, татар алпавытлары булмаган. Мин бу мәсьәләне өйрәндем һәм шушы пьесаны яздым»[3]. Әлбәттә, мәсьәлә моның белән генә чикләнми. Ф.Бурнаш ерак тарихны революцион вакыйгалар яктылыгында аңларга тырыша, үткәндәге вакыйгаларны сәнгати анализлау нигезендә революцион хәлләрнең мәгънәсен тирәнрәк ачарга омтыла.

Әсәр узган гасырның 20 нче «елларында Казанда Академия театрында, Мәскәү Татар эшче театры һәм Астрахань театрларында зур уңыш белән кат-кат уйнала. Сәхнә осталарыннан Бари Тарханов (Дивана Гаскәр ролендә), Зәйни Солтанов (Хөсәен мирза ролендә), Фатыйма Ильская (Сара ролендә) һ.б. онытылмаслык образлар иҗат итәләр. Матбугатта «Хөсәен мирза» спектаклен «Сезонның иң уңышлы нокталарыннан берсе» дип бәяләгән, «әсәрнең художество ягы чибәр» булу өстенә, «баштан ахырга чаклы ике сыйныф арасындагы көрәш кызыл җеп булып» сузылуы «безнең идеология өчен хезмәт» иткәнлеген әйткән мәкаләләр чыга[4].

Трагедиянең бер үзенчәлеге моннан гыйбарәт. Андый әсәрләрнең күпчелеге вакыйгаларда төп рольне уйнаган персонажлар исеме белән атала («Король Лир», «Гамлет», «Спартак», «Ромео һәм Джульетта»). Татар драматургиясендә дә шулай («Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Җир уллары трагедиясе», «Идегәй», «Кол Гали»). Аларда геройлар уңай, аларның фаҗигале язмышын укучы һәм тамашачы сыкранып кабул итә. Ф.Бурнашның бу трагедиясендә башкача. Ул тискәре герой исеме белән аталган. Хөсәен мирза – крепостной крестьяннарның аянычлы, бәхетсез язмышында төп гаепле кеше. Шуның белән бергә аның үз язмышы да фаҗигале. Автор моны ышандырырлык ситуацияләр тудырып раслый. Ул балаларыннан, аның үз кызы дип алданып, яратып йөргән Сарадан да мәхрүм кала, акылдан яза.

Трагедия беренче мәртәбә Ф.Бурнашның ике томлык «Сайланма әсәрләр»ендә Г.Кутуй редакциясендә басылды[5]. Ләкин ул монда шул заман таләпләренә, коммунистлар партиясе кануннарына буйсындырылып, үзгәртелеп һәм кыскартылып бирелә. Әсәрнең кульязмасы язучының шәхси архивында саклана. Текст журналда шуннан алып басыла.

Татар совет әдәбияты, театры сәнгатенең һәм журналистикасының башында торган, фаҗигале язмышлы (нахакка гаепләнеп төрмәгә ябылган һәм 1942 елда атып үтерелгән) Фәтхи Бурнашның драматургиябез һәм сәхнәбез тарихында якты эз калдырган бу әсәре беренче, асыл варинтында дөнья күрергә, мәртәбәле «Безнең мирас»та басылырга лаек һәм тиеш дип табылды.

Азат Әхмәдуллин, *профессор*

---

[1] «Җирсезләр» пьесасы буенча куелган спектакль белән театрның 1922-1923 елгы сезоны ачыла.
[2] 1934 елның маенда татар драматурглары киңәшмәсендә Ф.Бурнаш ясаган чыгыштан.
[3] Шунда ук.
[4] Кызыл Татарстан, 1927, № 284.
[5] Ф.Бурнаш. Сайланма әсәрләр, 2 томда. – Казан, 1959.

ХӨСӘЕН МИРЗА

Борынгы татар тормышыннан трагедия

Фәтхи Бурнаш

6 пәрдәдә

Катнашалар:

Хөсәен Мирза Асанов – татар алпавыты.

Мәрьям бикә – Хөсәеннең хатыны.

Сара – аларның кызлары.

Муса – бунтарь егет.

Иргали – Хөсәеннең эш башкаручысы.

Гаскәр (дивана) – Хөсәеннең әүвәлге җырчысы.

Гөлбәһар – балаларның әүвәлге сөт анасы.

Бикморза – тегермән караучы (тегермәнче).

Красильников – алпавыт.

Хәдичә.

Шакир.

Солтан.

Ибраһим.

Гайшә.

Габдулла.

Карт.

1 нче карт.

2 нче карт

3 нче карт.

4 нче карт.

5 нче карт.

Әхмәт.

Җәббар.

Хәзрәт.

Сакчы.

Берәү.

Икенче.

Өченче.

Дүртенче.

Бишенче.

Кызлар.

Егетләр.

Казаклар.

Капитан-исправник.

Безнең мирас №8 август 2019

Беренче пәрдә

Хөсәен мирзаның өй алды. Артта ындыр күренеп тора. Сулда өйнең крыльцосы чыга. Уң кулда кое, чүлектәсе күтәрелгән.

Җирдә бүрәнәләр, әйберләр. Уңга киң капка чыга.

Пәрдә күтәрелгәндә сәхнәдә беркем дә юк. Музыка тавышы килә. Вакыт кичкә таба. Беркадәр вакыттан соң, уңнан Дивана чыга – сәләмә киенгән.

Дивана ялгыз.

Дивана *(чыгып)*. Атам юк... анам юк...
Югалган нәсәбем...
Балам юк... чагам юк...
Чуалган исәбем...
Үлем чүпрәгеннән
Уралган җәсәдем...
Шулай көн күрәм мин...
Торам мин – дивана.
(Карана, акрын гына килә.)
Хор *(ерактан)*.
Йөрәгем яна ла...
Күзем кан ала...
Кыз балаларга
Авыр замана...
Абау ла!
Зифа буем михнәт өчен үстеме?
Башларымнан хәсрәт җиле истеме?
(*Сулдан Сара чыга, Дивананың артыннан килә.)*

Сара, Дивана.

Сара. Әй, син, диваначыгым! Син болай кичкә карап нишләп йөрисең? *(Аркасыннан сөя.)*
Дивана. Ходайдан сөрелгән,
Сөрелгән иман...
Йөземнән чөергән
Күзен һәр имам...
Сара. Дивана! *(Нәрсәдер әйтергә тели.)*
Дивана. Әдәпкә, гадәткә.
Торып мин кыям...
Шулай көн күрәм мин,
Торам мин дивана...
Хор. Йөрәгем яна ла...
Күзем кан ала,
Кыз балаларга
Авыр замана...
Абау ла!
Зифа буем хәсрәт өчен үстеме?

Баш очымнан ачы җилләр истеме...

Сара *(Диванaны җитәкләп, җыр арасында).* Әйдә минем белән, дивана! Син тузанга буялып, кырлар карачкысы кебек булып беткәнсең... Әйдә, минем бүлмәмә кер! Мин синең ачыккан карыныңны туйдырып җибәрермен. Бүген дә, сиңа дип әзерләп куйган күчтәнәчләремне алып китәрсең... Әйдә, дивана, кеше-кара күргәнче... әйдә...

(Керәләр. Беркадәр вакыттан соң, тавышлап, Шакир белән Гайшә, егетләр, кызлар чыгалар.)

Шакир, Гайшә һәм башкалар.

(Гайшә чабагач күтәргән, Шакир аны куа, арттан көлешкән тавышлар килә: – Һайт! Тот! Җибәрмә! Әлә-лә! Әттә-тә!)

Шакир. Тотам, барыбер тотам!

Гайшә. Тоталмассың!

Шакир. Тотам, юкка качасың.

Гайшә. Тоталмассың!

Шакир *(тотып).* Ә... Эләктеңме!

Гайшә. Кыланма, дим, Шакир абый, җибәр!

Шакир. Юк, әйтмичә җибәмим!

Гайшә. Җибәр, дим инде...

Шакир. Әйтсәң, җибәрәм... Нигә яшерәсең? Минем чабагачымны алгансың бит...

Гайшә. Китсәнә! Мин нишлим синең чабагачың белән... *(Китәргә тели.)*

Шакир. Тпру! Китәлмәссең...

Яшьләр. Ха-ха-ха.

– Кем кемне!

– Җәгез!

– Бирешмә, Гайшә!

– Шакир, җибәрмә!

Шакир. Әнә... әйттем бит – минеке... мин тәпәсеннән таныйм.

Гайшә. Әй, кыланма сана... Әйтәм ич, бу синеке түгел!

Шакир. Кисмәктер, диген...

Гайшә. Кисмәктер...

Шакир. Чүлмәктер, диген...

Гайшә. Чүлмәктер...

Шакир. Кояштыр, диген...

Гайшә. Айдыр, кояштыр... Әй, китсәнә... Нигә әле син миңа үземнең чабагачым өчен, әйттем исә, кайттым, ай, кояшлар тоттырган буласың...

Шакир. Ялганлаганга күрә! Синең бит үз чабагачың булганы да юк...

Гайшә. Үземнеке булмаса, этинеке бар.

Шакир. Юк, мин таныйм. Бу аныкы түгел.

Гайшә. Китсәнә! Бер чабагачыңа хуҗа була алмагач, егет булып сөйрәлгәнең корсын!

Яшьләр. Ха-ха-ха!

– Чабагачын кызлардан алдырган!

– Егетем чабагачсыз калган!

Гайшә. Икмәктер менә эти чибагачы...

Шакир. Юк... мин беләм... этиеңнеке кыскарак иде...

Гайшә. Кыскарак булса, менә сиңа озынрагы алай булса...

(Чабагач белә суга да, кача.)

Шакир. Эх, юл куяны!

Яшьләр. Ха-ха-ха! Җибәрмә!

– Бүлеп ал!

– Әт-тә-тә!

Кызлар. Гайшә, тоттырма!

Шакир. Тотармын!

Гайшә. Тоткычың сынмасын! Әл-лә-ли! *(Кызлар арасына керә.)*

Шакир. Эх, әрлән баласы... Эләгерсең әле бер эләгүен...

Гайшә (үчекләп). Шакир шакмак, утын тукмак, пыяла бармак, җиз тырнак...

Яшьләр. Ха-ха-ха!

(Бер егет йөгереп керә, уртага баса.)

Егет. Хөсәен мирза! *(Һәммәсе дә баскан урыннарында катып калалар. Иргали керә, кулында камчы.)*

Иргали һәм башкалар.

Иргали. Йөзләрегездән кояш күләгәсе китмәгән, ә сез таралдыгыз да мени әле?

Шакир. Иргали ага, без эшебезне бетердек, картлар безне җибәрделәр.

Иргали. Миннән башка кем сезне җибәрергә батырчылык итә ала?

Барыгыз яңадан урыннарыгызга – мин өйрәтим әле сезгә төн карасында ничек эшләргә кирәк икәнне!

Шакир. Иргали ага, без соң ничек таң ярылгач яңадан чыгарбыз?

Иргали. Шулай... чыгарсыз! Барыгыз!

Х**өсәен** *(артта)*. Әй, ябалак!

Иргали. А, туктагыз! Хәзер Хөсәен мирза монда килә – сез бире калыгыз. *(Артка үтә.)* Әй, сез, әдәм имгәкләре! Кайчаннан бирле бер кибән белән булашып ятуыгыз корсын...

(Хөсәен, Муса, Красильников керәләр, алдан киемнәр күтәреп малай үтеп китә.)

Хөсәен, Муса, Красильников.

Хөсәен. Егетләр, кызлар, берегез дә китмәгез, сез миңа кирәк булырсыз...

Шакир. Тыңлыйбыз, хуҗа хәзрәтләре...

Хөсәен. Рәхим итегез! *(Красильников өстәл янына утыра.)* Әй,

Ябалак! *(Малай чыга.)* Урындык чыгар монда! *(Сара чыга.)*

Текстны ***Азат Әхмәдуллин*** *әзерләде*

Дәвамы бар ■

ГОМӘР БӘШИРОВ *көндәлегеннән*



Гомәр Бәширов. Аккош күле. 1953 ел

Татарстан китап нәшрияты 2011 елда Гомәр Бәшировның «Күңел дәфтәре» исемле көндәлек-хатирәләрен[1] бастырып чыгарды (мәҗмуганы төзүче, кульязма һәм искәрмәләрен басмага әзерләүче – язучының улы, мәгълүм фотограф Зөфәр Бәширов).

Аннотациядә искәртелгәнчә, 1937-1999 елларны эченә алган «Күңел дәфтәре»ндә әдипнең «Сиваш», «Намус», «Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә», «Гыйбрәт» кебек әсәрләренең язылу тарихы, иҗат чорындагы кичерешләре, шулай ук замандашлары – күренекле язучылар, композиторлар, галимнәр турындагы истәлек-хатирәләре тәфсилләп язылган.

Авторның вакыйгаларны шулкадәр төгәл, җентекле сурәтләвенә, шәхесләрнең биографиясенә, холык-фигыленә, иҗатына гаять зур игътибар биреп тукталуына исең китә.

---

[1] Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кульязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 464 б.

Бу истәлекләрне XX гасырның мәдәни тормышына характеристика дип атарга мөмкин булыр иде.

Анда, шулай ук, безне «Очты дөнья читлегеннән» сәхифәсе кысаларында кызыксындырган урыннар да бик күп. Арадан кайберләрен сайлап алып, аларның да аерым җирләрен кыскартып, сезгә, хөрмәтле укучы, тәкъдим итәргә булдык. Гәрчә ул хатирәләрне, һичшиксез, тулаем, калыпка салынган китап рәвешендә уку фарыз...

Якын дусты, олпат шагыйрь Хәсән Туфанның авыру хәл-әхвәлен белешеп, аның үзәк өзгеч көннәрен бәян иткәндә (димәк, аның халәтен кичергәндә!) Гомәр Бәширов болай дип язып куйган: «Бүген иртәдән үк күңел төшенке. Иртә торуга, нигәдер, «озакламыйча үләргә туры килер» дигән күңелсез фикер башка килде. Никадәр эшләгән булып йөрсәң дә, нинди генә эшләр башкарган булып кылансаң да, бу яшьтә сине инде котылгысыз үлем сагалап тора. Син үлемнән беркая да китә алмыйсың. Син үлгәч,ниләрдер үзгәрер, синнән соң дөнья буш нәрсә булып, шыксызланып калыр, дип ялгыша күрмә. Синең үлемең турында ишеткәч, таныш-белешләрең «нихәл итмәк кирәк, вакыт җиткән иде шул», дип уйлаячак. Сине күмәргә барганда, күмеп кайтканда нинди дә булса башка нәрсәләр турында сөйләргә, сине тизрәк онытырга тырышачаклар һәм алар хаклы булачак. Әйләнә-тирәңдә тормыш кайнап торганда үлем турында гына уйлау, гел кайгырып кына яшәү гайре табигый бер хәл бит ул. Чөнки тормыш синнән башка да дәвам итәчәк».

Бу сүзләрдә хакыйкать ярылып ята, билгеле. Ләкин әлеге әдипләр, һичшиксез (күпшы сүзләргә төреп маташу дип санамагыз!), үзләренең бибәһа мирасында, үлемсез иҗатында мәңге яшәячәк...

Киләсе берничә санда татар мәдәниятенең күренекле вәкилләрен яд итәрбез, аларның, күпмедер дәрәҗәдә, тормыш-көнкүрешенә һәм, әлбәттә, үлем-китеменә шаһит булырбыз.

Ул көннәргә исә безне СССР Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәширов кайтарыр.

Рүзәл Мөхәммәтша

Мирсәй Әмир (1906-1980)

Бу арада бик күңелсез хәлләр булып тора әле. 2 июньдә Аккош күленнән кайтып килгәндә, мине ишегалдында Афзал Шамов каршы алды.

– Син бернәрсә дә белмисеңме? – ди.

Безнең өйдә Флүрә[2] авырып тора иде. Мин, ул хакта уйларга куркып, телсез калдым.

– Юк, белмим, – дидем.

Афзал, ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Мирсәй вафат, – диде.

Бу хәбәр минем башыма сыймады, мин аны аңлый алмадым. Әле бит мин кичә генә, әйе, ул үләсе көннең иртәсендә генә аны хатыны Фәүзия ханым белән бакчага барганда, Некрасов урамында очраткан идем. Таза-сау кебек, үз аягы белән трамвайга төшеп бара иде. Бер-беребездән хәл-әхвәл сораштык, һәйбәт кенә сөйләшеп аерылып киттек. Ә шул көнне кичен аны инде сузып салганнар иде. Шулкадәр авыр булды, мин, 4 каттан бер катка гына төшәсе булуга карамастан, бик озак аның квартирасына керә алмый йөрдем.

[2] Авторның килене.

Мирсәй Әмир хатыны Фәүзия белән. 1930-1940 нчы еллар

Мин аны, әле кичә иртә белән генә исән-сау хәлендә күргән кешене, мәет хәлендә күрергә куркам, җаным тайчана, берничек тә аягым тартмый иде.

Ниһаять, үземне җиңеп кердем. Мирсәйнең углы Камил, кызы Гөлшат каршы чыкты. Кече яктан Фәүзия ханымның килеп чыгуы күренде, һәммәсенең күзендә яшь, карадан киенгәннәр. Фәүзия ханым, елый-елый, фаҗиганең ничек башланып, ничек тәмамлануын сөйләп алды:

– Бакчада ул эшләмәде, балалар эшләгәнне генә карап йөрде. Кайттык, ашаган-эчкәннән соң, газеталар карады. Ятып ял итте. Сафа Сабировның китабын укып бетерәсе бар иде, аны укыды. Кичке 5ләр тирәсендәме икән, йөрәгеннән зарланды, нәрсәседер авыртып тора, диде. Корвалол бирдем, нитроглицерин капты, ләкин аларның тәэсире булмады. Врач чакыру турында сүз чыккач, «тиз ярдәм» машинасын чакырма, алар алып китәләр, диде. Махсус поликлиникага чылтыраттык. Ләкин алар кырык минуттан соң гына килделәр. Әмма уколлар кадап карасалар да, ул вакытта инде коткарып калу мөмкин булмаган.

Шул көннең иртәгесен Мирсәйләргә кердем. Мине Мирсәйнең хатыны Фәүзия ханым белән углы Камил һәм кызлары каршы алды. Мирсәйне үзенең кабинетына сузып салганнар. Мин аны берникадәр ачык ишек аша гына күреп калдым. Аны, күмгәнче бозылмасын өчен, врачлар бальзамлаганнар иде. Шунлыктан, битен япканнар, тәрәзәләрне ачык тотарга кушканнар. <...>

Мирсәй белән без, бер үк йортта, янәшә фатирда гына торганлыктан, көн саен диярлек очраша, хәл белешә идек. Күп вакытны җыелышка да бергә барырга туры килде. Байтак вакыт ул такси чакыра, мин дә аның янына утырып бара идем. Ә инде җәяү барырга

Мирсәй Әмир. 1977 ел

туры килсә, ул, юлда бераз гына үрлерәк урын булдымы, туктап, нитроглицерин кабып ала торган иде. Әйтүенә караганда, аның бик сөзәк кенә үр менгәндә дә күкрәге кыса башлый, сулышы тарая, ул аягын атлый алмый башлый торган иде. Дөресен әйткәндә, Мирсәй миннән шактый ук яшь булганлыктан (ул – 73тә, ә мин исә 80 нче яшь белән барам), кайвакыт минем аның турында, «ул үзен саклау өчен бераз иркәләнмиме икән», дип уйлаган чакларым да булгалады. Әмма шулай җыелыш-фәләнгә бергә-бергә йөргәли башлагач, мин аның чыннан да авыру булуына ышанмыйча булдыра алмадым.

4 июнь көнне Мирсәйне күмдек. Аның гәүдәсен Татар академия театрына куйдылар. Өстә бертөзлексез музыка уйнап торды. Аның белән бәхилләшергә халык бик күп килгән иде. Матәм җыелышында (митинг диләр бугай) Гариф Ахунов, Атилла Расих, Башкортстан вәкиле, Марсель Сәлимҗанов, Геннадий Паушкин, Мансур Хәсәнов һ.б. сөйләде. Мансур Хәсәнов аны совет әдәбиятының классигы дип атады.

Зиратка күмәргә баручылар да бик күп булды. Мирсәйне татар зиратының яңа эшләнгән капкасы тирәсендә зур гына юкә агачы янына күмеп кайттык. <...>

***

6 июнь көнне Мирсәй эшләгән һәм яшәгән кабинетта аны искә алу мәҗлесе булып узды.

Мәҗлестә Бакый Урманче, Атилла Расих, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Хәсән Хәйри, Шәүкәт Галиев, Вакыйф Нуруллин һ.б. катнашты, һәммәсе дә диярлек аның истә калырдай сыйфатларын, кылган яхшылыклары һәм аның хатирәсен озак саклау өчен күрелергә тиешле чаралар турында сөйләделәр. Мин дә берничә сүз әйттем. Мирсәй Әмирнең вафаты миңа аеруча авыр тәэсир итте. Мин аның белән әдәбиятка килгән елларда ук, ягъни 30 нчы еллар башында ук, танышкан идем. Хәзерге өлкән буын дип йөртелгән әдипләр – Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники һәм шулар арасында мин дә – без әдәбиятка бер вакытларда килеп, татар совет әдәбиятын бер-беребездән өйрәнеп, бер-беребезгә иҗади ярдәм итешеп алга әйдәдек. Бу төркемдә Мирсәй Әмирнең, бик талантлы иптәшебезнең, үз урыны бар иде. Ул чын күңелдән иҗат итүче, көчле юморист, каләм остасы, бай телле көчле художник иде. Аннан беразга өлкәнрәк булуыма карамастан, минем дә Мирсәй белән киңәшкән чакларым булды. Чөнки ул әдәбиятка миннән элегрәк килгән кеше иде.

Мирсәй Әмирнең миңа бик ошаган тагын бер сыйфаты булса, ул – аның эшендә һәм тормышында, иҗатында һәрвакыт гадел булуы, үзе инанганны турыдан ярып әйтүе иде. Дөрес, гадел булу кайвакыт бик авырга килә. «Туры әйткән туганына ярамаган», дигәндәй, ул гаделлек кайвакыт әйтүченең үзенә кире ягы белән әйләнеп төшә. Әмма Мирсәй Әмир бу өлкәдә нык булды, батыр булды. Турыдан ярып баруы, гаделлек өчен көрәшүе аны бик кыен елларда зур фаҗигаләрдән[3] алып калды. Мирсәй Әмир тормышында халыкчан әдип булып яшәде, халыкчан булып иҗат итте. Ул талантының кадерен белде. Бер генә минутын да, тормышының бер генә көнен дә әрәмгә уздырмады, халык мәнфәгатенә, аның әдәбиятын, гомумән, аның мәдәниятен үстерүгә хезмәт иттерде. <...>

Үлеменә һаман ышанасы килми, исәндер кебек.

1980, 3 июнь[4] ■

---

[3] Утызынчы еллар «тикшерү»ендә кыйналып бетеп тә, ни үзенә, ни башка каләмдәшләренә яла якмый. Нәтиҗәдә, аны аклап, иреккә чыгарырга мәҗбүр булалар. – ***Редакция.***

[4] Язманың икенче өлеше («6 июнь көнне...» дип башлана), күрәсең, соңрак язылган. – ***Редакция.***

ИЗГЕ АНТКА ТУГРЫЛЫК

Шаһинур Мостафин

«Гайнан Кормаш төркеме» әгъзасы Фәрит Солтанбәков. Казан. 25 август, 1994 ел. Мидхәт Шакирҗанов фотосы

Казаныбызның Себер трактында урнашкан Республика онкология үзәгендә ошбу елның май аенда дәваланып ятканда иртәнге якта төшемә данлыклы җәлилче Фәрит ага Солтанбәков керде:

– Шаһинур якташым, син безнең батырларны онытып бетерә күрмә инде. Тиздән – шушы елның 25 августында – җәлилче-кормашчы дусларыбызның Германиянең Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелүләренә 75 ел тула бит! Алар хакында һәрдаим сөйләргә, язарга кирәк. Сиңа без, тынгысыз җанлы эзтабар язучы буларак, зур ышаныч белдерәбез. Моңарчы сынатмадың, киләчәктә дә изге кыйблаңа тугрылык сакла – үлемнәре белән Үлемсезлек яулаган шул шәһит җаннар турында чын хакыйкатьне һәркемнең күңел түренә җиткерергә тырыш!..

Ил агасының әлеге хикмәтле сүзләре мине бик уйландырды. Мөмкинлектән файдаланып, бу юлы яраткан журналыбыз укучыларын иң элек Фәрит Сәхиулла улының тормыш юлы белән якыннанрак таныштырырга уйладым.

1916 елның 15 маенда Украинаның Луганск өязендәге Ирмино шәһәрендә дөньяга килә ул. Аның әти-әнисе – тумышлары белән Казан губернасының Мамадыш өязендәге Югары Ушмы һәм Алкин авылларыннан. 1923 елда алар, Татарстанга кайтып, җиде ел чамасы яшиләр. Данлыклы Түнтәр (Балтач төбәге) мәдрәсәсен тәмамлаган указлы мулла буларак, Сәхиулла хәзрәт Солтанбәковка өязнең төрле авылларындагы мәчетләрдә дини вазыйфалар башкарырга туры килә. Хәләл җефете Гамилә абыстай исә, оста тегүче буларак, җирле халыкны затлы-матур киемнәр тегеп тә сөендерә. Дингә каршы көрәш көчәйгәч, Солтәнбәковлар гаиләсе Казанга, аннан исә якын туганнары яши торган Үзбәкстанга күчеп китә.

Фәрит Солтанбәков биредә авыл хуҗалыгы техникумын, шуннан соң Сәмәрканд дәүләт университетының физика-математика факультетын уңышлы тәмамлый. Шәһрисәбез районындагы урта мәктәптә мөгаллимлек иткән җиреннән аны хәрби хезмәткә – Кызыл Армия сафларына алалар. Шуннан Фәрит сугыш гарасаты эченә кереп чума...

1941 елның 6 июлендә пулеметчы-сержант Ф.Солтанбәков, бер төркем сугышчан иптәшләре белән, дошман чолганышында кала. Шепетовка шәһәре янәшәсендәге дотларның берсендә фашистларга каршы өч көн, өч төн көрәшә алар. Патроннары һәм гранаталары беткәнен сизгәч, гитлерчылар аларга огнеметтан ут ачалар. Нәтиҗәдә, Фәрит, тоташ ялкын эчендә калып, һуштан язып егыла... Аңына килгәндә ул инде дошман тозагында була. Шуннан соң аның өчен искиткеч газаплы әсирлек тормышы башлана. Язмыш Фәрит Солтанбәковны иң элек Гайнан Кормаш, аннары Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Рушад Хисаметдинов, Гарәф Фәхретдинов кебек ватанпәрвәр рухлы гаярь ир-егетләр белән очраштыра. Тиздән Фәрит үзе дә «Идел-Урал» легионында фашистларга каршы яшерен оешманың иң актив әгъзаларыннан берсе булып китә...

1943 елның августында яшерен оешмада кулга алулар башлана. Ф.Солтанбәковны да, Узедом дигән урында «эләктереп», Берлин төрмәсенә ябалар. Ул анда 6 айдан артык утыра. 1944 елның февралендә Берлин Хәрби суды аны, гомерлеккә төрмәгә ябарга хөкем итеп, каторга хезмәтенә озата...

1945 елның апрелендә Ф.Солтанбәковны һәм башка тоткыннарны Америка хәрбиләре коткара һәм бераздан Фәрит, тиешле тикшерүләр – «фильтрация» үткәннән соң, Совет Армиясе сафларында – 27 нче гвардияче мотоукчы полкта сапер-танкист буларак хәрби хезмәтен дәвам иттерә...

1945 елның декабрендә армия сафларыннан демобилизацияләнгәч, Ф.Солтанбәков Үзбәкстанга – Шәһрисәбез шәһәрендә яшәүче әти-әнисе янына ашкынып кайта! Озак та үтми, 1946 елның мартында – ямьле Нәүрүз бәйрәмендә – Фәрит Сәхиулла улы янәшәдәге Карши шәһәрендә үзе кебек мөгаллимлек итүче Мәрвә Шәрифҗан кызы белән гаилә корып җибәрә. Алар 50 ел буе бик тату яшәп, матур гомер кичерделәр. Һәр икесе дә фидакарь хезмәтләре өчен «Үзбәкстанның халык мәгарифе отличнигы», «Атказанган мөгаллим» дигән мактаулы исемнәргә, СССРның хөкүмәт бүләкләренә лаек булдылар. Булдыклы Мәрвә ханым да сөекле иренә бик тә пар килгән иде. Ул педагогия фәннәре кандидаты, дигән гыйльми дәрәҗәгә иреште, «Почет Билгесе» ордены белән дә бүләкләнде.

1996 елның февралендә ирле-хатынлы Солтанбәковлар уллары Фоат, кызлары Венера һәм Флюра гаиләләре белән яши торган Казан каласына бөтенләйгә күчеп кайттылар. Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә рәхмәтләре бик зурдан иде, чөнки ул аларга башкалабызның Хөсәен Мәүлетов урамында яңа төзелгән йорттан бөтен уңайлыклары булган ике бүлмәле фатир бүләк

итте. Әнә шул яңа фатирда бергә нибары 7 ай яшәп калдылар өлкән Солтанбәковлар. 1996 елның 7 сентябрендә Мәрвә Шәрифҗан кызы кинәт кенә үлеп китте. Җанына үтә якын кешесен югалту Фәрит агага да нык тәэсир итте – саулыгы сизелерлек начарланды, әмма кулыннан каләмен һич кенә дә төшермәде.

2002 елның 27 октябрендә безгә кайгылы хәбәр килеп иреште: 87 нче яше белән баручы күренекле җәлилче-легионер Фәрит Сәхиулла улының тынгысыз йөрәге тибүдән туктаган...

Без әлеге легендар шәхесне, барча якыннары белән бергәләп, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, тугрылыклы хәләл җефете Мәрвә ханым янәшәсендә – Самосырово зиратының мөселман өлешендә җирләдек. Аңа багышлап, «Ватаным Татарстан» газетасының 2002 елгы 1 ноябрь санында күләмле язмамны да (мәрсиямне дә) урнаштырдым.

Фәрит ага Солтанбәков татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән «Эш күрсәткән ирне Ил онытмас...» – «Мужество останется в веках...» дигән китабын (Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2001 ел) киләчәк буыннарга мирас итеп калдырды. Батырлык һәм Рухи Матурлык дәреслеге буларак, бәһа биргесез ул китап халкыбызга бик озак хезмәт итәр әле. Җәлилчеләр турында чын дөреслекне белергә теләгән тарихчылар да, язучылар да аны кулларына еш алырлар, үзләрен кызыксындырган сорауларга төпле җаваплар табарлар...

***

Безгә мәгълүм булганча, мөхтәрәм Фәрит Сәхиулла улы күргән-кичергәннәре турындагы истәлекләрен 1953 елда ук яза башлаган. Аның белән, якташлар буларак (безнең Арташ белән Югары Ушмы, Алкин авылларын өч-дүрт чакырымлы кырлар һәм урман гына аерып тора!), узган гасырның сиксәненче-туксанынчы елларында даими рәвештә хатлар алышып яшәдек. Ил агасына һәм җәлилче дусларына кагылышлы язмаларымны республикабызда чыгучы газета-журналларның байтагында, татар календарьларында бастырдым, радио-телевидение тапшыруларында да файдаландым.

Өлкән Солтанбәковлар Үзбәкстаннан Татарстан башкаласына күчеп кайткач, безнең үзара аралашуларыбыз-очрашуларыбыз тагын да көчәйде. Аларның кунакчыл фатирларында сөекле хәләл җефетем Дамирә Рафаил кызы белән еш була идек. Алтын туйларын да, барча балалары, килен-кияүләре, оныклары, якыннары һәм шулай ук биредә һәрчак көтеп алына торган кадерле Рафаэль ага белән Рауза ханым (ирле-хатынлы Мостафиннар) катнашында, зурлап үткәрдек. Кабатланмас шул мизгелләрне чорыбызның атаклы фоторәссамы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт ага Шакирҗанов киләчәктә карар-багар өчен мәңгеләштереп калдырды. Әлеге фоторсурәтләр Фәрит ага Солтанбәковның китабында да үзләренең лаеклы урыннарын алды.

Җәлилче якташымның китабына керәчәк истәлекле язмаларны редакцияләү эшенә үз теләгем белән алындым. Искиткеч кызыклы, тәрбияле-зыялы һәм туры сүзле – гадел шәхес буларак, ул миңа газиз әтиемдәй якын-үз кеше булып әверелгән иде инде.

Ошбу китапны нәшрият өчен әзерләгәндә безгә атаклы эзтабар язучыбыз – җәлилчеләрнең якын дусты Рафаэль ага Мостафин, мөхтәрәм Фәрит Сәхиулла улының данлыклы нәсел дәвамчысы Фоат әфәнде Солтанбәков, бар яктан да уңган киленнәре Альбина ханым Сәяпова (аларның һәр икесе дә – танылган галимнәр һәм әдәбият-сәнгать әһелләре!), булдыклы кияүләре – «Татхимэнергогаз» ябык типтагы



Фәрит ага Солтанбәков күренекле әдипләр белән

акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Илдар әфәнде Хәмидуллин рухи һәм матди яктан зур булышлык күрсәтте. Тәрҗемәчеләребездән Марианна Валишева белән Петр Овчинниковка да бик рәхмәтле без – алар игелекле эшләрен тиешенчә башкарып чыктылар. Нәтиҗәдә, Фәрит ага Солтанбәковның 240 битле әлеге китабы киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты.

Якын киләчәктә без әлеге китапның тулыландырылган яңа басмасын нәшер итәргә җыенабыз. Хәзер исә укучыларыбызны шундагы бер өзек белән кыскача таныштырып үтәбез *(аны, хөрмәтлебез Фәрит Сәхиулла улының татарча-үзбәкчә язмаларын редакцияләп, телдән сөйләгәннәрен дә өстәп, нәшриятка тапшыру өчен шулай ук үзем әзерләгән идем.* – **Ш.М.***)*.

«...1943 елның октябрь ахырларында җәлилчеләр Варшава төрмәсеннән Берлин төрмәсенә күчерелде. Тоткыннарны ташучы машинада Гайнан Кормаш, Зиннәт Хәсән, Абдулла Баттал, Рушад Хисаметдинов һәм миннән башка кеше юк иде (Гарифҗанов Варшава төрмәсендә калды. Аны гомерлек каторгага, Бухенвальд концлагерена җибәргәннәр. Әмма ул, берничә үлемнән котылып, коточкыч газаплар күреп, Туган илгә кайта алган. Бу хәбәрне мин күп еллар үткәч кенә ишеттем...)

Һәммәбезнең кулларында богаулар. Үзара сөйләшергә ярамый. Менә шунда Зиннәт Хәсән нәрсәдер әйтмәкче булган иде, әмма гестапо офицеры шундук аңа коралы белән бәргәләп тә алды. Төрмәдән вокзалга чаклы – «черный ворон»да, Варшавадан Берлинга чаклы – поездда алып бардылар. Вагонда Батталның бер ягында – мин, икенче ягында Хисаметдинов иде. Төнлә белән әкрен генә сөйләшеп тә алдык. Бер җаен туры китереп, Хисаметдинов Батталдан шыпырт кына: «Безне кем сатты икән, белмисеңме?» – дип сорады. Баттал: «Мәхмүт саткан, – диде. – Аннары, нәфрәт белән:

– Мәхмүт, хаин, кызыл перчаткаңны
Юылмаслык канга мангансың.

Сузма кулың безнең күкрәкләргә –
Буең җитмәс, үсми калгансың!» –

дип, күңелендә кайнаган хисләрен сиздерде. Мәхмүтнең безне сатканлыгына шигебез юк иде инде. Ләкин без бернәрсә дә эшли алмадык. Ирек юк, тоткынлыкта ятабыз.

Берлин вокзалыннан Моабит төрмәсенә безне тагын «черный ворон»да алып бардылар. Анда 2-3 сәгать чамасы тотканнан соң – биредә урын булмагандыр инде – безне Вильгельм-штрасседа урнашкан Тегель төрмәсенә китереп яптылар...

Беркөнне төрмә душында мин Кормаш белән янәшә туры килдем. Күрешкәч, ул, миңа карап, әкрен генә болай диде:

– Фәрит дустым, синең ишеткәнең бармы халыкның мондый сүзләрен: «Күк күкрәми – яшен яшьнәми, корбан бирми – халык яшәми...» Без корбан булырбыз инде. Ләкин синең турыда бер иптәшнең дә начар итеп бернәрсә дә сөйләгәне юк. Ышанам, син Туган илгә кайтырсың, атаң, анаң, туганнарың һәм сөйгән ярыңны күрерсең. Без корбан булсак та, безне Ил онытмас, бу эшләр турында халкыма, туганнарыма, Даниямә сөйлә. Бу тарихны яз син!..

Шунда мин: «Әгәр исән кайтсам, үлем сәгатен көтеп ятканда кылган эшгамәлләребез турында сөйгән халкыма сөйләрмен, кулдан килгәнчә язармын», – дип, дустыма ант бирдем. Һәм менә, күп еллар узгач, шул вәгъдәмне үтим...

***

Тегель төрмәсендә, хәрби судтан соң, Гайнан Кормаш «Син – бәхетле» дигән шигырен язып, аны миңа прогулкага чыкканда кулыма бирде. Ләкин соңыннан шигырьләр туплаган блокнотымны немец унтер-офицеры ертып ташлады. Мин кадерле блокнотымнан аерылдым. Ни кызганыч, күпме генә тырышсам да, бу шигырьне искә төшерә алмадым. Шулай да бәхетем бар икән: Рафаэль Мостафинның «Җәлилчеләр» китабын укыганда авторлары билгесез шигырьләр арасында Г.Кормашның шул әсәрен очраттым һәм моңа бик шатландым. Менә әлеге якын дустымның үлемсез шигъри юллары – соңгы истәлеге:

«Сау бул инде, дустым, күрешалмабыз,
Ераклаша безнең арабыз.
Кайнар яшьләр түгеп артыгыздан,
Якты юллар теләп калабыз.

Син – бәхетле, чиксез зур бәхетле,
Син кайтырсың Туган илеңә.
Яшьләй уйнап үскән кырларыңа,
Кара кашлы нечкә билеңә.

Мин каламын монда, төрмәләрдә,
Мәңге сүнмәс хәсрәт эчендә,
Ялгызлыкта, кояш нуры күрми,
Үлем көтеп көндез, кичен дә.

Әйт бәгъремә соңгы сүзләремне,
Көтмә, диеп, сөйгән ярыңны.
Сөйлә аңа үлем тырнагында
Тәмамланган көрәш җырымны.

...Сау бул инде, башка күрешалмабыз
Кулны кулга сузып дусларча.
Кайт Илеңә, туган кырларыңа,
Сөйгән ярың белән шат яшә!

1944 ел».

* * *

Әле исән чагымда – аяк-кулларым йөргәндә, аң-зиһенем чуалмаганда – ошбу көрәштәшләрем турындагы чын дөреслекне, ак-хак сүзне үз авызымнан һәркемнең күңел түренә җиткерәсем килә. Муса Җәлил, Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Рушад Хисаметдинов һәм башка каһарманнарның бөек батырлыгын вакыт яңгырлары кешелек хәтереннән һич кенә дә юып ташлый алмас! – мин моңа тирәнтен ышанам...»

***

...Әнә шулай диеп язган иде үзенең истәлекләрендә кадерле якташым Ф.Солтанбәков. Тынгысыз җанлы Фәрит Сәхиулла улының үзенә генә хас эчке бер кайнарлык, ялкынлы яктылык һәм эчкерсез якынлык, рухи туганлык хисләре белән сугарылган язмаларын кат-кат укыганнан соң, күңелемдә аңа һәм көрәштәш дусларына багышланган өр-яңа шигъри юлларым туды:

Сез – Җәлил, Кормаш дуслары,
Сез алардан көч алган! –
Шуңа күрә Тәмуг утын
Сез исән-сау кичә алган...
Сез бит легион турындагы
Күптән көткән хәбәрне
Алып кайтып, үзгәрттегез
Илдәге күп хәлләрне!
Кара көчләр җиңелделәр,
Балкыды нур-яктылык! –
Җәлилчеләрнең йөзләре
Бердәй китте яктырып!
Сез дә бит, Җәлил-Алиштай,
Батырлык эшләдегез –
Дусларыгызны акламый
Иярдән төшмәдегез!
(Сез Хаклыкның Акбүз атын
Ныклап иярләдегез,
Имансыз-кыйбласызларга
Һич тә иярмәдегез!)
Сез бит гомерегез буе
Дуслар өчен яндыгыз,
Яктыртып кара төннәрне
Һәрчак алдан бардыгыз!
Сездән күчкән җылылыктан
Терелде сулган гөлләр...
...Сезнең хакта, изге җаннар,
Гасыр гасырга сөйләр!.. ■

МӨХТӘРӘМ МӨДӘМИЛ ЯДКЯРЕ

Рөстәм Зарипов

Сүнгән көннәр һаман арта тора,
Кими бара алдагылары.
Туктатасы иде бу елларны,
Тышаулыйсы иде шуларны!
Яшисе дә гел яшисе килә! —
Яшәү ямьлегәме бу дәлил.
Беләсеңме шуны,
Сизәсеңме,
Тоясыңмы икән, Мөдәмил?

Зөлфәт

Инглизнең сәнгать белгече Уолтер Пейтер: «Һәр сәнгать әсәре җыр булырга омтыла», – дигән. Бер, әмма берәгәйле җыр яза алу – зур казаныш. Мөхтәрәм Гомәр ага Бәширов тә халкыбыз күңеленә кайчандыр зурланган «Намус» романы белән түгел, ә «Җидегән чишмә» җыры тексты белән кереп калмагае. Якташым, хакыйкый композитор Фасил

ага Әхмәтовның, Казанның «Божра» атлы мәйданында ахыргы күрешүебездә: «Минем дә халык күңеленә кереп калырлык берәр җырым булыр әле», – дигәне онытылмый. Бу җәһәттән «Безнең мирас» журналы баш мөхәррирен дә төшеп калганнар рәтенә кермәс идем. Аның «Халкым минем» атлы шигырен сабалы якташларым җыр канатларына күтәрде – Айдар Тимербаев көен язды, ә Зөлфәт Зиннуров, кабатланмас музыкаль озатылышта башкарып, милләттәшләребезне таң калдырды, дип санарга рөхсәт итегез...

Язганнары җыр канатларында күтәрелгән шагыйрь Наил Касыймовның бер тезмә әсәрендә: «Дәрдмәнд булу өчен бер китап җитә, ә бездәге том арты том чыгару аша «халык шагыйре», «халык язучысы» исеме алуда ярышучыларның берәр язган юлын кем дә булса хәтерендә тота, кабатлый микән?» – дигән ачынулы бәяләмәсенә юлыктым. Яшерен-батырын түгел, шәхсән үзем дә андыйлар җитештергән рухи азыктан гаҗиз һәм аптырашта, яшь чакта язганнарын, аннары хәзергеләрен укып карыйм, әмма салам тәме дә тоймыйм. Бу – шәхси бәяләү, ихтимал, мин, техник вузда белем алган кеше буларак, әдәбиятның кайбер нечкәлекләрен аңлап җиткермимдер... Алай да халкыбызның, «күпнең кадере юк», «күп сүз– чүп сүз», дигән әйтемнәре тәҗеллеген җуймаска охшап тора. Сер түгел, бүген, каләмзатлар даирәсендә китап, томнар саны, калынлыгы, бүләкләр, мактаулы исемнәр-титулларга, ягъни хакимият хуплавына ирешү буенча игълан ителмәгән бәйге бара сыман. Һәм тугрылыклары рәсми бәяләнү дәрәҗәсеннән чыгып, дәүләт хисабына, кибетләргә кертеп тормый, ягъни зарурлыкларын аныкламый гына китапханә киштәләренә бер төркем тар даирәнең китапларын, томнарын кунаклату матавыгы әлегә дәвам итә. «Әдәби тәнкыйть» дип тамгаланган, чынлыкта оядаш каләм әһелләрен рекламалауга кайтып калган мәкаләләрдә катгый ранжир буенча тезелгән бер төркем әдипләребезнең исем-фамилияләре, һинд мантрасы сыман, укучыны шул төркемдәгеләрнең шәплекләренә инандыруга программалау максатында булып аңлашыла, кат-кат искә алына. Янә килеп, фәннилеккә дәгъва итүче әлеге «жанр»да, үрнәк сыйфатында мәкалә каһарманы иҗатыннан китерелгән өзекләр нигезендә, фәлән-фәлән мөһим фикерләрнең «кызыл җеп булып сузылуы», төгән-төгән чагыштыруларының «ассоциатив тойгы уятуы» билгеләнә һәм башка шундый чачаклау-чуклауларга юлыгыла...

Истанбулда яшәп, бишенче сыйныфта белем эстәүче оныгым Әмирхан, тэквандо көрәше буенча кара билбау алуга ирешә, Бөтендөнья татар конгрессы оештырган интернет-бәйгедә Тукай шигырен сөйләп гран-при яулады, «Ялкын» журналында «Тутый кош хәбәре» исемле фантастик хикәя бастыруы өстенә, атнага бер көн университетка йөреп компьютер программалау серләрен үзләштерә башлады. Анда йөрү бәхетенә ул тест ярдәмендә йөз мөмкинлектән йөз балл җыеп ирешә. Ә быел, укучылар алмашу программасы буенча, Грециядә атна-ун көн белем алачак. Оныгымның әйтүенә караганда, һәр төр эшчәнлекне дә программалап була. Әле мәктәпкә кергәнче, әнисе укыган татар халык әкиятләрен тыңлап: «Син миңа беркем беркемне ашамый торганнарын сөйлә», – дип кызымның игътибарын «Татар халык әкиятләре» исеме белән чыга торган тупламалар эчтәлегенә җәлеп иттергән ул. Баксаң, андагы әкиятләрнең күпчелеге балаларга укырга ярамаслык дәрәҗәдә тозсыз һәм куркыныч икән ләбаса!..

Тискәре бәяләмәне раслау өчен дәлилләрне еректан эзлисе түгел. Шәхси китапханәмдә татар халык әкиятләре исеме астында чыккан тупламалар шактый гына. Иң саллылары – 1977 елда Казанда, Татарстан китап нәшриятында басылган, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты ышыгында дөнья күргән ике том. Соңрак чыккан әкият китаплары да, нигездә, шул томнардагы эчтәлектән

«бии». Соңгы тапкыр сатып алган саллы, катыргы тышлы «Татар халык әкиятләре» китабын Татарстан китап нәшрияты 1989 елны нәшер иткән һәм ул да әлеге томнардагы тәртиптә, «хайваннар турында әкиятләр», «тылсымлы әкиятләр» һәм «көнкүреш әкиятләре» дигән өч бүлектән гыйбарәт. Хайваннар турында әкиятләр бүлеге «Әтәч белән төлке» дигән мәсәлгә тартым мәзәктән башлана. Эчтәлек болай: төлке агач башында утырган әтәчне: «Намаз укыйк», – дип, үз янына төшәргә чакыра. Әтәч: «Агач төбендә йоклаган имамны уят», – ди, ә ул эт булып чыга һәм төлке: «Тәһарәтем бозылды, яңартып килим», – дип, таю ягын карый. Икенче әкият «Торна белән төлке» дип атала. Анысы – мәктәптә үткән И.Крылов мәсәленең игезәге. Өченче әкият «Аю, бүре, төлке» дип исемләнгән. Эчтәлек болай: аю, бүре, төлке, «моннан соң беркемгә дә тимик», дип, хаҗга чыгып китәләр һәм юлда боларга ияргән дөяне буып ыргыталар. Менә бер өзек: «Суеп бетерү белән, Аю әйтә: «Мин моның эчәк карынын күлдә юып кайтыйм». Дүртенче әкият – «Наян төлке». Бүре төлкегә балаларын, бүләкләр биреп, укытырга дип калдырып китә. Әкияттән бер җөмлә: «Бүре китү белән, Төлке моның ике баласын да суеп, ике айда ашап бетерә...»

Бүлектәге «җәүһәрләр» алга таба да шул дулкында.

Хуш, күчик икенчесенә – «Тылсымлы әкиятләр» дигәненә. Монысы «Елан патшасы Шаһмара» дигән әкият белән ачыла. Инде шуннан өзек: «Егет Шаһмараны өчкә кисте. Моңарга өч савыт бирделәр, өч рәт кайнатырга куштылар». Икенче әкият – «Зөһрә». Менә анысыннан өзек: «Төнлә, кулына кылыч алып, үзе (Зөһрәнең әнисе) күл янына килә. Озак та тормый, күл төбеннән кара елан чыга. Кара еланның чыгуы була, кылыч белән аның башын чабып өзә. Кара елан бөтерелеп кала шунда». Өченче әкият «Каракош» дип атала. Анысы – русларның атаклы «Аленький цветочек»ны интектереп язылган инша. Әллә соң фольклор җыярга чыккан студентлар, зачет алу хакына төрле чыганакларга мөрәҗәгать иткәләп (кайда, кем сине әкият сөйлим дип көтсен, каяндыр әкият җыеп кайту, фаразымча, ул үзе әкият), бәгъзе халыкларның җәүһәрләрен татар файдасына хосусыйлаштыру мәрәкәсенә кергәннәрме? Әлбәттә, студентларны, аклап булмаса да, аңлап була... Ә менә шундый тупламалар хакына галим исемен йөртүче, әлеге тупламаларга юл ачучы «остазлар» белән нишләргә?! Дүртенче әкият – «Балыкчы һәм гыйфрит». Инде шуннан өзек: «Патша малае тора сикереп. Хатын Гыйфрит терелде, дип куана. Патша малае тота да бу Гыйфрит хатынын чала». Бу бүлектә адәм итләре белән туенучы диюләр, батыр егетнең, аларның гәүдәләрен турап, әрдәнәләп өеп куюлары – күпме кирәк, шулхәтле. Соңгы өченче бүлек әкиятләре янә мәзәк жанрына якынрак. Иң күркәле дигәне – «Шомбай». Шомбай, алдашып, эшкә урнаша һәм хезмәт хакын вакытында түләмәгәннәре өчен, эшкә яллаучылардан алдап үч алып кинәнә... Монда тагын дин юлындагылардан көлгән нәрсәләр дә бар...

Оныгым Әмирхан, татарча басмалардан үзе укыган хикәяләр һәм мәкаләләрнең һәммәсе дә уртак алгоритмга буйсына һәм андый эшләнмәләрне, компьютер ярдәмендә калыплауга күчүнең кыенлыгы юк, дип саный. Кызык, ә бит классик әдибебез Мөхәммәт Мәһдиевнең үзе исән чагында басылмый калып, кызы Гәүһәр ханым тырышлыгы белән «Татарстан яшьләре» газетасында «Язучы һәм тәнкыйтьче» исеме астында соңарып булса да (2015 ел, 2 июль саны) дөнья күргән мәкаләсендә дә әдәби басма хадимнәренең теләсә кайсы автор текстын уртак калыпка каулауга хирыслыкларына ризасызлык белдерелә... Онныгымның мәсьәләне артык гадиләштерүе белән килешмәскә тырышып караган идем дә, ул исә:

– Бабай, синең мантыйгың юк икән, – дип кырт кисте.

Уртәлүемнән ни диярга белми, өченче сыйныфта укучы, шулай ук тэквандо көрәше белән мавыгучы сеңлесе Нурбикә онгыгыма:

– Кызым, чынлап та минем мантыйгым юкмыни соң? – дип мөрәҗәгать иткән идем, анысы:

– Бар, бар, бабай, әзрәк мантыйк бар синдә, – дип тынычландырды....

Әнә шул барлы-юклы мантыйкны эшкә җиккәч, үзем укыган мәкаләләрнең һәм байтак кына әдәби әсәрләрнең дә кайчандыр мәктәпләрдә, хезмәт дәресләрендә ясаган артсыз урындыкларыбызны хәтерләтүләрен танырга мәҗбүр булдым. Александр Дюманың «Сильвандир» исемле романында берәү әңгәмәдәшенә, Һинстандагы югары катлам әһеле үлеменнән соң, аның хатыны, үзен мәрхүм ире белән бергә тереләтә яндыруга омтылуын, «аларда шундый мода» дип аңлата. Шуның сыман, тәнкыйть дип тәкъдим ителгән мәкаләләрдә генә түгел, бәян, роман, тарихи роман, дип аталучы эшләнмәләрдәге уртаклыкларны да «уртак оя»да күңелләргә бикләтелгән «мода» кәсафәте, дип аңларгамы икән әллә?..

Гомеренең соңгы елларында Мөслим матбугат йорты җитәкчесе булып эшләгән журналист һәм шагыйрь Мөдәмил Әхмәтов та, Казан дәүләт университетының татар бүлеген тәмамлаган авторларның әсәрләрендә ниндидер күзгә күренмәс трафаретка буйсыну барлыгын тәкърарлап, шундый уртаклыкка салулаудан куркуын яшермәде. Мөмкинлеге була торып, чын талант ияләре Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) һәм Мөдәррис Әгъләмовлар кодалавына карамастан, исән чагында бер китап та чыгарырга теләмәвенең сәбәбе дә бәлки шул булгандыр?.. Аның университетны читтән торып тәмамлап, диплом алып кайткач: «Яза белмәсәң анда укымаска кирәк, чөнки анда язарга өйрәтмиләр, яза белсәң дә анда укымаска кирәк, чөнки анда язарга өйрәтмиләр», – дигәне дә булды.

Мөдәмил Әхмәтов белән күп еллар элек, вуз тәмамлап, юллама белән Мөслимдә юл төзү оешмасында эшли башлагач танышкан идем. Ул Фоат Садриев баш мөхәррир булып эшләгән район газетасында авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире вазифасын башкарды. «Авыл утлары» газетасының бер санында төрле авторларның шигырьләренә, шул исәптән минекеләргә дә урын бирелде. Хезмәттәшем, оешмабызда техник вазыйфасын башкаручы Энҗе ханым, әлеге шигъри шәлкем урнашкан газетага ымлап: «Иң шәп шигырь Мөдәмилнеке», – дип белдерде. Аннары, уңайсызланып кына елмаеп: «Сезнеке дә ярыйсы инде, ләкин аныкы шәбрәк», – дип өстәде. Яхшы шигырьләр бер укуда хәтеремдә калучан. Менә ни язылган иде аның «Уйлану» атлы шигырендә:

«Мин оныттым сине, ә син әрсез –
Төшләремә һаман керәсең.
Җанның теленгәнен беләсең бит,
Арадагы ярны күрәсең...
Телгәләнеп беткән йөрәгемне
Учка кысып тагын кабатлыйм:
«Уйларымнан, төшләремнән кит син, –
Мин яратмыйм сине, яратмыйм...»

Еллар уза, әллә ниткән авторлар әлеге шигырьнең игезәкләрен тудыра тора, хәтта ки җырга да салулар да булмады түгел... Саба районының Сабай авылы кияве – шагыйрь Җәүдәт Дәрзаманның, инде мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, әлеге матавыкны ансат кына аңлатып биргәне булды. Баксаң, Казанда яшәп, редакцияләргә урнашып иҗатчы чутында йөрүче бәгъзеләр төрле район газеталарын күз уңыннан уздыруны гадәт итеп, сирәк-мирәк юлыккан уңышлы әсәрләрдәге метафораларны, образларны чүпләштерүне, игътибарга лаек җөмлә-гыйбарәләрне әвеш-тәвеш китерүне гаепкә санамыйлар икән... Мөдәмил шигыреннән файдаланулары үртәлдерде, әлбәттә, әмма

Ләбиб Леронның эпиграф кысасына кертелгән мисалларга бай сатирик шигырьләр җыентыклары белән танышкач, азмы-күпме тынычлана төштем... Баксаң, бер үк җөмләларне бәгъзе әдипләребез «шәпи шикәре» хәленә төшергәнче төрләндерә һәм мондый шаукым берәүнең дә исен китәрми башлаган... Шулай да, талантлы шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның «Бердәнбер кыз турында баллада»сын (анда рефрен булып «бердәнбер» төшенчәсе һәр куплетта – дүртъюллыкка кабатлана) бозып тегеп димме, шуңа ияреп, яки шуның белән рухланып дияргәме икән, турыдан-туры түрәгә, син бердәнбер ди-ди кат-кат тез йөгенүле мәдхия иҗат итүләре, шуны әдәби журналда бастырулары, интернетка элүләре һушны алды. Янә килеп Мөдәррис әкәнең «Сабантуй» шигырендәге «бирмә билеңне!», «бирмә илеңне!» шигарь-гыйбарәләреннән файдаланып, «кыюлык күрсәтү»ләр дә тешкә тигәләде...

Мөдәмилнең китап чыгарырга теләмәвенең төп сәбәбе, ихтимал, исемен ул иҗатчы дип кабул итмәгән вәзенчеләр рәтендә телгә алуларыннан качу, андый янәшәлекне өнәмәү иде, ахрысы. Җырдан, әдәбияттан, беренче чиратта шигърияттән татар моңы туналуына, максатчан буналуына аның җаны әрнеде һәм ошбу өзек тә моңа җиткелекле дәлил санала алыр, дип өметләнәм:

«Әллә урладылар,
Әллә үзе китте...
Буп-буш калды сәхнә
Һәм музыка
Бетте...
Залны тезләндерде
Әле генә әле...
Тетрәнгән җанымның
Моң эзләгән мәле...
Тәрәзләрне бәреп
Чыкты урамга ул...
Хәтта давылны да
Сизми калды авыл...
Моңны урладылар...
Җанда бушлык.
Залда басып торам
Үпкә-нәфрәтләрне
Бергә кушып...»

Ә бит җырларыбыз гына түгел, хикәяләр, бәяннар һәм романнар да татар моңыннан арчылуга дучар икәнен күрми мөмкин түгел. Әдәби басма тиражларының төпкелгә тәгәрәве дә шул хакта тәкърарлый. Әлбәттә, хакыйкый шагыйрьлекне беренче чиратта талант билгели. Ә чын талантка нәзәкатьле затлылык, ихласлык һәм зыялылык хас. Хакыйкый шагыйрь җаны-тәне белән халкыныкы һәм беркайчан да шәхси мәнфәгатьләрне күздә тотып хаким партиягә, түрәләргә сатылмый, тез йөгенми, койрык болгамый. Хәлбуки, койрык болгаучылар да уяу, аларның үрчемле талымсыз иҗатлары чакырылышы, хакыйкый иҗатчыларның талантлы әсәрләрен иге-чиге юк чүп өемнәренә бәрабәр эшләнмәләренә күмеп калдыруны күздә тотуы, кем әйтмешли, Мәнди анасына да аңлашылса кирәк... Китапханәләрдә эшләүче кайбер хадим-хадимәләр дә, халык яратып укучы авторларга матбугатка чыгып күсәк күтәрүләргә ихластан рәнҗеп, бәгъзе

авторларның томнарын ачып карау түгел, бармак та тидергәннәре юклыгы хакында серне чишкәлиләр. Тик шыпырт кына, колакка гына...

Мөдәмил шигъриятне чүп-чар язып иярләргә азапланучыларны һичкайчан өнәмәде һәм шундый эшләнмәләргә юлыкканда пародияләр сырлап ташларга да күп алмый иде. Бер авторның төрле һөнәрләргә маһир авыл егете турында « уңган егет, булган егет, бар эшне гөлт итеп башкара, өстәвенә, электр эшен дә белә» кебек мактаулар тезмәсеннән гыйбарәт шигырен ирештереп, хатын-кыз авызыннан, дип искәртеп,менә болай язган иде:

«...Бер кич шулай ут сүнде дә.
Аулакта калган идек;
Мин беркатлы, кызып китеп.
Кулмәкне салган идем...
Ә ул сикереп торды да,
Пробкага тотынды.
Чыннан да, уңган икән шул.
Ут юк иде — ут булды...
Ә икенче кичне кереп,
Эрәтләде үтүкне,
Плитә кыздырмый иде,
Анысын да ут итте.
Уңган егет, диләр аны,
Уңгандыр, аңлыйм инде...
Әмма аулакта калганда.
Кулмәкне салмыйм инде...»

Мөслимдә шагыйрьләр күплеккә җирле гүзәлкәйләр гаепле бугай һәм Мөдәмилне дә шулар каләмгә тотындырган булса, ни гаҗәп?..

«...Җилнең яллары кабарган.
Буран да буран гына,
Саташып күрсенеп куя
Кешесез урам гына.
Төн дими серләшә һаман
Бәхетле парлар гына;
Син юк, капка төбегезне
Кумгән ак карлар гына...»

Хисләр уралышы-тукылышыннан хасил чын шигырь бернинди аңлатуларга да мохтаҗ түгел. Буран урамда гына түгел, ә сөйгәне белән кавыша алмаудан гаҗиз автор күңелендә дә икәнен әйтеп тору артыктыр да...

«Күз ал яулык болгап китеп бара...
Камылларга сарылып сагыш кала,
Күзгә сыймый күкнең зәңгәрлеге,
Тәгәри дә тама, тәгәри дә тама...»

Мөдәмилне хакыйкый талант ияләре Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) һәм Мөдәррис Әгъләмов чын шагыйрь дип саныйлар һәм шуны гавәм алдында раслар өчен китап чыгарырга димлиләр иде. Үземнең дә, шуларга ияреп, аны рус халык аваз иҗатына караган «Полюбила парня я» исемле шаян, эчтәлеге цензурага бик үк сыешмый торган такмазаны үзгәртеп ирештерергә азапланганым булды:

«Мин беләм бер шәп шагыйрьне,
Ә ул шагыйрь – китапсыз...
Ни пычагыма китапсыз,
Китаплылар хисапсыз...»

Ләкин файдасы тимәде, нәтиҗә күренмәде. Аның «Кайту» исемле китабы бик нәни тиражда үзе мәрхүм булгач, якташлары химаясы һәм хәләл җефете Венера ханым тырышлыгы белән дөнья күрде. Искиткеч шигырьләр язган авторның киң катлам укучылар өчен нәмәгълүм калуы үкенечле хәл, билгеле. Бер мәкаләмдә мин һаман-һаман бер үк танылган саналучы авторларның томнарын гамәлгә куяга караганда юка-юка китапчыкларын чыгаргалап торып, шигърият күгендә атылган йолдыз сыман эз калдырган талантларны искә алу чын әдәбиятның нindилеген онытмау өчен зарур, дип язган идем... Хәлбуки, аяныч ки, «Һәфтияк» калынлыгында гына булса да андый китапчыклар күренми, Эдуард Мостафин, Фәннүр Сафин, Зиннур Насыйбуллин, Госман Садә һәм башка хакыйкый иҗатчылар язганнар онытыла, оныттырыла... Ә Мөдәмил кебек талантлар иҗатын белү, өйрәнү зарурияте көн тәртибендә тормый да бугай. Юк, алай ук түгел. «Безнең мирас» журналы кысасында аңа багышланган альманах дөнья күрде ләбаса!..

«Гаепләп утыру иң ансаты, хәл үзгәрсен, уңайлансын өчен үзеңнең нәрсә кылганың бар?» – дип сорарга мөмкиннәр. Эдуард Мостафин турындагы «Озябшие цветы» атлы мәкаләмне «Звезда Поволжья» һәм «Великая Эпоха» сайтларыннан укырга мөмкин. Мин анда Эдуардның якты дөнья белән хушлашулы ике шигырен рус теленә тәрҗемә итеп урнаштырдым. Эдуардның «Юлчы» шигыренә көй язып, ул җырны Салават бик күп сәхнәләрдән яңгыратты, интернеттан табып тыңларга мөмкин. Әлеге җырга клипны Рамил Төхвәтуллин төшергәнен дә әйтеп узыйм. Зөлфәтнең «Кайтыйк әле, Наис» шигыренә, Наис Гамбәрнең «Меңнәр арасында син бердәнбер», Госман Садәнең «Ялганган ботак монологы», Мөдәмилнең «Күз ал яулык болгап китеп бара», «Җилнең яллары кабарган», «Уйлану», шигырьләренә, Җәүдәт Дәрзаманның «Казан турында җыр» шигыренә көйләр яздым һәм алар белән шәхси блогымның «клиплар клипы» дигән бүлегенә кереп танышу мөмкинлеге бар. Кызганыч, барлык җырларны да, алар белән аралашу мөмкинлегем чикле булу сәбәпле, һөнәри җырчыларга тапшырырга өлгермәдем. Ихтимал, вәгъдә сәгате дә сукмагандыр...

Диңгез суының тәмен белер өчен, диңгезне эчеп бетерү кирәк түгел, диләр бугай. Китерелгән мисаллар Мөдәмилнең язганнары нindилеген чамаларга, шәт, мөмкинлек биргәндер. Әмма аның иҗатын аңлар өчен, үзенең нindилегеннән беркадәр хәбәр бирү артык булмас кебек. Нинди кеше соң ул Мөдәмил?

Күз ае иде, бугай, хәлемне белергә әни белән апам килеп төште. Икенче көнне Мөдәмил, аның хәләл җефете Гөлниса һәм мин әни белән апамны гүзәл Ык буен күрсәтергә алып чыгып киттек. Ханымнар, табыныбыз буласы урынга полиэтилен җәю, ризыкларны тезү, утырыр урыннарны көйләү, киезме – нәрсәдер түшәү белән мәтавыкланганда, Мөдәмил белән икәү шашлык куыру өчен учак ягарга дип, ботак-сатак хәстәренә керештек. Ык ярын баскан куе таллык арасында андыйга кытлык юк, әмма безгә коры-сары кирәк, шундыйны эзлибез. Йөри торгач, уртасында сары төнбоеклар тирбәлгән нindидер күлгә төртелдек.

– Сезнең Саба якларында төнбоеклар юк бит? – дип кызыксынды Мөдәмил.

– Очраткан булмады, – дидем.

Дускай, тиз генә чишенеп, суга кереп китте. Төнбоек сабагы сыгылмалы көпшә шәкелендә төпкә таба сузыла икән, ул аларны өзә-өзә байтак азапланды. Күл тирәнгәдер,

су ифрат суык, җитмәсә, көзнең ул көне шактый сүрән иде, дускай ярга күм-күмгәк булып килеп чыкты. Аннары, җылынырга теләп, утлы күмер өстендә сыман сикергәли-сикергәли киенде...

...Әнигә ипи, күмәч, чәй, лимон-әфлисун ише күчтәнәчләр алып кайткалаган бар ла ул, ә менә чәчәк бүләк итү турында уйга да кереп карамаган. Мөдәмил тапшырган чәчәкләргә әни һәм апамның дулкынланулары, куанулары әле дә булса күз алдымда... Алар бу дөньяда юк инде, бер үк җәйдә бер-бер артлы киттеләр дә бардылар... Ә дуска мең рәхмәт, чөнки ул чәчәкләр, минем дус тапшырганга күрә, өлешчә барыбер дә миннән дә сыманрак кабул ителде...

Мөдәмилнең әниләр турында язган бер шигырендә шундый юллар бар:

«...Вакыт җиткәч кенә кадерләргә,
Кереп югалалар каберләргә...»

Мөслимдә яшәүче бер укытучы ханым, газетада басылганнарыннан чыгып, ахры: «Мөдәмилнең барлык шигырьләре дә «Кудым, тота алмадым, әх...» дигән эчтәлеккә кайтып кала», – дигән... Кем белә, ә бәлки мәхәббәт шигырьләре өчен бик кулай формуладыр ул.

Ә бер мәлне Зөлфәт, Мөдәмил һәм мин тамак ялгыйбыз. Зөлфәт һаман безне шигърият өлкәсендә агартудан туктамый. Дөньясын онытуыннан файдаланып, Мөдәмил моның чәенә тоз сала. Тамагы кипкәнен бетерәм дип чәй уртлаганда Зөлфәт тоз тәмен сизә, әмма сер бирми: чынаякка бер кашык май, ярты телем колбаса өстәп болгата һәм, ипи кабып:

– Менә, кыргызларның чәе шундый, – дип, шупырырга керешә.

Мөдәмилгә дә чәенә ак май, тоз һәм колбаса салып, Зөлфәт «батырлыгын» кабатлаудан гайре чара калмады...

Мөдәмилнең 55 яшьлек юбилей кичәсенә иң кызыклы тостны танылган язучы, драматург, Тукай бүләге лауреаты Фоат ага Садриев әйтте.

«Мөдәмилне әллә ниткән кара урманга, яки чыгар юлы юк, диварлары адәм менмәслек биек лабиринтка кертеп адаштырсаң, ул шуннан котылу әмәлен таба. Әгәр аны гапгади паркка кертеп калдырсаң, ул: «Болай китсәм, бик ансат була, тукта, бу якка барып карыйм, юк, болай да булырга тиеш түгел», – ди-ди, үзен тәмам бутап, чарасыз калырга мөмкин», – дип сөйләгән иде ул...

Мөслим ягы – каләм тибрәтүчеләргә бай як, калалардан Зөлфәт, Фәрит Гыйльметдинов, Флүс Латыйфилар кайтып йөри. Наис Гамбәр белән электәнрәк, студент чагымнан ук таныш идем. Болар бар да Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Мөдәмил, әйткәнемчә, шуны читтән торып бетерде. Бер тапкыр аңа атаклы әдип Мөхәммәт ага Мәһдиевкә имтихан тапшыру насыйп булган. Билеттагы ике сорауны көч-хәл белән ерып чыккан бу, ә өченчесендә «йөзә» башлаган, анысында «Хаҗи әфәнде өйләнә» әсәренә анализ ясау таләп ителә икән.

– Йә, нәрсә анда өченче сорауда?

– «Хаҗи әфәнде өйләнә».

– Комедиядә ни хакында сүз бара?

– Өйләнә инде.

– Кем?

– Хаҗи әфәнде...

– Өйләнәме соң ул?

«Әһә, болайга киткәч, мантыйк буенча өйләнми булып чыга бу», – дигән нәтиҗә ясый Мөдәмил күңеленнән һәм:

– Өйләнеп үк бетми инде ул, – дип мөгри.

– Нишли соң? – дип тәфтишли сабыры төкәнә баручы остаз.

Студент уйга кала. Тәк... Әсәр – комедия... Драматургиядә уртак сюжетка корылган әсәрләрнең чуты юк. Мәгъшукасы белән очрашырга килүче азгын ирләрне үз хатыны белән кавыштырып, көлкегә күтәрү штампы да күп кулланылышлы... Бу тәвәккәлләргә карар кыла:

– Аны, по-моему, үз хатыны белән кавыштыралар.

– Энем, син кайда эшлисең?

– Мөслимдә, редакциядә.

– Әйтәм район гәҗитләре агач тел белән яза, синдәйләр инде анда, – ди мөхтәрәм язучы һәм киләчәктә журналистлар бәйгесендә «Бәллүр каләм»гә лаек булачак журналистның зачеткасына өчле куеп чыгара..

Ир-ат дуслыгы турында сүз чыкса, сыраханә телгә керми кала алмый, минемчә. Әйбәтрәк сыра кайтканын ишетсәк, тиз генә хәбәрләшәбез дә, шунда турылый торган чорыбыз. Беркөнне, Мөдәмилнең эш урынына сугылып, һаман да шул тарафка ашыкканда, юлыбызны аның хезмәттәше бүлде. Сеңлесе кияүгә чыккан икән, фотоларын күрсәтергә тели:

– Күрче, Мөдәмил, ничек матур чыкканнар! – ди.

Мөдәмил, сул күзен кыса төшеп, сурәтләргә күз ташлады һәм:

– Ярый, исән-сау барып кайтсын инде, – дип көлемсерәде...

Ә сыраханәдә хатын аерган бер танышыбызны очраттык. Ул зарлана: «Кызны сагынам да, кай кичне хатын фатирына керәм, анда вакыт тиз уза һәм куна калына. Ә иртән торып чыгып киткәндә, моңа әллә ниткән әшәке сүзләр әйтәсе килә, ә тапмыйм», – дип авыр сулый. Мин әле өйләнмәгән дә булгач, ул өлкәдә чи наданлыгымны танып, тыңлап кына утырам. Ә Мөдәмил күпне күргән, күпне кичергән, бераз уйланып тора да.

– Нәрсәгә усал сүз әйтергә? Чыгып китәрең алдыннан, өстәл читенә бөгәрләнеп беткән өч тәңкә ыргыт һәм вәссәлам! – ди...

Хәтерлим, Мөдәмил редакциядә ничәдер ел эшләп, укуын тәмамлагач, райкомга инструктор булып күчте, аннары аны парткомиссия рәисе итеп күтәрделәр. Райком таралгач, пенсия фонды башлыгы иттеләр. Менә районда җитәкчелек алмашына һәм аңа әлеге җылы урынны калдырырга боералар. Мөдәмил, компьютерны үзләштереп, программист булып акча эшләү әмәлен тапты, ә аңарчы алыпсатарлык белән дә шөгыльләнеп алды. Бермәл моның кесәсенә миллионнар агып керә башлады. Әмма бизнеста уңыш алдын да, артын да күрсәтүчән. Берзаман бу гел югалтуларга дучар була башлады һәм шул чорда, яшәү өчен көч өстәп, нәни генә хикәя сырлап, аны район газетасында бастырып чыгарды. Хикәянең кыскача эчтәлеге болай: «Берәү башта бай-ый. Аннары байлыгын югалта башлый. Берзаман бар кереме эреп бетә моның. «Зыян юк, – дип үз-үзен юата эшмәкәр, – аның каравы, мин бит мәхәббәттән уңдым».

Моны хатыны калдырып китә. «Дүрт сан төзек әле, шөкер», – ди тол калучы. Инде аяк-кулларын кисәләр. «Ничава, – ди инвалид, – иң мөһиме – баш исән». Моның башын чабып төшерәләр. Һәм башы, тәгәрәп барышлый, аяксыз-кулсыз гәүдәсен күздә тотып, үзен:

– Бу ит түмәркәсеннән аерылып, нәрсә югалтам соң әле мин, – дип юата...»

Шәп дус иде ул, иң авыр чакта юатырдай, купайтырдай сүз таба белә иде.

Бер шәп кыяфәтле, зифа буй-сынлы, «мәхәббәт фронтында» җиңүләрдән җиңүләргә

ирешүче дустыбызның сөйгән яры, аны ташлап, энесе белән очраша башлады. Ниндидер мәҗлесебездә бу хакта сүз чыкты. Дустыбыз уңышсызлыгы өчен вазыйфасының катлаулы булуы, вакыты тарлыгы белән акланырга азапланды. Әмма безгә кызык, көлешәбез. Дустыбызга кыен, ул гарьлегеннән кызарынып бүртенә, ни дияргә дә белми. Шулвакыт Мөдәмил, телгә килеп:

– Примитив кешеләргә оригиналга караганда копия күбрәк ошый, – дип белдерә.

– Моның белән ни димәкчек буласың? – дип кызыксына дустыбыз.

– Син бит гаиләгездә беренче малай. Ә энең – икенче, ни дисәң дә азмы-күпме копия.

Хактан да алар бер-берсенә шактый охшаш егетләр иде.

Дусларына ышанычлы таяныч иде Мөдәмил. Мөслимдә район газетасы баш мөхәррире булып эшләгән һәм арабыздан вакытсыз китеп барган уртак дустыбыз Алмаз Хәйруллин исәлегенә язылган күңел тетрәткеч шигыре дә аның дусларга карата булган ихлас мөнәсәбәтен ача, дип уйлыйм:

«Тәрәзәмне карлы яңгыр шакый –
Адашкан бер мосафирмы әллә?..
Күңел җылы эзләп бәргәләнә
Кара төндә. Шыксыз көзге мәлдә...

Елый-елый, каен яфрак коя,
Яфрак түгел, сары сагыш мәллә?..
Бер сәбәпсез күзләр тулып таша
Сарыга коенган көзге мәлдә...

Басуларда бары камыл гына,
Тырналып җил җылый микән әллә?..
Кабер исе килә басулардан
Салкыннан өшегән көзге мәлдә.

Тәрәзәмне карлы яңгыр кага,
Шомраеп көтәм мин кичләрен...
Әллә җаным шулай тынгы тапмый,
Барлап йөри микән дус-ишләрен?..

Кич җиттеме, килә карлы яңгыр,
Тәрәзәдән китә каберләргә...
Кисәтә көз, кисеп бәгырьләрне:
« Исән чакта кирәк кадерләргә!»

Җанга ява көзге карлы яңгыр,
Кемдер кирәк җанны юатырга.
Бар иде, дип әйтә алу өчен,
Өйрәнгәнбез, ахры, югалтырга...

Җылы эзләп килә карлы яңгыр -
Үземнең дә җаным туңган чакта.
Якыннарын җуйган күңел буп-буш,
Мич суынган, тәрәзәмдә – такта...

Җәй иде бит әле кайчан гына,
Өмет сыман яшел иде җиһан!
...Ә алда – кыш, кәфенгә төренгән...
Көзге сагышлардан туйдым, дисәң...»

Мөдәмилнең якты дөньядан китеп баруы яраткан эшеннән китүе белән бәйле, дип уйлыйм. Яше җитте, әмма китәсе килми китте. Хәер, чын дөресен, хакыйкый шагыйрьнең фаҗигасен шушы шигыре тулаем ачып сала булыр:

«Чакырылганмы?
Әллә чакырылмаган?
Без озакка диеп
Килгән идек...
Капкаларын каерып ачып куйган –
Сау бул, диләр миңа,
Иртәгедән, диләр...
Алда –ак кыш...
Кыштан куркам...
Куркам тагын куркып яшәүдән дә...
Без озакка диеп
Килгән идек...
Капкаларны кемдер куйган ачып...
Тормыш – матур!..
Ләкин кемгә кирәк
Үлем белән яшәү бәхәсләшеп?!.

Инде Мөдәмилнең язылып та, югалу сәбәпле, алда әйтелгән кечтеки китабына керми калган ике хикәясенең эчтәлеген сөйләмәкче булам. Кем белә, Мөдәмил мотивлары буенча, дип, берәр драматургка пьеса-фәлән язарга этәргеч бирер?! Ул аларны миңа укыган иде. Беренчесе менә мондыйрак булып истә калган: «Мөслимнең Ык күпере башында машина көтеп торучылар арасында чуар күлмәк кигән, яулык япкан, бите кояшта янып каралган бер әби. Тик машиналар ул кул изәгәнгә түгел, ә чибәр кызлар катында туктый. Кызлар китә тора, ә ул кала бирә. Менә бер дәү йөк машинасы аны узып туктый һәм әбигә кул болгый. Әби, бу минем оныгым микән әллә, мөгаен, шулдыр, дип, абына-сөртенә алга уктала. Баксаң, шофер егет әби артында торган туташка дип туктаган икән: «Бетмәс монда әрсез алабайлар», – дип сукранып, аны кабинасы ишеге төбеннән читкә этә-төртә, сөйгән кызына кабинага менәргә булыша. Аннары, машинасын яман акыртып, тузан өермәсе куптарып кузгалып, күпергә барып керә. Һәм күпер җимерелә. Бөтенләй түгел, бер адым арада гына. Әле бу Ык күперенең агач чагы, имеш. Урып-җыю чорында азга да юл өзелү түзеп тормаслык хәл, бу хакта хәбәр тиз арада район җитәкчелегенә барып ирешә. Озак та үтми, урынга райбашкарма комитеты рәисе килеп җитә. Мөдәмил аны шул вазыйфадагы гайрәтле җитәкче Гариф Хафиз улы Хафизов гәүдәләнешендә күзаллыйм, дигән иде. Һәм җитәкче «ә» дигәнче эшне оештыра. Ул юл читендә моңаеп һәм бөкшәеп торган, бу якныкы түгеллеге кояшта янган чыраена чыккан әбине күреп ала, аның катына килә, хәлен сораша. Әби Казахстанда, бала карарга китеп, байтак еллар кызында яшәгән икән. Оныклар үскәч, анда сыймый башлаган һәм туган ягына, төпчек улына кайтырга ниятләгән.

– Казахстанның кайсы өлкәсеннән? – дип кызыксына җитәкче.

– Анда сафхуз дигән җир бар, – дип җавап күндерә әби.

Әбинең йөрәге шаяргалый икән, валидолым бетә, нишләрмен, дип куя якты йөз күрсәтүчегә. Гариф агабыз, борчылмагыз, миндә бар, дип, машинасыннан алып, үзе өчен тоткан даруын аңа суза: «Җитәкче мосафирә карчыкның кайсы авылга юл тотканын ачыклый. Баксаң, ул аның салгаларга яратучы улын да, улының пырдымсызрак хатынын да белә икән. Авылда әбекәйгә көн булмаячагын Гариф агабыз чамалый һәм бер милиционерга аны Салавыз Мухан авылындагы картлар йортына урнаштырырга куша. «Шунда яшәп тор, малаең белән киленең Башкортстанга кунакка киткәннәр иде, алар кайткач, үзем илтермен», – дип тынычландыра. Исәбе – әлеге гаиләгә ниндидер матди ярдәм күрсәтеп, әбинең гаиләгә кабул ителүен уңайлау...» Милиционерның прототибы Ильяс исемле участок инспекторы дигән иде Мөдәмил. Бар иде шундый үзешчән сәнгать йолдызы, һавадан «чирәм йолкып» бии, урында сикереп сальто ясый, йөзеннән елмаю китми торган погонлы ир-егет... Картлар йортына урнаштыруның мәшәкате күп, медицина комиссиясе узу кирәк, вакытлы прописка алу, тагын әллә ниткән кәгазьләр... Ильяс бу киртәләрне ничек кирәк алай уза һәм әбине картлар йортына көнендә урнаштыруга ирешә.

Аннары Мөдәмил картлар йортындагы тәртипләрне бәян итәргә керешә. Сүзне борынга нинди исләр бәрүеннән башлый һәм персоналның үз карамакларындагы картқорыга карата төксе мөнәсәбәтен сурәтли. «Персоналны да аңлап була, баксаң, анда олы вә кече йомышын астына гына үтәп ята торган, яки акылы бик үк камил түгелләр дә бар һәм шикаять юлларга остарган бәлачеләре дә юк түгел, имеш... Әбинең исә үтә нык сагынган, төшләренә кереп йөдәткән туган авылына кайтасы килә. Ул аның кай тарафта икәнен дә аңыша, иртән җәяү чыгып китсәм, кич барып җитәрмен, дип исәпли. Китешли, картлар йорты биләмәсендәге кишер түтәленә кармак салып балык тотмакчы булып утыручы исәр карт белән шактый кызык һәм гыйбрәтле әңгәмә кора. Аннары, бисмилласын әйтеп, тәвәккәлләп, авылына төбәп кузгала. «Балыкчы» карт бер мәл түтәлдә ялтыравыклы нәрсә күреп ала. Баксаң, карчык райбашкарма комитеты рәисе бүләк иткән даруын төшереп калдырган икән.

– Әһә, селәү (суалчан) салырга әйбәт булды әле бу, – дип, исәр карт ихлас күңелдән куана... Тартманы ачып, дару төймәләрен түтәлгә сибә...»

Тагын бер хикәясе «Толым» дип исемләнгән иде: «Чишмәләр типкән, таллар баскан мең кошлы сазлыклы үзәндәге болынга кичләрен яшьләр уенга чыга торган була. Авылның иң гүзәл кызының йөрәген ике егет яуламакчы. Көрәштә дә, җыр-биюдә дә ярыша болар. Кыз, ниһаять, берсен сайлый. Икенчесе төнлә кыз йоклаган келәткә үтеп керә һәм аңа кагылмый-орынмый гына чәч толымын кисеп алып чыга. Шул толым киселү аркасында үзара сөешүчеләрнең арасы бозыла. Толымны кем, ничек кискәнен беркем белми. Ара төзәлергә өлгерми, гашыйк егетләрнең икесе дә сугышка алына. Икесе дә исән кайта. Кыз чит якка вербовка белән киткән, адресын беркем белми. Әсәр азагында, көндәшләрнең берсе үлем түшәгендә ятканда, хәл белергә кергән икенчесе аңа толымны тапшыра... Ә инде яшь чакларында болар кич чыккан болын юк, ул су астында калган, анда плотина корылган». Плотина коручы ПМК җитәкчесен Мөдәмил миңа охшатып тасвирлаган. «Сулык зур, киң, иркен, анда вак балыклар сикерешә, эреләре чуптырдап куя, үрдәк-казлар йөзә, бөҗәкләр тыз-быз килә, акчарлаклар кыйгачлап оча. Карап торырга бар да соклангыч һәм әйбәт кебек, ә асылда берөзлексез җан кыеш бара».

Язмамны Наил Касыймов фикере кысасында тәмамлыйсы килә. Чын шагыйрь, чын язучы булып саналуга бер китап чыгармый да ирешергә мөмкин. Һәм йөз том чыгаручыны да графоманга чутлаулары ерак йөрми... ■

МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ САБАКТАШЛАР

Ләбиб Лерон

Миңа 1969-1979 елларда Актаныш районының өч мәктәбендә белем алырга туры килде. Үзем үскән Олы Имән авылында – өч, Югары Яхшыйда – биш, Киров авылында ике ел укыдым. Укытучыларымның холык-фигыльләре, килеш-килбәтләре төрле булса да, аларның һәрберсе тирән белемле, чын мәгънәсендә үз эшенең фанаты иде. Мәктәп белән саубуллашканга кырык елдан артык вакыт узса да, мөгаллим-мөгаллимәләремнең йөз чалымы әле дә күз алдымда тора. Алар безгә белем дә, үгет-нәсыйхәт тә бирде, эшкә дә өйрәтте. Кирәк чагында җырлаттылар да, биеттеләр дә, авырлыклар килгәндә – юаттылар да... Кыскасы, безне кеше итәргә тырыштылар. Рәхмәт укытучыларымның барчасына да!

ОЛЫ ИМӘН. БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘП

Олы Имән – Казан-Уфа юлыннан биш чакрым читтә урнашкан авыл. Аңа XVII гасырда нигез салынган. Ул зур авыл түгел, шул ук вакытта кечкенә дә димәс идем. Авыл тек авыл. Шаккатмалы урманнары да юк үзенең. Исләреӊ китәрлек үк булмаса да, Шәүләгән болыны, Алтынчы җәйләве, Таллык аланы, Әхнәф чокыры бар. Тирә-якта – Асаба, Мурзин, Умарталык һәм Тәкмәк әрәмәләре. Хәзер аларны урман дип йөртсәң дә буладыр инде – агачлары шактый озынайган, юанайган. Үзенә күрә Ташлы

Олы Имән башлангыч мәктәбе. 1978 ел

Олы Имән авылы күренеше. Ташлы таудан бер караш. 2019 ел

тавы (Таштау) да бар авылның. Хәер, хәзер инде «бар иде» дип язсам, дөресрәк туры килер, чөнки Казан-Уфа юлының Пучы-Байсарга караган өлешен яңартканда, Ташлы тауның ташлы комын машиналап-машиналап ташыдылар. Кайчандыр Емельян Пугачев яугирләре һәм аклар белән кызыллар оборона тотып яткан бу тау хәзер орылып-сугылып һәм яньчелеп беткән иске, эче буш ләгәнне хәтерләтә...

Классик язучыбыз Әмирхан Еники әйтмешли, хуп, ары таба китеп, безнең бәрәңге бакчасы артына юл тотыйк. Үзәнлек булуына карамастан, монда да үзенә күрә тау бар. Кышын-язын без – бала-чага гел шунда әвәрә килеп яттык, чаңгы йә чана шуарга һәвәс идек. Күрше кызы, сыйныфташым Рәфинәнең (Әхмәтова) агач чана белән ярдан «упкын»га очканы һаман да күз алдымнан китми. Ярый әле үзенә ул-бу булмады тагы... Кышын кар – тирән, яр буен сырып алган көртләр «алагаем зур кашлы» була торган иде шул ул елларда. Яз җиткәч, кар ачылып, үләннәр «борын төртә» башлауга, әлеге тау итәгендә «Карга боткасы» бәйрәме үтәр иде. Күбрәк безнең Түбән оч урамы балалары кинәнде инде бу тауда. Безнең урам очындагы яр башында да бала-чага гел мәш килер иде ул чакта. Язгы ташу вакытында бигрәк тә. Кәрт сугарга шунда өйрәнде инде бездәй малай-шалайлар...

Туктале, «сүз башым бит шүрәле», дигәндәй, мин бит мәктәп турында сөйли башлаган идем.

Ноябрь аенда дөньяга килүем сәбәпле, укырга яшьтәшләремнән бер елга соңга калып керергә туры килде. Дөрес, алар белән бер сафта булу мөмкинлегем бар иде, әмма мин, нигәдер, тагын бер ел «трай тибеп йөрүне» кулайрак күрдем. Дөресен әйтим, рәсем ясарга һәвәс булсам да, укырга кергәнче укый-яза белми идем. Мәктәпкә «вакытында» кермәвемнең төп сәбәбе шул булгандыр да әле. Безгә туган тиешле Нәҗип абый

Олы Имән башлангыч мәктәбенең беренче сыйныф укучылары. Икенче рәттә уртада – Л.Леронов. 1969 ел

Әһлиевнең кызы, булачак сыйныфташым Мәрвәнең (игезәге Мөнир белән бер партада утырып укыган чакларны яхшы хәтерлим әле) «Социалистик Татарстан» дигән ике сүзне укырга кергәнче үк яза белүе мине гаҗәеп дәрәҗәдә таң калдырганы истә. Мәрвә, укырга кергәч, бигрәк тә башлангыч классларда, гел «бишле» билгеләренә генә укыды.

Мәктәпкә 1969 елда кердем мин. Дөресрәге, беренче сентябрь иртәсендә туганнан туган сеңлем Ләлә җитәкләп илтеп куйды мине. Мәктәпкә бу юлы да аяк тартмый торды. Нигәдер...

Бер елга соңарып керүем шуның белән дә истәлекле: бездән алдагылар «Арифметика» укыган булса, безгә «Математика» керде.

Бер елдан артык «кара»га манып яздык. Язган чакта бармаклар зәп-зәңгәр (әллә шәмәхәме?!) булып бетә иде. Шариклы ручка кулланышка кергәч, хәл бераз җиңеләйде: чистарак итеп яза башладык, дәфтәрләр эчендәге киптергечләрнең хаҗәте шулкадәр генә булып калды.

Башлангыч сыйныфларда без унтугыз бала укыдык: игезәкләр – Мәрвә һәм Мөнир Әһлиевләр, Рәфинә Әхмәтова, Илһар Вәлиев, Рәмилә Заһидуллина, Азат Исламов (Вәлиев), Азат Каюмов, Мөнирә Минһаҗева (Ганиева), Рәдиф Наҗаров, Дәбир Нәгыймов, Дәнирә Нигъмәтуллина, Данир Сафин, Илдар Саматов, Рисхәт Фатыйхов, Айзирәк Хәтимова, Фәндәвис Шәйхетдинов, Ленарис Шәйхразыев (ягъни мин бахырыгыз – Лемон Лерон улы Леронов – Ләбиб Лерон), Римма Шакирова, Индус Хәйретдинов (1969 елда төшкән фоторәсемдә Данир Сафин юк).

Безне сыйнфташым Айзирәкнең әнисе Ания апа Әбуярова укыта башлады...

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №8 август 2019

КАЙСЫСЫ ДӨРЕС: «*Фатих*»мы, әллә «*Фатиһ*»мы?

Фатиһ Кутлу

Бу якларга аяк басканнан соң, кирилл әлифбасы белән тәүге тапкыр рус теле аша таныштым. Шуңа исемемне «Фатих» дип яза башладым. Алга таба татарның бөекләре – Фатих Кәрими, Фатих Әмирхан, Фатих Кәрим, Фатих Халиди, Фатих Хөсни, Фатих Урманче һ.б. исемннәренең дә «Фатих» дип язылганын күреп, моның белән ризалашкан идем. Төрек халкы арасында «Фатих» бик таралган исем. Кыскача гына булса да моның тарихын язып үтү урынлы булыр. Госманлы дәүләте патшасы 21 яшендәге 2 нче Мәхмәт 1453 елда Византиянең башкаласы Константинопльне алгач, аңа «Фатих» исеме бирелә. Шуннан соң ул «Фатих Солтан Мәхмәт» дип йөртелә башлый. «Фатих» ул гарәпчә – «фәтх» – ачу, буйсындыру, җиңү дигән сүзләрдән ясалган – «ачучы, җиңүче» дигән мәгънәгә ия. Ачкыч мәгънәсендәге «Мифтах» сүзе дә – шул ук тамырдан.

Инде төп мәсьәләгә күчим. Төрек телендә «х» авазы юк, фәкать «һ» авазы гына бар. «Х» авазы, ялгышмасам, әзәриләрдә дә очрамый. Төрекчәдән моңа мисал итеп кайбер исемнәрне тезеп китмәкче булам: Һайдар, Һасан, Һүсәен, Һалил, Һамит, Аһмәт, Маһмут, Фатиһ, Мәһтап (Махитап), Мәһмәт, Һалимә, Һаят, Һүррәм һ.б.

Татар әлифбасы белән танышып анда «һ» авазының барлыгын белгәч: «Их, исемемне чын дөрес итеп язу мөмкинлеге булган икән, ник моны алдан белмәдем», – дип борчылып куйганым хәтеремдә.

Сүз уңаеннан, «һ» авазы – татар теленең бик зур байлыгы ул. Әмма шушы байлыктан тиешенчә файдаланылмый кебек. «һ» авазы үгисетелгән төсле тоела миңа. Моңа, үзе дә үпкәли торгандыр шикелле.

Мәгълүм булганча, рус телендә «һ» авазы юк. Шуңа күрә Аурупа телләреннән кергән алынма сүзләрдә, теләр-теләмәс, «г» авазына мөрәҗәгать итәләр. Ә татар телендә андый мәҗбүрилек юк. Шул ук сүзләрне турыдан-туры алып, чын дөресенчә язарга мөмкин. Бу урында кайбер сүзләрне мисал итеп тезеп китмәкче булам: Һегель, Һәнри, Һитлер, Һолландия, Копенһаген, моһикан, һибрид, һигиена, һидро, һипноз, һипотеза, һипертоник һ.б.

Киләчәктә төзеләсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә һәм татар энциклопедияләрендә югарыда телгә алган яки алынмаган бик күп «һ» авазлы сүзләрне «г» исемлегеннән «һ» баганасына күчерү бик тә урынлы булыр иде.

«Фатих» исеменең ничек язылуы мәсьәләсенә кире кайтканда... Татарчадан төрекчәгә тәрҗемә иткәндә ялгызлык исемнәрендәге үзенчәлекләрне сакларга тырышам. Мәсәлән: Гали, Гайшә, Гомәр, Госман, Габдулла исемнәре очраса, аларны, төрекчәләштереп, Али, Айшә, Өмәр, Осман, Абдуллаһ, дип үзгәртмим. Татарчада ничек кабул ителгән – шулай язарга, шулай әйтергә азапланам. Латин хәрефләре белән язып күрсәтсәк: Ğali, Ğayşe, Ğomer, Ğosman, Ğabdulla, дип язам. Шулай ук

төрекчәдән татарчага тәрҗемә кылганда да моңа игътибар итәргә кирәк. Төрек исеме икән, аны, татарчалаштырмыйча, Али, Айшә, Осман, Өмәр, Абдуллаһ дип күчерергә кирәк. Бу шулай тиеш һәм ул, икенче яктан, бер-береңне санлау, хөрмәт итү билгесе дә. Сөйләшкәндә, эндәшкәндә дә моңа тугрылыклы калырга кирәк. Әлбәттә, бу бик җиңел эш түгел. Синең телең гомер-гомергә «Гайшә» дип әйтергә ияләшкән яки киресенчә. Безгә ошыймы ул, ошамыймы – «Гайшә»не «Айшә»гә, «Айшә»не «Гайшә»гә үзгәртмәскә телебезне күнектерергә кирәк.

Бер хатирә исемә төште. Күптән күрешмәгән бер татар танышымны очраткан идем. (Ул үзе төрекчә бик яхшы белә.) Гаилә хәлләрен, бала-чагаларын, аларның исемнәрен сорашкач, танышым миңа: «Кызым Зөһрә исемле, ә төрекчә Зәһра була», – дигәч: «Юк! Зөһрә икән, Зөһрә. Төрекчә дә шулай, русча да (Зюхрэ)», – дип шелтәләгәнем хәтеремдә. Үзем дә фамилиямне дөрес итеп яздырырга тырышам. «Котлы» дип язучыларны «Кутлу»га төзәтәм. Бу өлкәдә күпмедер уңышка ирештем шикелле. Хәзер күпчелек «Кутлу» дип яза башлады, шөкер. Икенчедән, шунысы да бар: «Кутлу» сүзе төрек телендә күпчелек «изге» дигән мәгънәдә кулланыла.

Мәкаләмдә сүзне исемем «Фатих»ның дөрес язылышыннан башлаган идем. Инде мине бу мәкаләне язарга этәрүче төп сәбәпкә күчәргә телим.

Быел февраль аеның 15ендә 36-37 яшьләрдәге алты ир бала атасы Венер (Габделкәрим) хәзрәт Моратовның юл һәлакәтендә гомере өзелүе Татарстан җәмәгатьчелеген, аеруча мине зур кайгыга салган иде. Венер мәрхүм – Алабуга педагогия институтының филология факультетына кергән татар-төрек бүлеген тәмамлаган кеше. Мин анда ике ел алар төркеменә төрек телен укыткан идем. Шәкертем дә булгач, ничә көн борчылып, аңгы-миңге йөргәнемне бер Ходай гына белә. Ул үзе фәрештә валчыгы иде, каберендә дә аны фәрештәләр каршы алсын, дип теләп тордым.

2002 елда Алабугадан киткәндә шәкертләремнән истәлек өчен саубуллашу хаты язуларын үтенгән идем. Шуннан соң да күпме шәкертем белән хатлар алышып тордык әле. Ул мәңгелеккә күчкән көннәрдә мин әлеге хатлар арасыннан мәрхүм шәкертем Венерның саубуллашу хатын һәм соңыннан миңа язган бер хат белән открыткасын табып алдым. Аларны кат-кат укып тордым... Ни кызганыч, Венер мәрхүм университетны тәмамлаганнан соң, бер мәртәбә дә очрашмаганбыз. (Бик каты үкенәм хәзер.) Хатыным: «Кара әле, эндәшү сүзендә синең исемеңне дөрес итеп «Фатиһ» дип язган бит ул!» – диде (ул игътибар итмәсә, гомердә дә күрмәс идем). Карыйм, чыннан да шулай. Егерме яшьлек вакытында ук исемемне дөрес итеп яза белгән, мәрхүмкәем! Шәкертем мине уятып җибәрде. Бу хәлне бер ым-ишарә дип кабул иттем. Ул миңа мөгаллим булды һәм күпме еллар үткәннән соң әлеге хатаны төзәтеп, «Фатиһ» дип язарга, дигән ныклы карарга килүемә сәбәбче булды.

Бу мәкаләм басылып чыкканнан соң, исем-фамилиямне «рәсми рәвештә» «Фатиһ Кутлу» дип яза башлыйм, дидем. Һәм башкаларга да үтенечем шул: моны «Безнең мирас» аша бөтен халыкка игълан итәм.

Урының Фирдәвес җәннәтендә булсын, газиз кардәшем! Аллаһы Тәгалә әтиәниеңә, хәләл җефетеңә, гөнаһсыз нарасыйларыңа, барча туганнарыңа күркәм сабырлык бирсен. Аларга балаларыңны үстереп, аякка бастырырга көч-куәт насыйб итсен! Амин! ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Фәрваз Миңнуллинның тууына 85 ел

Әдәби тәнкыйтьче, язучы, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984) Фәрваз Мөхәммәдулла улы Миңнуллин 1934 елның 5 августында хәзерге Татарстан Республикасының Арча районына караган Ишнарат авылында игенче гаиләсендә туган.

1950 елга кадәр үз авылларындагы башлангыч һәм күрше Носы авылындагы җидееллык мәктәптә укый, аннан Арча педагогия училищесында (1950-1954), Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә (1954-1959) белем ала.

1959-1961 елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә бүлек мөдире булып эшли.

1977-1984 елларда ул – Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре һәм 1978 елдан идарә рәисе урынбасары, ә 1984-1989 елларда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире. 1989 елдан гомеренең ахырына кадәр нәшриятның баш мөхәррире вазыйфасын башкара.

Ф.Миңнуллин – «Якты юллар» (1975), «Прозаның гражданлык йөзе» (1983), «Талантлар юлы» (1984), «Затлылык» (1990), «Балта явызлар кулында» (1994) исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган җыентыклар авторы.

Ф.Миңнуллин тәрҗемәсендә Г.Уэллсның «Күренмәс кеше» (1979), «Галәмнәр сугышы» (1987) һәм Дж.Лондонның «Мартин Иден» (1982) романнары басылып чыкты.

Ул – 1973 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Ф.Миңнуллин 1994 елның 11 декабрендә вафат булды һәм туган авылы Ишнарат зиратында җирләнде.

Рәссам Байназар Әлминевнең тууына 110 ел

График, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957) Байназар Мостафа улы Әлминев 1909 елның 14 августында Самара губернасының Бозаулык өязе (хәзер Оренбург өлкәсенең Тоцк районына керә) Кызыл Мәчет авылында зәркән остасы гаиләсендә туган.

1930 елда Самарадагы татар-башкорт техникумын, 1934 елда Пенза сәнгать-педагогия техникумын тәмамлый.

1934-1935 елларда Куйбышев шәһәрендә «Кызылармияче» газетасында рәссам булып эшли.

Татарстан китап нәшриятында бизәлеш мөхәррире (1935 елдан), бизәлеш мөхәрририятенең мөдире (1947 елдан) вазыйфаларын башкара.

Б.Әлминев китап бизәү өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе иде. Ул әдәби әсәрләрнең үзенчәлекләрен җентекләп чагылдырган 300дән артык китап бизәде, алар арасында «Идегәй» дастаны һәм татар әдәбияты әсәрләре, дәреслекләр («Әлифба») бар.

Б.Әлминев 1976 елның 31 октябрендә Казанда вафат булды.

Язучы һәм тәрҗемәче Яхъя Халитовның тууына 90 ел

Язучы, тәрҗемәче, ТАССР һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре Яхъя Мөхәммәтгали улы Халитов 1929 елның 22 августында Татарстанның Тәтеш районындагы Үтәмеш авылында крәстиян гаиләсендә туган. Үз авылларында башлангыч, күрше Бакырчы авылы мәктәбендә җидееллык белем алганнан соң, башта Арча педагогия училищесын, аннары 1972 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Университетның соңгы курсында укыган чагында ук «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли башлый.

Яхъя Халитов 1960-1963 елларда Татарстан китап нәшриятында редактор вазыйфасын башкара.1963 елдан башлап редакциянең проза бүлегенә җитәкчелек итә.

Ул – иҗади сәләтен тулысынча тәрҗемә эшенә багышлаган каләм осталарының берсе.

Я.Халитов 2016 елның 2 гыйнварында вафат булды.

Рәссам Исмәгыйль Хәлиулловның тууына 90 ел

Рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1979) Исмәгыйль Минтаһир улы Хәлиуллов 1929 елның 28 августында Самара өлкәсенең Ставрополь-на-Волге (хәзерге Тольятти) янындагы Татар Выселкие авылында туган.

И.Хәлиуллов алтмышынчы елларда иҗат иткән Казан рәссамнары арасында лаеклы урын алып тора. Аның исеме күп санлы монографияләргә, альбомнарга һәм Татарстанның белешмә-сүзлекләренә кертелгән.

Исмәгыйль 1947 елда мәктәпне тәмамлый. Аның рәссам буласы килә һәм ул Түбән Новгород сәнгать училищесына юл тота. Пароходта барганда Исмәгыйль Казанда укучы бер студент белән таныша. Яңа дусты аңа Казан сәнгать училищесына кереп карарга киңәш итә. Исмәгыйль әлеге уку йортын 1952 елда тәмамлый.

И.Хәлиуллов – 1960 елдан СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы.

Ул «Ленинны беренче мәртәбә кулга алу», «Отряд китте», «Җир хуҗалары», «Беренче бала» кебек картиналары белән таныла. Рәссам милли темага да мөрәҗәгать итә. Туган җиренә, туган иленә, әти-әнисенә булган мәхәббәте аның «Туганнарым минем» картинасында яхшы чагылыш тапкан. Күпләр андагы хатын-кыз сурәтендә рәссам әнисенең төсмерләре булуы турында әйтә. Ул картина хәзер Татарстанның «Хәзинә» милли галереясында саклана.

И.Хәлиуллов 2009 елның җәендә вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2019

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Классик саз

САЗ

Дөнья ул – «саз», яшисең килсә
Әгәр аның белән бер көйгә,
Көйлә аны үзең теләгән көйгә.
Тик син каршы килсәң тормышка,
Сазың да уйнар ялган тавышка.

Низами (XII гасыр)

Саз сүзе безгә борынгы фарсыдан килеп кергән. Тәрҗемәдә ул «уен коралы» дигәнне аңлата. Иран галимнәре саз борынгы танбур, ә азәрбайҗаннар сетар уен коралыннан үзгәртелеп ясалган, диләр. Сазның башка уен коралларыннан аермалы берничә үзенчәлеге бар. Беренчедән, танбур

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

да, сетар да өске такталары урынына тире тарттырып ясалган, ә сазның өслегенә каты чикләвек агачыннан такта куелган. Икенчедән, аның корпусының эче бик тирән һәм кузовының рәвеше урталай киселгән дулегә (грушага) охшаган һәм кыллары да парлап тарттырылган.

Сазның ике төре бар: зур саз һәм кече саз. Зур саз баглама дип атала. Аның парлап тарттырылган беренче ике кылы – октава аралыгына, икенче ике кылы – бер үк тавышка (унисон). Өченчесендә исә бер үк тавышка өч кыл тарттырылган. Озын грифка 12-17лад аралыгы урнашкан. Ладлар, татар музыкасыннан аермалы буларак, чирек тоннар белән дә көйләнелә.

Мәскәүнең М.Глинка исемендәге Дәүләт музеенда элеккеге СССР җирлегеннән табылган саз уен коралының берничә төре саклана.

Саз безнең якларга ничек килеп кергән соң? Татарның иң сәләтле яшьләре, берничә йөз еллар буе, Урта Шәрык илләрендәге мәдрәсәләрдә белем алган, укымышлы катламы хаҗга барган. Аларның байтагы, суфыйчылык гыйлемен үзләштереп, Урта Көнчыгышта аеруча популяр булган уен коралларында уйнарга өйрәнеп, үзләре белән әлеге уен коралларын безнең якларга да алып кайткан. Шул рәвешле, саз, танбур, дәф, гыҗык һәм тагын байтак кына уен кораллары татар тормышына килеп кергән. Бу гыйлемле яшьләр, кайткач, мәдрәсәләрдә үзләренең шәкертләре, дини мәҗлесләрдә гади халык алдында әлеге уен коралларында уйнап, зикер, робагый һәм мөнәҗәтләр әйткәннәр. Әлбәттә, халык аларны яратып тыңлаган, кушылып җырлаган. Бу гәмәлләре, башкарган әсәрләре халык хәтерендә әле дә саклана. Бигрәк тә саз уен коралын үз итә татарлар. Аның турында шигырьләр, җырлар иҗат итәләр. Араларында бу коралларны үзләре ясап карап, аларда уйнарга өйрәнүчеләр дә булган.

Татарларда «саз» сүзе ике мәгънәдә кулланыла. Мәсәлән, күренекле язучы һәм галим Нәкый ага Исәнбәт әлеге уен коралы турында:

«Моңланып ай нурларында,
Син сазыңны уйнадың.
Нинди кыллар чиртте, бәгърем,
Ул матур яшь кулларың?»... – дип яза.

Ә халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай:

«Әй, мөкатдәс моңлы сазым,
Уйнадың син ник бик аз.
Син сүнәсең, мин китәмен,
Аерылабыз, ахрысы»... – дип, әлбәттә, үзенең күңел моңын, хисләрен, ачы язмышын сурәтли.

Калтыран, саз, яңгыра, саз,
Дөнья тынсын, тыңласын.
Тыңласын дөнья!
Сазымның кылларын көйлим менә,
Яктылык, сафлык, мәхәббәт сеңсен
Илемнең күңеленә.

Н.Исәнбәт.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә, тарихи чыганакларда да саз уен коралы турында мәгълүмат бик аз сакланган. Булганнарына таянып, шулай ук күрше төрки

халыкларның музыка уен кораллары белән чагыштырып, аның ясалу рәвешен, уйнау алымнарын күзаллап була. Соңгы 25 ел эчендә Татарстанда гына да мин белгән халык осталары унлап саз уен коралын үзләре белгәнчә ясадылар. Шуңа күрә мин үлчәмнәрне, ясау өчен материалларны якынча гына тасвирлыйм, чөнки әле саз уен коралын һәм шулай ук гөслә, ятаган, думбыра һәм башка уен коралларын да сыйфатлы итеп ясау өчен күп эзләнергә, күп өйрәнергә, күп төрле итеп ясап карарга кирәк.

Ике төрле ысул кулланылган. Беренче ысул – сап өлеше дә, кузов өлеше дә бербөтен 90 см озынлыктагы өрәңге һәм каен агачларыннан тоташ итеп чокып, юнып ясалган. Икенче ысул – сап өлеше аерым, ә кузовы шулай ук өрәңге һәм каен агачларыннан юка итеп эшкәртелгән такталарны ябыштырып эшләнгән.

Гомумән, музыка уен коралын ясау ул – иҗади шөгыль. Ясаучы оста нинди генә уен коралын әзерләргә алынса да беренче чиратта шушы якларда үсә торган материалны сайлый. Иранда һәм Төркиядә сазның кәүсә өлешен тут агачыннан, сабын исә чиядән, өске тактасын, такталарны беркетү өчен кадакчыкларны каты чикләвек агачыннан ясыйлар. Безнең якларда да шул ук агачларның күбесе үсә, әмма аларның катылыгы, тыгызлыгы андагыдан аерыла. Бу, әлбәттә, уен коралының яңгырашына, сыйфатына тәэсир итә.

Заманалар үтү белән, татар сазының формасы күпмедер үзгәреш кичергән. Танылган рәссамнарыбыз, сәнгать әсәрләрен иҗат иткәндә, тарихи, әдәби китапларга рәсемнәр ясаганда, саз уен коралын түгәрәк итеп сурәтлиләр. Каян килә бу? Әлегә сорау ачык кала. Шулай ук хәзерге осталар да татар сазын түгәрәк итеп ясыйлар. Кылларының саны нәкъ кече сазныкы кебек: шундый ук үлчәмнәр, парлап тарттырылган өч кыл. Тик лад аралыгы ярты тоннар (хроматизм) белән көйләнгән. Сазны каурый (плектор) ярдәмендә чиертеп уйныйлар.

Павлодар шәһәрендә яшәүче Шакен ага Рахишев беренче тапкыр 1989 елда «Сорнай» ансамбле өчен ике саз ясап бирде. Соңгы елларда саз уен коралын Казанда Таһир Вәлиуллин әзерли.

Текстта Т.Вәлиуллин ясаган сазның үлчәмнәре бирелә. Озынлыгы – 1000 мм. Башта, 2-3мм калынлыктагы өрәңге агачыннан ясалган, билгеле бер формадагы һәм үлчәмдәге юка такталарны хәзерләп куялар. Аннары аларны кайнар суга салып пешеклиләр һәм кирәк кадәр бөгәләр. Шуннан соң алдан әзерләнгән калып ярдәмендә кузовны җыя башлыйлар. Өске тактасы – 2 мм калынлыктагы ак чыршы агачыннан, сап өлеше исә өрәңге агачыннан ясалган. Аңа тыгыз итеп капрон җептән (леска) 12 лад бәйләнгән, парлап металл кыллар тарттырылган. Сазны кырнак, каурый (медиатор) ярдәмендә чиертеп уйныйлар. Кылларның көйләнелеше мондый:

– түбән тавышлы ике кылның берсе кече октаваның, икенче кылы беренче октаваның-Ре тавышларына;

– икенче урта ике кыл беренче октаваның-Ля тавышына;

– өченче ике кыл икенче октаваның-Ре тавышына.

Гомумән, саз ул – затлы уен коралы, анда, гадәттә, халкыбызның югары, затлы катламы уйнаган. Бөек Тукай, Н.Исәнбәт язып калдырган шигъри юлларда гына да никадәр илаһилык, күңел байлыгы, затлылык чагыла. Сазда көйне моңлы итеп уйнап була. Бу татар музыкасы өчен бик мөһим. Тавышының тембры йомшак, ягымлы. Шәрык халыклары поэзиясендә аның тавышын «алтын тавыш», дип олылыйлар.

Татар сазы

МАНДОЛИНА

1900-1907 нче елларда татар милләте милли яңарыш чорын кичерә, азга гына булса да, чикләүләрдән котыла. Шул елларда алдынгы карашлы татар яшьләре мандолина уен коралында яратып уйный башлыйлар. Хәтта аны татарның милли уен коралы дип тә йөртәләр. Мандолина турында шигырьләр, җырлар иҗат итәләр, профессиональ башкаручылар барлыкка килә. 1930-1960 нчы елларда мәшһүр мандолиначы Исмәгыйль Һилаловның эшчәнлеге истә калырлык була. Ул уйнаган дистәләгән әсәр хәзер дә Татарстан радиосы фондында саклана. Аның сәхнәдә кулларын шулкадәр килештереп, төрле хәрәкәтләр ясап уйнавын һәм көчле алкышларга күмелүен үзем дә сокланып тыңлый идем.

Махсус музыка уку йортларында мандолина уен коралын укыту программасына кертәләр. Мәсәлән, мин белгән Арча педагогия училищесында студентларга 1970 нче елларга кадәр мандолинада уйнарга өйрәтү дәресләре керә иде.

Мандолина саз уен коралына бик охшаган. Ул – аның үзгәртеп, кечерәйтеп ясалган бер төре: шундый ук парлап тарттырылган кыллар, кылларының көйләнелеше һәм уйнау алымнары. Итальянча да мандолина сүзе «кечерәйтелгән» (mandola) дигәнне аңлата. Татар халкы шуңа да мандолинаны үз итә. «Җан тартмаса да кан тарта», диптер инде, яратып уйный, яратып тыңлый.

Мандолинаның кыллары мондый тәртиптә көйләнелә:

– беренче парлап тарттырылган түбән тавышлы кыллар кече октаваның-Соль тавышына;

– икенче, өченче кыллар беренче октаваның-Ре, Ля тавышларына;

– дүртенче кыл икенче октаваның-Ми тавышына.

Ринат Гыйләҗев,

«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе ■

Ил тотмыйча, тел тотып кара...

Бикә Рәхимова

Ил тотмыйча, тел тоткан халыклар, ягъни үзләренең мөстәкыйль дәүләте булмаганнар өчен тел мәсьәләсе һәрвакыр кискен – кабыргасы белән, ягъни көнүзәк мәсьәлә булып тора. Әйе, Атилла Расихның мәгълүм хикәясендәге «тел мәсьәләсе» инде ул – трагедиясе, комедиясатирасы бергә укмашкан.

Тел «озын» булу да телне кыскарта. Ягъни бер-берсе белән ызгышып, берничә мәртәбә дәүләтен югалткач, татар алдында туган телне саклау проблемасы барлыкка килгән... Әй, яратабыз инде без бер-беребез белән үзебез өчен зыянлы бәхәс корыр-

га. Акылга утырганыбыз юк әле. Бүгенге көндә дә, үзебез белән үзебез бәхәсләшкән булып, телебез өчен җайлы гына булган «яңалиф»не кайтара алмадык. Милләт өчен берәр уңайлы форсат чыга башласа, безнең татар тавык кебек кирегә тырный башлый. Ходайга шөкер, шулай да татарның гены – нәселдәнлеге көчле, «төштән соң булса» да, акылы да бар... Дәүләтен югалту чорыннан алып, юлда көчле каршылыкларга, зур югалтуларга да дучар булып, тырышып-тырмашып телен саклый. Тел саклау – үзеңне саклау инде ул. Халкыбызның әдәбияты, сәнгате, гореф-гадәте билгеле бер күләмдә сакланып калу – шул көрәшнең иң мөһим нәтиҗәседер, мөгаен.

Мөстәкыйль дәүләтең булмаган хәлдә тел саклау кыенлыгын башкалар мисалында да күрсәтеп үтеп була. Татарлардан бик күп мәртәбәләр уздырып, бөтен дөньяга таралган, ләкин шул ук вакытта бер-берсе белән иң оешкан-береккән милләт булган яһүдиләр дә телләрен бөтенләй диярлек югалтып бетергән булганнар икән. Шулай да алар, Израиль дәүләтен төзегәч, язмадан тел торгызалар, аны гамәлгә кертәләр...

Ай-һай, читен ул, ил тотмыйча, тел тоту. Синең телеңә урамда бәйләнәләр, эшеңдә бәйләнәләр, мәктәптә бәйләнәләр, балалар бакчасында бәйләнәләр. Брежнев чоры дигән елларда эштә, авыз ачып, үз телеңдә сүз әйтерлек хәл калмаган иде: «Не говорите по-татарски, это не культурно!» Куркытуның шундый «культурный» юлын таба беләләр диген, ә! Ярый әле без – татар теле укытучылары Разия апа, Мөслимә, мин: «Өйрәнегез сез дә безнең телне, гомер буе безнең белән бергә яшисез бит», – дип әйтә ала идек. Ә берсендә, урамда татар кешесе дип ялгыш эндәшкәч, «ваш поганый язык», дип әйтмәсләрме?!.

Менә тагын безнең өчен читен заманаларның кара офыгын ачабыз, дип, Жириновскийлар йөгерешеп йөриләр. Безнең барлы-юклы дәүләтчелегебезгә теш кайрый башладылар. Һәм иң яманы – татар шунда ук артка чигенү ягын карады. Матур гына татарлашып килгән мәктәп-гимназияләребез күзгә күренеп артка тәгәри. Анда укучы балалар бер-берләре белән урысча сөйләшә башлады. Иң ояты – сораштыра башласаң, «Казан утлары» журналының, «Мәдәни җомга» гәҗитенең ни икәнен... белмиләр, башкалары турында әйтеп торасы да юк. Мондый чорда бездән бигрәк тә оешканлык, бигрәк тә эчке оешканлык таләп ителә инде. Халкыбызның милләт өлеше әйткән, сөйләгән, язган һәрбер үгетләү сүзләренә барчабыз колак салып, аңлап, түрә яисә гади бер татар кешесе булуга карамыйча, вак-төяк «мин-минлеккә», һавалану-зурлануга, бөтенләй дә начары – битарафлыкка бирелмичә, өч көнлек дөньяның алдавычларына кызыгып сатылмыйча, туган телебез мәсьәләсендә барыбыз да бер булып аны яклашсак, саклашсак иде! Безнең гомер – мизгел, ә татар теле барыбыздан да олы, галибанә, ул мең-мең елларны кичеп килә. Билгеле туган телебез дә татарга рәхмәтле булачак – үзенең гүзәл гыйбарәләре белән колакларыбызны иркәләп, укыган чакта күзләребезгә дә шифа булачак.

Бездә эчке оешканлык патша Россиясе заманнарында ук булган. Тик бүгенге шартларда аеруча оешканлык таләп ителә. Алда әйтеп үтелгәнчә, ун-унбиш еллар элек, салкын карны тишеп җирдән калыккан умырзая чәчәге кебек, бер-бер артлы ачылган татар мәктәп-гимназияләренә конкурс белән керү азайды гына түгел, аннан кире агым башланды. Безнең ата-аналар шундый бер «сизгерлек» күрсәтәләр ки, имеш, заманаларның кая таба барганлыгын бик тиз аңлап алалар... Намус дигән нәрсә дә булырга тиештер бит әле бу дөньяда? Үзеңнең татарлыгыңа – туган телеңә хыянәт итү намуслылык билгесе түгелдер инде ул.

Күренекле язучыбыз Тәүфикъ Әйдинең бөтен дөнья буенча сибелгән татарлар турында язуын күбебез белә булыр. Ул сурәтләгән йөзләрчә татар кешесенең һәрберсе татар мәктәпләрендә укып, алга таба элеккеге СССРның әллә ничаклы мәртәбәле югары

уку йортларында белем эстәп, дөньякүләм атаклы кешеләр булганнар. Белмәсәң, бел, дигәндәй, атом реакциясе үткәрелә торган казаннарның ныклыгы да Казан шәһәренең ике-өч кенә йортлы Завод урамында уйнап үскән, татарның 12 нче мәктәбендә белем алган безнең татар кешесе Шәүкәт Ибраһимовның фәнни һәм гамәли эшчәнлегенә турыдан-туры бәйләнгән булган икән. «Татар мәктәбендә укып, кеше булып булмый», – дигән кайберәүләргә җавап булып языла минем бу сүзләрем. Юкны сөйләп йөрмик, татар мәктәбендә тырышып укыган балага ныклы белем алырга да, чын кешечә тәрбияләнергә дә мөмкинлекләр җитәрлек. Рухи яктан кеше булу – бүгенге көндә иң әһәмиятлесе әле ул. Урыс мәктәбендә укыган һәр татар баласы югары уку йортына кереп укый дип белерсең. Алай түгел ич, аннан соры масса күбрәк чыга әле. Бу хакта Казан дәүләт университеты студенты Элмира Гыймәтуллина болай ди: «Урысча миллионлаган кеше укый... Ә шулай да илдә күпме сукбайлар, эшсезләр, хәерчеләр, җинаятьчеләр...» Яисә бик тә билгеле, күркәм укытучы, Даур урамында урнашкан педагогик көллиятнең директоры Марат Гәйнетдиновның әйткәннәренә колак салыйк. «Тулай торакта яшәүче дүрт йөз студент бала арасында бер генә норкаман да, эчкечелек белән шөгыльләнүче дә, тәмәке тартучы да юк, – ди ул. – Ә менә инде татар мәктәбендә укып, берәрсенең баласы алга таба укый алмаса, әлеге хәбәр тиражланып таратыла. Бу эштә баланың әти-әнисе «тырышлык» күрсәтә. Гәепне башка җирдән эзлисе урынга...»

Заманалар үзгәреп, хосусый милек, хосусыйлаштырулар килде. Байлык шәхси кулларга күчә. Бәлки татар байлары да күбәя төшәр әле, дип ышанасы килә. Тик әлегә алар элеккеге Хөсәеновлар да, Рәмиевләр да түгел.Татар телен яшәртү өчен матди ярдәм кирәклеген аңлый торганнары сирәк күренә. Өстәвенә, һәртөрле кызганыч хәлләр шаһиты да булырга туры килә. Бераз хәлле татар кешесе бер шәһәрдә татар балалары укыган мәктәпне төзекләндертә, мәчеткә хатын-кызлар өчен иркен янкорма төзеттерә. Ни гаҗәп, бер дин әһеле бу эшләргә каршы килә, ул төрлечә аяк чалырга тотына, төрле киртәләр кора башлый. Билгеле инде, теге кешенең гайрәте чигә... Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: мәчет-мәдрәсәләрдә туган телебезнең бик аз өйрәнелүе алардагы җитәкчеләрнең милли аңы бик түбән дәрәҗәдә булуын күрсәтә, күрәсең.

Шулай да тырмашабыз әле. Әллә кайларда, Татарстаннан читтә яшәүче, туган телебездә рәтләп ипи-тозлык та сөйләшә белмәүчеләрнең дә «родной язык» дигән графага «татарский» дип язучылары турында әйтүем. Соңгы вакытта ул графаны юкка гына бетермәделәр ич инде, кемгәдер комачаулый, димәк...

Аннан, тагын да мәктәп белән бәйле хәл. Ата-аналар, мәктәпкә килеп: «Ипи, тоз дип әйттерә алмаган балаларыбызга туган телне өйрәтәсез, рәхмәтләр яусын сезгә», – дип, елый-елый рәхмәтләр әйтәләр иде. Шуны да искәртик: Идел-Урал төбәгендә шул Брежнев хакимияте елларында урысча укытуга күчеп беткән катнаш мәктәпләрдә туган телне өйрәтү бары тик татарларда гына иде. Соңыннанрак, бездән күреп, башка халыклар да укыта башлады.

Татар халкы үзенең яшәешенең җайсыз-уңайсыз чорларында туган телен җыр җырлап та саклады. Бу уңайдан бик зур ярдәмчебез ул җыр. Сихри көйләргә үрелеп, колакка ятышлы сүзләребез күңелгә сеңә, үзләштерелә. Татарның иң күп барганйөргән урыны – театр тамашалары һәм концертлар. Тик соңгы вакытта җырга кагылган уңайсызлыклар да чыгып тора. Глобальләштерү шаукымы милли көйләребезгә дә һөҗүм итә башлады, дөньякүләм бертөрле көйсезлек-моңсызлыкка тартып кермәкче булалар. Татар көе хәтта үзебезнең төрки кардәшләребезнекеннән дә аерылып тора иде, әле дә шуңа омтылырга кирәктер. Моңа чаклы татар колагы иң нечкә моңлы борылышларны, мелизмнарны ишетеп яшәде, ә инде бер-ике генә нотадан торган, турыдан-туры

кычкырта торган көйләр җырлый, тыңлый башласак, халкыбыз моңнарыннан бөтенләй бизгән татарлар кавеме барлыкка килергә мөмкин, Аллаһ сакласын!

Телебезне баетуга килгәндә, без ялгышрак юлда бугай. Бөтен халыкларда да тел, нигездә, алынма сүзләр хисабына байый. Барчасы да күршесеннән сүз ала да, үз теленең кагыйдәләренә туры китереп, аны әйтә башлый; яңа сүз шулкадәр дә үзләшеп китә ки, аны читтән кергән, дип уйлаучы да булмый. Бары тик галимнәр генә ул сүз тарихын өйрәнеп-тикшереп, аның беренчел нигезен табарга мөмкин, чынлыкта ул сүз кабул иткән телнең үзенеке булып йөри – «ищи ветра в поле» кебек. Ә менә безнең тел мисалындагы хәлләр гаҗәпләндерә. Бездә алынма сүзне үзенең иске кагыйдәләре буенча хәрефен хәрефкә туры китереп язалар, авазын безнең артикуляциягә туры килмәгән очракта да бугаз ертып әйтәләр һәм... әйттерәләр. Гүя безне кемдер күзәтеп, болар сүз урламасын, дип, карап-тикшереп тора. Нәтиҗәдә, теге сүз дә «мин сезнеке түгел», дип «кычкырып» тора. Телне алай баетып булмый. Үзебезнең тел тегермәнендә тарттырсак кына безнеке була ул алынма сүз. Тел баетуның тагын бер юлы – диалекталь сүзләрдән файдалану. Татарның диалектлары бай, күп тармаклы, шундый кирәкле, шундаен да матур сүзләр күп алар эчендә, сайлап-сайлап кына иң кирәкләрен, иң матурларын аласы гына кала, ләкин ялт итеп каршы төшүчеләр табыла... Бу хәлне дә үзең утырган ботакны үзең кисү, дип әйтмичә, башкача ни дип атыйсың.

Тел саклау һәм аны баету мөмкинчелеге булып торган тагын бер урын бар. Безнең шартларда бу урын беренчеләрнең беренчесе әле. Бар ул андый урын: ул – гаилә. Әбибабае, әти-әнисе, углы-кызы булган гаиләдә мөлдер-мөлдер генә тутырып, гөлдер-гөлдер генә гөрләшеп-сөйләшеп чәй эчеп утыруны гына күз алдына китерсәк тә, туган тел өчен борчылуларыбызның нәкъ яртысы юкка чыгар иде! Сирәгрәк күренештер шул бу. Ешаеп торсын иде шундый манзаралар. Шигырь дә шуны тели:

...Газизем, дип, кадерлем, дип,
Иркәләсәм баламны,
Бу чынында үз телемне –
Татар телен барлавым.
Шикәрем, балым, дисәм дә,
Бал тәмен тоям телдә.
Чын татар гамәле булыр –
Сөйләшик туган телдә!
Газиз телем – чиксез күгем,
Син – диңгезем, хыялым.
Мәңгегә сине яшәтү –
Бердәнбер ихтыярым!

2004 ел.

*Сәхифәне **Рөстәм Акъегет** «Татарстан» радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруы язмасына нигезләп әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2019

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

КУЛТАМГАЛЫ КИТАПЛАР ТУПЛАНМАСЫ

Милли китапханәдә танылган галимнәр, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре кул куйган китаплар да саклана. Болар – авторы яисә иясе тарафыннан истәлекле култамга язып бүләк ителгән яки тапшырылган китаплар. Фондларда нәкъ менә шундый язуы булган китаплар, бердәнбергә әйләнеп, мәдәни һәм әдәби-тарихи кыйммәткә ия кадерле ядкяр мисалында, китапханәнең йөз-рухын күтәрә. Андый басмалар тематик күргәзмәләрне бизи, төрле эчтәлектәге чаралар оештырганда һәрчак китап сөючеләрдә даими кызыксыну уята, игътибарын җәлеп итә. Тупланманың мондый тамгалы нөсхәләре кулъязмалар һәм сирәк китаплар, татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, сәнгать бүлекләрендә саклана.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган И.А.Второв тупланмасындагы китапларга аның үз кулы белән «Иван Второв» дип язып куелган. «Рус-татар сүзлеге, Тоболдагы төп училищеда татар теле укытучысы рухани Иосиф Гиганов җыйган һәм йорт татарлары муллалары тарафыннан расланган» дип аталган, күләме 680 битне тәшкил иткән, 1804 елда Санкт-Петербургта басылган китап кызыклы. Титул битенә кара төстәге кара белән иясе болай дип язган: «Дворяннар башлыгы Иван Николаевич Владимировныкы».

Александра Андреевна Фукс «Шигырьләр. Казаннан Чабаксарга сәяхәт» (1834) дигән китабын Иван Алексеевич Второвка болай дип язып бүләк иткән: «Мөхтәрәм әфәнде Иван Алексеевич Второвка». Бу – бик кадерле һәм кыйммәтле китап.

Чираттагы кадерләп сакланган китапка: «Галиҗәнап әфәнде Иван Павлович Павловка. А.Дубровин. 1868 елның 1 гыйнвар көне», – дип култамга салынган. Басманың исеме – «Таң: Җиңел укылышлы җыентык В.Г.Бенедиктов, Ф.П.Берг, П.И.Вейнберг, И.С.Генслер, Н.В.Гоголь, И.Ф.Горбунов, Ф.А.Зиновьев, В.В.Крестовский, В.С.Курочкин, Л.А.Мей әсәрләреннән төзелгән» (Казан, 1868).

И.А.Сахаров тупланмасында истәлекле язу калдырылган биш китап бар. Алар арасында Казан университетының рус теле-әдәбияты, гомуми әдәбият тарихы буенча профессор К.К.Фойгтның «Г.Р.Державинга Казанда һәйкәл ачканда 1847 елның 25

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.





августында ясалган чыгыш» дип исемләнгән китабы бар, аның форзац битенең икенче ягына болай дип язылган: «Иван Александрович Сахаровка ихластан рәхмәтемне һәм икърар итүемне белдереп. Автор. Казан. 1848 елның 9 марты». Бүләк ителгән тагын бер китап авантитулында Сахаровның Түбән Новгород гимназиясендә бергә укыган курсташы, булачак язучы П.И.Мельников (Печерский) култамгасы тора: «Иван Александрович Сахаровка. 1846, сентябрь, 3».

Берничә китап танылган педагог М.А.Малиновскийга адресланган: «Галиҗәнап Михаил Афанасьевич Малиновскийга, Вильна уку-укыту округы попечителе ярдәмчесенә, югары дәрәҗәдәге төрле орденнар кавалерына тирән ихтирам белән автор Б.Сегаль тәкъдим итә. Вильна, 26 март, 1873 ел».

Бүләк ителгән китаплар арасында авторы тарафыннан кул куелганнары да, китапны төзүчеләр, мөхәррирләрнең – әдәбият-сәнгать белгечләренең һәм галимнәрнең, төбәкне өйрәнүчеләрнең һәм гап-гади укучыларның да култамгаларын куйганнары бар. Күбесенең эчтәлеге охшаш: «Казан шәһәренең җәмәгать китапханәсенә. Автордан», – дип язылган. Шулай кыска гына язып китап бүләк итүчеләр арасында рус теле белгече, профессор С.К.Булич, әдәбият тарихы белгече П.В.Владимиров кебек танылган шәхесләр дә бар.

Култамгалы китаплар арасында Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә аның элекке директоры, хәзер китапханәнең Химаячеләр шурасы рәисе Разил Исмәгыйль улы Вәлиев бүләк иткәннәре шактый. Болар – рус һәм татар телләрендәге мең ярымга якын нөсхәдәге һәм гарәп, төрек телләрендәге берничә басма. Алар барысы да Р.И.Вәлиевкә күренекле җәмәгать эшлеклеләре, танылган галимнәр, язучылар,

шагыйрьләр, композиторлар тарафыннан бүләк итеп бирелгән. Арада Лев Ошанин, Роберт Рождественский, Нурихан Фәттах, Туфан Миңнуллин, Әбрар Кәримуллин, Рабит Батулла, Вахит Имамов, Фирдәүс Гарипова, Тәлгат Галиуллин, Равил Фәхретдинов, Мәсгуть Имашев һ.б. бик күпләр бүләк язуы, теләкләр язып, имза куеп тапшырган китаплар бар. Әлеге кыйммәтле басмалар да кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә кадерләп саклана.

Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә дә атаклы галимнәр, әдәбиятсәнгать әһелләре, наширләр тарафыннан бирелгән автографлы китаплар саклана. Шундыйлардан Казан университеты профессоры С.Шпилевскийның «Казан губернасындагы борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар ядкярләре» (Казан, 1877) дип

аталган, «Казан шәһәр җәмәгать китапханәсенә автордан. 15 окт. 1877 ел» дип бүләк сүзләре язылган китабы бар. Тагын берсе – «Казан патшалыгының яралуы хакында һәм Мәскәүнең олуг кенәзләренең Казан ханнарын җиңүе турында хикәят...» (Казан, 1902). Казанның Император университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы Федор Тихонович Васильев кулъязмасын файдаланып бастырылган бу китап: «Казанның шәһәр җәмәгать китапханәсенә наширдән», – дип язып бүләк ителгән. Хива ханы Әбелгазый әсәренә нигезләнгән «Төркиләрнең шәҗәрә агачы, Г.Саблуков тәрҗемәсе һәм кереш сүзе, Н.Ф.Катановның йомгаклау сүзе һәм искәрмәләре» (Казан, 1906) исемле китаптагы «Казан шәһәр китапханәсенә, 50 еллык юбилее хатирәсе итеп, Казан Император университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятеннән. Рәис М.Хвостов. 10/27 гыйнв. 1915 ел» дигән сүзләр аеруча истәлекле.

1917 елга кадәр чыккан басмаларның байтагы фән кешеләренең бер-берсенә автограф белән бүләк итешкән китапларыннан тора. Мисал өчен, язучы А.Фуксның «Казан губернасындагы вотяклар янына бару. А.А.Фуксның җәмәгате К.Ф.Фукска хатлары» (Казан, 1844) китабында «Җәнабе галия Елена Павловна Фадеевага китапның иҗатчысыннан» дигән сүзләр язылган; Казанның керәшен татарлары мәктәбе укытучысы Семён Максимов «Казан губернасындагы хәзерге керәшен татарларының дин тотуында мәҗүсилек калдыклары» (Казан, 1876) дигән үз китабын Казанның укытучылар әзерләүче семинариясе директоры Н.Ильминскийга язып бүләк иткән булган; математик, Казан университеты профессоры Ф.М.Суворов «Лобачевский геометриясенең нигезләре: Казан Император университетында узган тантаналы җыелышта ясалган доклад» (Казан, 1876) дигән култамгалы китабын И.М.Догельгә биргән; «Рус телен укыту хакында: (Казанның укытучылар әзерләүче татар мәктәбендәге күзәтүләрдән)» (2 нче басма, Казан, 1899) дип аталган китабын В.А.Богородицкий, автограф белән, Казан университетының атказанган профессоры Ф.Г.Мищенкога тапшырган; П.А.Пономарёв үзенең «Лобачевский биографиясенә карата (моңарчы басылмаган хат һәм замандашларыннан язып алынган сүзләр буенча)» (Казан, 1913) исемле китабын автограф белән М.М.Ивановка; Казан рухани академиясе профессоры Я.Д.Коблов «Казан татарларының дини мәктәпләре» (Казан, 1916) дип аталган китабын автограф белән А.Г.Муравьёвка бүләк иткән.

Танылган язучылар тарафыннан бүләк ителгән китаплар күз карасы кебек саклана. Габдрахман Әпсәләмовның «Республикабызның мактанычы һәм горурлыгы В.И.Ленин исемендәге китапханәгә. 10/XII-49, Казан» дигән автографлы «Алтын йолдыз»ы (Казан, 1949), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Сүнмәс утлар»ының 2 нче басмасы (Казан, 1960); Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәнис Яруллин китабы, Зәки Нуриның китапханәгә 100 ел тулган көннәрдә «Юлбашчыбыз Ленин исемендәге үзәк китапханәбезгә – 100 еллык юбилее көнендә, китап пропагандалау һәм мәгърифәт эшендә тагын да зур уңышлар теләп: Зәки Нури. 1965 ел» дигән автограф белән бүләк ителгән «Туган көн» шигырьләр җыентыгы, шагыйрь Мәхмүт Хөсәен китабы, Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» дигән автобиографик повесте, язучылар Вакыйф Нуруллин, Фоат Садриев, Юныс Сафиуллин һәм башкаларның култамгалы китаплары кадерле урыннарны биләп тора. Драматург Юныс Сафиуллин китабына шундый юллар язган: «Инде 50 ел буе миңа белем биргән кадерле китапханәмә истәлеккә. Автордан». Китапханәдәге чыганакларны файдаланып язылган һәм авторлары тарафыннан бүләк ителгән китаплар – Ф.Гуловның «Татар милли аяк киеме» (Казан, 1983) монографиясе; П.Т.Власовның «Казанда Октябрь таңы» (Казан, 1988) дигән документаль повесте.

А.Беляевның «Татар халкының тарихи нәсел тармаклары. Буыннан-буынга

килгән туганлыкның гаилә, милләт һәм дәүләтчелектә тарихи роле» (Казан, 2012) дип исемләнгән кызыклы фактларга бай китабына: «Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә, ихлас теләкләремне белдереп, автордан», – дип язып кул куелган. Шулай ук, изге теләкләрен белдереп, Алексей Иванович һәм Владимир Алексеевич Чернышевлар үзләре язган «Чернышевлар гаиләсенең нәсел агачы» дигән китапны «Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә бүләк. Хөрмәт белән авторлар Алексей Иванович һәм Владимир Алексеевич Чернышевлар» дигән автограф белән китапханәгә тапшырганнар.

Бигрәк тә 1990 нчы елларда китапханәнең Сәнгать бүлеге Россия һәм Татарстан язучылары, композиторлар, музыка белгечләре, дирижёрлар, җырчылар, биючеләр, артистлар бүләк иткән култамгалы китапларга баеды. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган пианист, композитор, педагог Рафаэль Биляловның туганнары үзе исән чагында аңа төрле шәхесләр тарафыннан истәлекле имзалар куеп бирелгән уникаль документларны китерделәр. Ул җыелмада СССРның халык артисты, Татарстан Республикасы гимнын язган мәшһүр композитор Рөстәм Яхинның да автографы бар.

Россия Федерациясенең Дәүләт бүләге иясе, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор, Милли китапханәнең шәрәфле укучысы Леонид Любовский бүләген дә әйтеп үтәргә кирәк. Ул үз кулы белән тапшырган «Тромбон һәм фортепиано өчен соната», «Стильләр уены», «Фикерләр», «Театр өчен сюита», «Муса Җәлил истәлегенә романс» кебек ноталы җыентыкларына, китапханәгә һәм аның хезмәткәрләренә атап матур теләкләр язып, имзасын куйган.

Тарихчы, сәнгать фәннәре кандидаты, күренекле композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Георгий Кантор гомеренең соңгы көннәренә кадәр китапханәнең Сәнгать бүлеге белән тыгыз дустанә элемтәдә торды һәм хезмәттәшлек итте. Бүлек фондында аның «XIX гасырда-XX гасыр башында Казанда музыкаль театр» дигән култамгалы китабы кадерләп саклана.

Тупланманың йөзек кашы булган «Татар халык җырлары» җыентыгына аның төзүчесе, музыка белгече, мөгаллим, профессор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов та истәлекле сүзләр язып калдырган. «Мин гармун булыр идем» дигән ноталы җыентыгына танылган композитор, РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Фасил Әхмәтов, автор буларак теләк-фикерләрен белдереп, имзасын куйган. «Татар-мишәр җырлары» җыентыгына төзүчесе, музыка белгече, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Земфира Сәйдәшева; «Л.Бетховен. 1 нче симфония; 2 нче симфония» грамьязмасына дирижёр, укытучы-остаз, СССРның халык артисты Натан Рахлин; «Концерт-89» язмасына РСФСРның, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Ренат Ибраһимовлар кулы белән язылган автографлар кыйммәтле ядкяр булып тора.

Композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Резеда Ахиярова Милли китапханәгә Татарстан композиторлары иҗат иткән милли музыка фондын булдыруда уңышлар теләгән. Бу язма – аның «Балалар өчен фортепиано пьесалары» дигән җыентыгындагы матур истәлек.

Тупланмада атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы эксперты, «Кристи» аукцион йортының (Нью-Йорк, Лондон) киңәшче белгече, рус зәркән сәнгатенең күренекле белгече Валентин Скурловның «Татарстанның Милли китапханәсенә – бүләккә. Казанның 1000 еллыгында» дигән факсимиль язмасы-автографы бар.

РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт Әсәдуллин үзенең «Мәһди» дип аталган грамтәлинкәсенә әнә нинди җылы сүзләр язган: «Татарстан Мил-



ли китапханәсенең Сәнгать бүлегендә эшләүче ягымлы ханымнарга – Музыка дигән могҗизаны саклаучыларга!».

«Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә, Казанның бөек мәдәни традицияләре варисына хөрмәт белән» дигән эчтәлекле култамга – педагог, режиссёр, театр тәнкыйтьчесе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ю.Благовныкы.

Республиканың мәдәният министры булып эшләгән Илдус Тарханов Милли китапханәгә шактый күләмдә автографлы документлар бүләк иткән. Алар арасында музыка белгече, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның Композиторлар берлекләре әгъзасы, сәнгать фәннәре кандидаты, доцент Ф.Я.Шәмсетдинова; Казан мәдәният һәм сәнгать академиясенең татар бүлеге укытучысы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ф.Т.Арсланова; җырчы, Россия Федерациясенең атказанган, Татарстан Республикасының халык артисты М.М.Сөнгатуллин кебек күренекле сәнгать эшлеклеләренең автографлары бар. ■

ИЮЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 июльдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов классик язучыбыз Шәриф Камалның мемориаль фатирында урнашкан Татар әдәбияты тарихы музеенда булды. Очрашу вакытында язучының туганы Эльза Шакирова-Байгильдиева Ш.Камал әсәрләренең яңартылган басмасын бүләк итте.

● 1 июльдә Татарстан Хисап палатасы оешуга 15 ел тулды. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шул уңайдан Хисап палатасы коллективын бәйрәм белән котлады.

● 2 июльдә ТНВ телерадиокомпаниясе беренче татарча ситком төшерә башлады. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов ситкомның илле серияле булуына өметләнүен белдерде. Сценарийны бер төркем

язучылар – Ркаил Зәйдулла, Аманулла, Ләбиб Лерон, Рөстәм Кәримуллин, Альберт Шакиров, Рәмис Нәҗмиев, Айсылу Хафизова язган. Идея авторы – Мансур Гыйләҗев.

● 4 июльдә РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Илгиз Мәҗитов яшәгән йортка (Зур Кызыл урамы, 14 нче йорт) истәлек тактасы куелды. Чарада Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады.

● 4 июльдә Актаныштa Татарстан китап нәшриятының генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин һәм Башкортстанның З.Биишева исемендәге «Китап» нәшрияты директоры Илһам Яндәүләтов ике нәшриятнең хезмәттәшлеге турындагы килешүне яңартты.

● 5 июльдә Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрен ачу тантанасы узды. Чарада Мәскәү шәһәренең Милли сәясәт һәм төбәкара элемтәләр департаменты җитәкчесе Виталий Сучков, Татарстан Премьер-министры урынбасары, Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле

Равил Әхмәтшин, Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев, Мәскәү татар милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе Фәрит Фарисов, Түбән Кама шәһәре мэры Айдар Метшин, Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин. Гәрәй Рәхим һ.б. катнашты.

● 6 июльдә Чүпрәленең «Мишәрләр» балалар фольклор-этнографик ансамбле «Әйлән-бәйлән» республика фестивалендә I дәрәҗә лауреат Дипломы белән бүләкләнде.

● 6 июльдә Биектау районының Кече Битаман авылында Туфан Миңнуллин исемендәге II Бөтенроссия драматурглар семинары үтте. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлеге оештырган әлеге күркәм чарада Мәдәният министрлыгы вәкиле Рәшит Фәтхуллин,

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, драматурглар – Рабит Батулла, Мансур Гыйләҗев, Әхәт Гаффар, Хәбир Ибраһим, Рушан Шәриф, Ләбиб Лерон, Халисә Мөдәррисова, режиссерлар – Илдар Хәйруллин, Фаил Ибраһимов, театр белгечләре – Ильтани Илалова һәм Әлфәт Закирҗанов, шулай ук Башкортстан, Удмуртия һәм Мари-Эльдан килгән иҗат әһелләре катнашты.

● 9 июльдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Бөтендөнья мөселман җәмгыятьләре советы (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) рәисе урынбасары Наср Мөхәммәд Ареф җитәкчелегендәге делегация белән очрашты.

● 11 июльдә «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова «Тынычлык розасы» алтын медале белән бүләкләнде. Әлеге бүләкне баш мөхәрриргә Дөнья мәдәнияте институты (ЮНЕСКО) ректоры, «Европа-Азия» Халыкара гуманитар академиясе президенты, академик Энгель Таһиров тапшырды. Россия Журналистлар берлеге сәркатибе Роман Серебряный

исә Венера Абдулла кызына «Россия Журналистлар берлегенә 100 ел» медален бүләк итте. ■

Мирасворд

Татар телендә чыга торган журнал

Язучы … Хәйруллин

Француз композиторы

Коры елга

Сихер, өшкерү, тылсымлы дога

Мәҗүсиләр табына торган сын, балбал

Удмуртларның элекке исеме

Тегү машинасында: җепле шүрене йөртә торган җайланма

Элекке мәдрәсәдә шәкертләрне күзәтеп, тикшереп торучы

… Урда

Нартага җигелгән этләрне куучы

1917 елда Казанда Шәһит Әхмәдиев чыгарган газета

Шаян эчтәлекле кыска эстрада пьесасы

Язучы Тәүфикъ …

Бик тиз, күз ачып йомганчы (диал.)

Алтын Урда шәһәре

Өчпочмаклы яулык (иск.)

Ханәкәнең хезмәтче кызы (бор.)

Дунайның борынгы атамасы

Кул белән җеп әрләү өчен агач таякчыктан гыйбарәт корал

Чокып ясалган клишедән төшерелгән рәсем

Ык кушылдыгы

Каеш прәшкәсе

Мич юллыгын томалый торган тимер клапан

Финикиядәге борынгы шәһәр-дәүләт

Галимә … Бәширова

Коръән сүрәсе

Эрих Мария Ремарк романы

Актер Нури …

Композитор … Хисамов

Татар халык җыры

Карл Маркс туган шәһәр

Афинада яши

Һавадагы бушлык, ачык урын (иск.)

Габдулла Тукайның 1906 елда язган шигыре

Эндре … (мажар шагыйре)

Хәсән Туфан поэмасы

… Фадлан

Шәриф Камал хикәясе

Рәис Габдулла *төзеде.*

7нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: «Кояш», әл, Латыйф, Имай, Вургун, Кыям, укол, машалла, Фән, «Золым», комык, изах, Вары, нун, октава, Туишев, Хуҗа, Авл, Ромен, Лия, «Ил», Гуд, көлтә.
Өстән аска: муафыйк, уалу, шәм, тәҗвид, Сөләйманова, яла, ял, Кави, кәтавыл, Ра, олы, указлы, «Чукрак», Шәфигуллин, ук, ызу, Шамил, Ногман, елт, Твен.



Ш.Камал музее урнашкан бина (Казан, Островский урамы, 15 нче йорт)

«Безнең мирас» елъязмасы /август

100 ел элек (1919)

Үзәк мәгариф бүлеге тарафыннан Мәскәүдә ике айлык татар теле курслары ачыла.

100 ел элек (1919)

Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге карамагындагы татар драма артистлары труппасы Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен (режиссеры – Кәрим Тинчурин) куя.

90 ел элек (1929)

Мәскәүдә «Октябрь баласы» исемле журнал (җаваплы редакторы – Муса Җәлил) чыга башлый.

85 ел элек (1934)

17 августта Мәскәүдә Совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съезды ачыла. Съездда Татарстан вәкиле булып тавыш бирү хокукы белән 12 кеше (М.Горький, Г.Ибраһимов, К.Нәҗми, К.Тинчурин, Г.Гали, Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи, Г.Толымбай, И.Гази, Л.Гыйльми, В.Киршон, Новиков-Прибой) һәм киңәш бирү хокукы белән 6 кеше (Г.Ризванов, Б.Красный, К.Төхфәтуллин, Х.Туфан, Б.Зернит, С.Кирьянов) катнаша. 19 августта Татарстан делегаты К.Нәҗми «Татар матур әдәбияты» дигән доклад белән чыгыш ясый.

80 ел элек (1939)

«Давид Сасунлы» эпосының 1000 еллык юбилеен үткәрү өчен Татарстан Язучылар союзы комиссия (Ш.Маннур, Х.Туфан, Ә.Исхак) төзи.

80 ел элек (1939)

ТАССР Халык Комиссарлары Советы Татар Тел, әдәбият һәм тарих гыйльми-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә. Институт 1945 елның декабреннән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составына керә.

75 ел элек (1944)

Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында әдәбият музее оештыру, Ш.Камалның фатир-музеен булдыру турында РСФСР Халык Комиссарлары Советы карары кабул ителә.

75 ел элек (1944)

Берлинның Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре Гайнан Кормаш (төркемнең җитәкчесе), Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров җәзалап үтерелә.

*Журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. АВГУСТ 2019



И останется в мире слово моё…: Газинур Мурат.

Историческое наследие: «Сююмбике». О.Иванова; «Всеобщая история тюркских народов». Х.Габаши; «Этруски – наставники римлян». С.Шамси; «Под огнём большевизма». К.Наджми; «Напоминание о двадцатых годах…» Р.Мухаметшин.

Татарский мир: «Наше время и наши современники». Р.Хабибуллина.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Воспоминания». С.Сунчалай; «О трагедии «Хусаин мирза». А.Ахмадуллин; «Хусаин Мирза». Ф.Бурнаш.

Эхо войны: «Верность священной клятве». Ш.Мустафин.

В глубинах памяти: «Памяти уважаемого Мудамиля». Р.Зарипов; «Школы и одноклассники». Л.Лерон.

Художественное наследие: «Древние татарские музыкальные инструменты». Р.Гилязов.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. AUGUST 2019

There will be left my word in the world…: Gazinur Murat.

Historic heritage: «Suyumbike» by O.Ivanova; «General history of Turkic people» by Kh. Gabashi; «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «Under fire of Bolshevism» by K.Nazmi; «Regards from the 20th century...» by R.Mukhametshin.

Tatar world: «Our time and our contemporaries» by R.Khabibullina.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Recollection» by S.Sunchalay; «About the tragedy «Khusain mirza»; «Khusain Mirza» by F.Burnash.

The echo of war: «Fidelity to the sacred swear» by Sh.Mustafin.

From the deepest store of memory: «Recollection of honorable Mudamil» by R.Zaripov; «Schools and classmates» by L.Leron.

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

Ирина Колмогорцева

1930 елның 5 июлендә Свердловск шәһәрендә туа. 1953 елда Львов полиграфия институтын тәмамлый. Ирина Константиновна – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1960), ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981), ТРның Халык рәссамы (2005), ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премия лауреаты (2007).
Казан шәһәрендә яшәде. 2015 елда вафат булды.

һ.Такташның «Тәүфыйклы песи» дигән әкиятенә иллюстрация.
1960-1970 нче еллар. Кәгазь, тушь, акварель, каләм

һ.Такташның «Тәүфыйклы песи» дигән әкиятенә иллюстрация.
1960-1970 нче еллар. Кәгазь, тушь, акварель, каләм

«Май аенда Казансу».
1977.
Кәгазь, йомшак лак, төсле офорт, акватинта

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Казан дәүләт консерваториясенең өченче курс студенты Наҗия Теркулова.1954 ел
(А.Хәкимова. «Якты күңелле җырчы».)

Кемнәр алар – болгарлар? Нәкыйп Каштан
Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләре. Рәйсә Шәрәфиева
Туган ил каян башлана? Эльмира Шәрифуллина
Сәер дустыбыз Шамил. Әгъзам Фәйзрахманов
Тарих шаһитлары. Абдулла Дубин
Якты күңелле җырчы. Алсу Хәкимова

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *podpiska.pochta.ru сайты ярдәмендә*

электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.